Безнен МИРАС

03

март 2015

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ПЕДАГОГИК, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

2015 елның 27 февралендә, Россия Федерациясендә Әдәбият елы булу уңае белән, Татарстан Республикасы Дәүләт Советында җөмһүриятебездәге милли әдәбиятларны үстерүнең актуаль проблемалары һәм перспективаларына багышланган «түгәрәк өстәл» үткәрелде.

Чарада галимнәр, филологлар, фәнни учреждениеләр һәм мәгариф оешмалары җитәкчеләре, язучылар, шагыйрьләр, журналистлар, министрлыкларның һәм ведомстволарның шул юнәлештәге белгечләре, укытучылар катнашты.

Утырыш барышында Татарстан Республикасында милли әдәбиятларның торышы һәм үсеше, профессиональ кадрлар әзерләү, уку-укыту программаларында милли әдәбиятны чагылдыру, әсәрләрне урыс теленә тәрҗемә итү, китап продукциясен бастырып чыгару һәм тарату мәсьәләләре турында фикер алышынды.

ГОД ЛИТЕРАТУРЫ В РОССИИ
2015

ХӘЛЕҢ НИЧЕК, ӘДӘБИЯТ?

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдмәнд

Безнең МИРАС 12 +
03(38)
март 2015
www.beznenmiras.ru

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ
тарафыннан гамәлгә куелды.
2012 елның май аеннан чыга.

4

38 ЧАЛЛЫ-ЧИБӘРКҮЛ АРАСЫ, УРАЛ КИЧЕП БАРАСЫ. *Людмила Белоусова*



84 БЕР СҮЗДӘН ТОРА ДӨНЬЯ… *Рүзәл Мөхәммәтша*

ЭЧТӘЛЕК

2015 ЕЛ — РОССИЯДӘ ӘДӘБИЯТ ЕЛЫ

3 **Болгар бабаларга ачык хат.** *Гәрәй Рәхим*

ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ

4 **Минтимер Шәймиев: «Яшәү мәгънәсе».** *Ләбиб Лерон әңгәмәсе*

ТАРИХИ МИРАС

18 **Кемнәр соң без — татарлар?** *Рабит Батулла*
25 **Керәшен евангелистлары.** *Николай Петров-Текин*
33 **Кем ул Морад мулла?** *Раиф Мәрданов*
38 **Чаллы-Чибәркүл арасы, Урал кичеп барасы.** *Людмила Белоусова*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

43 **Сүз һәм сурәт.** *Рәдиф Гаташ*

ҖИҢҮ — 70!

44 **Кара генерал.** *Рәис Зарипов*
53 **Җиңү алып килгән татар генералы.** *Александр Филиппов*
60 **Язылмаган кыйсса.** *Камил Кәримов*
62 **Албай төбәгенең биш батыры.** *Шаһинур Мостафин*

ӘДӘБИ МИРАС

66 **Кутадгу билик (Котайткыч белем).** *Йосыф Баласагуни*
72 **Кирпеч ясаучы Шапур һәм Хуҗа Мозаффар хикәяте.**
77 **Ачы тәҗрибә авазы.** *Габдулла Тукай*
78 **Атнабай канаты астында.** *Марат Кәбиров*
82 **Әнгам Атнабаев шигырьләре**
84 **Бер сүздән тора дөнья…** *Рүзәл Мөхәммәтша*
88 **Тукай энциклопедиясе.** *Алия Мөбарәкшина*

СӘНГАТИ МИРАС

90 **Күңел ташкыны.** *Аида Алмазова*

ХӘТЕР САГЫНДА

95 **Калфак.** *Руфия Мөхетдинова*
96 **«Буа эше»** *Әмир Камалов, Ислам Әхмәтҗанов*

ТЕЛ КҮРКЕ — СҮЗ

103 **Миллият сүзлеге.** *Адлер Тимергалин*
106 **Теле барның — иле бар!** *Рөстәм Акъегет*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

112 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1915 елның март ае.** *Ленар Гобәйдуллин*

ШАЯН МИРАС

116 **«Тынгысыз каләм» битләреннән**

119 **Мирасворд**
120 **«Безнең мирас» елъязмасы. Март**

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары-җаваплы сәркатип
Марат Закиров
(Марат Закир)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр Комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары — ТР фән һәм мәгариф министры)
Фәрит Шаһиәхмәтов
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
Рүзәл Мөхәммәтшин
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы,
2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

Заказ №О-527. Тираж — 1601 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 3.03.2015
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Михаил Козловский, Нурсөя Шәйдуллина, Солтан Исхаков һәм Ленар Гобәйдуллин төшергән, Абдулла Дубин, авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Тышлыкның 1 нче битендә — «Исемсез» (фрагмент). 2008 ел. Киндер, майлы буяу. *И.Максимов эше*

Гәрәй Рәхим

БОЛГАР БАБАЛАРГА АЧЫК ХАТ

Бу шигырь 1996 елның 23 гыйнвар төнендә Татарстанның Спас районы Болгар шәһәрендәге кунакханәдә язылды. Мин борынгы болгар бабаларыбыз яшәгән изге җирдә ялгызым төн үткәрдем...

Сез – Болгар бабалары,
Без – Болгар балалары.
Без бит тарих чылбырында
Бәйлелик гына бары.

Сез – Болгарның юл башы,
Ә без – аның дәвамы.
Сездән өлге алабыз без
Һәм дә рухи дәваны.

Арабызда зур чорлар,
Әмма уртак ич җырлар!
Сездән безгә мирас булып
Калган Иделләр, кырлар.

Болыннарда сез дә күргән
Шул ук чәчәкләр үсә.
Безнең битләрне иркәләп,
Болгар җилләре исә.

Кадерлибез сезнең куллар
Корган Болгар оясын.
Таң белән каршы алабыз
Изге Болгар кояшын.

Кемнәр килгән, кемнәр киткән –
Гасыр артыннан гасыр.
Ята милләт маңгаена
Тарих сызган күпме сыр?!

Изге Болгар изгелеге
Иманыбыз күгендә.
Сез табынган Тәңребезне
Олылыйбыз бүген дә.

Без мәҗүси... Без мөселман...
Кем сызган аермасын?!
Ходаем ата йортыннан –
Болгардан аермасын.

Без Болгарның бөеклеген
Саклаган хәлдә генә
Азатлык яулый алабыз
Татарстан иленә.

Сез – Болгар бабалары,
Без – аның балалары.
Бөтенебез бер чылбырның
Тарихи боҗралары.

ЯШӘҮ МӘГЪНӘСЕ

(Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе
МИНТИМЕР ШӘРИП УЛЫ ШӘЙМИЕВ
белән «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон әңгәмәсе)



«КЕШЕНЕ ӨМЕТ-ОМТЫЛЫШ ЯШӘТӘ»

— Минтимер Шәрипович, шундый төшенчә бар: яшәү мәгънәсе. Бу хакта философлар, әдипләр, дин әһелләре тарафыннан күпме трактат, шигъри әсәр һәм тәгълимат язылгандыр — моны бер Ходай гына белә. Сезнең дә бу хакта уйланганыгыз бардыр: чыннан да, яшәү мәгънәсе нидә? Без ни өчен яшибез?

— Сез миңа соравыгыз белән бергә җавап та бирдегез инде: аны бер Ходай гына белә, диеп. Чынлап та, барысын да бер Ходай үзе генә белә. Миңа калса, кеше үз язмышын, нигездә, үзе хәл итә: үзенең эшчәнлеге, үз-үзен тотышы белән, җәмгыятьтә тоткан урыны, җирдә яшәү рәвеше белән.

Яшәү мәгънәсе, дигәндә... Әйтәләр бит: кеше үзенә охшаган, үзе кебек нәсел калдырыр, дип. Әгәр дә шулай булмаса, кешелек дөньясы яшәмәс тә иде. Бездән генә тора торган нәрсә түгел бу, чыннан да, Аллаһы Тәгалә эше. Ходай шулай биргән кешегә. Аны парлы иткән. Кеше парсыз булса, тормыш дәвам итмәс иде, кешелек дөньясы алга бармас иде. Кешелек кенә түгел, гомумән, бөтен тереклек. Нинди генә җанварны, кош-кортны алма — барысы да нәсел калдыру өчен туа. Шуның өчен азык эзлиләр, гөрләшеп яшәргә, көн күрергә тырышалар. Шул ук вакытта, үзенә ошаган пар өчен җанфәрманга көрәшәләр.

Сүз дә юк, ул шулай булырга тиеш тә. Югыйсә, тереклек дөньясы үз-үзен юкка чыгарыр иде. Ә бит табигать кануны буенча көчлеләр яшәргә, көчлеләр нәсел калдырырга тиеш. Без, кешеләр, яшәр өчен, әйткәнемчә, үзебезгә лаеклы нәсел-ыру калдырыр өчен дөньяга килгән. Аны бурыч дип тә аңларга була, язмыш дип тә атарга була. Әгәр дә шушы бурычын үтәмәсә, тереклек дөньясы да, кешелек дөньясы да тулы булмас иде. Менә шунда инде аның мәгънәсе. Икенче мәсьәлә: балаң туган икән, аны ничек иттереп тәрбияләргә, ничек тормышка яраклаштырырга — болары инде көндәлек эшләр.

Белеп-күреп торабыз: кемнеңдер баласы туа, ә ул аны ташлап китә. Моны берничек тә кабул итеп булмый. Хайван да болай кыланмый, дип әйтәләр бит әле. Дөрестән дә, хайваннар моны эшләми. Ни кызганыч, кешеләр арасында андый хәлләр бар. Әле бүген генә телевизордан, радиодан сөйләп торалар: балаларын ташлап киткән аталардан ничек алимент алырга дип баш ваталар — башка чаралар белән беррәттән, машина йөртү хокукыннан мәхрүм итәргә кирәк, дип тә тәкъдим итәләр. Закон нигезендә. Кешене үз баласын карарга ничек мәҗбүр итәргә белмиләр. Ничек инде үз балаңнан, үзеңнән яралган нарасыйдан баш тартырга мөмкин? Ничек кенә аңлатырга теләмәсеннәр моны, бу — бернинди табигать кануннарына да, әхлак кануннарына да туры килми торган гамәл. Әйе, ир затының берничә хатын-кызы булырга мөмкин. Бу күренеш ир-ат сугышчыларның күпләп сугыш корбаны булган чорлардан килә. Бу хәл тол хатын-кызларның үзләрен һәм балаларын тәрбия итү белән бәйләнгән. Ә менә тудырган баласын карамау — монысы табигатьтә юк нәрсә, моны берничек тә аңлатып булмый. Дөньяга килүнең төп сәбәбе тормышка ашмаган, синең тарафтан берни эшләнмәгән икән, бу инде — бәхетсезлек.

Берничә ел элек Америка галимнәренә Нобель премиясе бирделәр. Фәнни хезмәтләренең темасы — кешенең барлыкка килүе турында. Кем ул — кеше? Ничек итеп дөньяга килә? Алар моны ихтималлык теориясенә (теория вероятности) кайтарып калдырды. Мин, гомумән, Нобель премиясе бирелгән эшләрне карап барырга, азмыкүпме дәрәҗәдә хәбәрдар булырга тырышам. Бу — бик фәлсәфи мәсьәлә. Менә сез бар, мин бар, бүтәннәр бар. Якты дөньяга килгәнбез. Ә бит минем кебек, сезнең кебек миллионнарга, миллиардларга ул бәхет ирешмәгән.

Хак булса, спермада сперматозоидлар саны миллионнар белән санала. Миллионлаган сперматозоид хатын-кызның җенесе аша үтә. Әмма фәкать берсе генә кабул итеп алына, шуннан кеше барлыкка килә. Бар сперматозоид та бертигез хокуклы, ләкин берсенә генә шулай кушылу тәти. Шул сәбәпле без дөньяга килгәнбез. Уйлап карасаң, кешенең барлыкка килүе — ул иң зур бәхет. Моны аңлау да, аңлату да җиңел түгел. Моның өчен син Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтле булырга тиеш. Дога кыласыңмы, корбан чаласыңмы, гомереңне дингә багышлыйсыңмы… Кайсы җирдә-илдә яшәвеңә, кайсы расадан булуыңа карамастан, бер Аллага табынырга тиеш. Башкача була алмый. Инде дин ягыннан карасаң…

Дин, минем фикеремчә, кешеләр өстеннән хакимлек итәр өчен барлыкка килгән. Юкса, бер генә дин булыр иде,

Минтимер Шәймиев һәм ЮНЕСКОның Генераль директоры Ирина Бокова. 20 август, 2014 ел, Болгар

Борынгы Болгар җирендә

«Борынгы Болгар һәм Зөя-утрау: үткәне һәм киләчәге» дип аталган күргәзмәне ачу вакытында. 13 февраль, 2015 ел

Зөя-утрау

ә алар берничә бит?! Башкача уйласаң, бу шул ук фәнни ихтималлык теориясе ләбаса! Һәм киресенчә: ихтималлык теориясе белән килешмибез икән, бу Аллаһы Тәгаләгә табынуны, аны зурлауны тагын да көчәйтә. Башка җавап юк.

Минем үземә гомерем буенча тынычлык бирми торган сораулар бар: мәсәлән, югары математикада чиксез кечкенә һәм чиксез олы зурлыклар бар. Фән көннән-көн алга бара. Без укыганда әүвәл молекула, молекуладан атомнар китә иде. Ә хәзер атомның өлешләрен өйрәнәләр: һәрбер өлеш бүленә дә бүленә, бүленә дә бүленә. Һәр бүленгәненең үз орбитасы, үз энергиясе бар, бүленеш процессы чиксез бара. Моның чиге бар, дип бүген беркем дә әйтә алмый. Биниһая нәни чиксезлек нольгә омтыла, әмма ул барыбер ноль түгел. Менә шуннан соң инде уйлана башлыйсың. Моның чиге булмагач, фән аны танып бетерә алырмы, юкмы? Кеше үзеннән-үзе җавап эзли. Ә җавап табылмый, бары тик ышанырга гына кала.

— Бу уңайдан Станислав Лем дигән поляк язучысының мондый гыйбарәсе бар: «Хакыйкатьнең төбенә төшеп җиттем дигән идем, анда да йозаклы ишек тора».

— Дөрес әйтә. Ни өчен шулай әйтә? Чынлап та, фән өлкәсендә тикшеренү алып бара торган бик зур галимнәр дә шушы тупикка килеп терәлә. Галимнәр арасында дуализм дигән фәлсәфи төшенчә бар. Гомер буе эзләнәләр, һаман барып терәләләр шул чиксезлеккә. Шул ук вакытта, биниһая зур чиксезлек төшенчәсе бар. Йөзәр мең галактиканы күз алдына китерегез сез. Әле үзебезнең галактиканы гына да күзаллап бетерә алмыйбыз. Менә — чиксезлек. Ничек аңа җавап табып бетерергә кирәк? Шуңа күрә, бу дөньяга килүебезгә без рәхмәтле булырга тиеш, тормышның табигатьтән килгән, вакыт үзе биргән төшенчәләре нигезендә уйлап карасаң, бу — өлешеңә тигән көмешең. Көмеш кенә булса инде. Кешелекнең дөньяда ничә миллиард еллар яшәвенә карамастан, күп сорауларга әле дә җавап таба алганы юк.

Тормыш ул — бер мизгел генә. Кеше күпме яшәсә дә, Аллага шөкер, инде вакыт җитте, дисә дә, күңелендә һәрвакыт яшәү өмете белән яши. Кеше нинди генә картлыкка җитмәсен, ничә яшькә кадәр яшәмәсен, аның тормышы барыбер бер мизгел генә ул. Ун ел яшәсә дә, йөз ел яшәсә дә — бары бер мизгел. Ә чыннан да, уйлап карасаң, галәм, вакыт дигән төшенчәләр бар бит фәндә. Чыннан да, алар белән янәшә кеше гомере — мизгел генә. Шуңа күрә, безнең тууның мәгънәсе бар. Һәркем уйланып, үз фикере җитмәсә, башкалардан өйрәнеп, аңлап, яшәүнең мәгънәсенә инанырга тиештер. Кем һәм нәрсә белән шөгыльләнмәсен, бу якты дөньяга килүенең мәгънәсе, аны аңлату рәвеше шушылайрак, дип саныйм мин. Ихтимал, аның башка җаваплары да бардыр, белмим. Әмма уйлана башласаң... Нәкъ менә шушы уй яшәтә дә кешене. Әйтәләр бит: әгәр кеше бу дөньядан китәсе көнен алдан ук белеп торса, ул яши алмас иде. Өмет-омтылыш яшәтә кешене. Менә шуннан уйлыйсың: ничек корылган бу дөнья, аны нинди көч яшәтә?! Кешеләр генә кормаган бит дөньяны. Калган барысы да — аңларга тырышу. Зур галимнәрме ул, кечкенә галимнәрме, гап-гади кешеләрме — барысында да шуны аңларга омтылыш бар.

«МАКСАТ КУЕП КЫНА ТАЛАНТЛЫ БУЛЫП БУЛМЫЙ»

— Атаклы шагыйребез Хәсән Туфанның «Талантлы син, Кеше туганым» дигән канатлы сүзләрен искә төшерик әле. Әдипнең бу сүзләрен бераз үзгәртеп, «Талантлы син, Татар кардәшем!» дисәм, Сездә нинди хистойгылар, уй-фикерләр уяныр икән?

— Кем генә әйтсә дә, иң мөһиме — яхшы мәгънәле сүзгә колак салу, игътибарлы булу кирәк. Әлбәттә, бөтен кеше дә акыллы сүзләрнең мәгънәсенә

аңлап бетермәскә мөмкин. Гомумән, хәзерге заманда шигырьләр, чәчмә әсәрләр, әйтемнәр аша күп мәгълүмат, бик күп тирән фикерләр җиткереп була кешегә. Җиткерергә кирәк тә. Ни өчен әйтәм? Чөнки инде байтактан ук мин, телевизордан шигырьләр, күләмле язмалардан өзекләр укырга кирәк, дип әйтә килдем. Ул экраннан бөтен бер поэманы уку дигән сүз түгел. Яхшы сүз, мәгънәле сүз барыбер үзенә җәлеп итә. Безнең телевидение тәкъдимне ишетте, кабул итеп алды. Төпле фикерне, мәгънәле, акыллы сүзләрне кешегә җиткерүдә, минемчә, шигырьнең роле, әһәмияте искиткеч зур. Кайчак уйлап куясың: дөнья, тормыш турында әниләр нәрсә әйтә иде, әтиләр нәрсә әйтә иде? Авырлыкка юлыксаң, нәрсәдер көтәсең, көткәнең акланмый. Шул мизгелләрдә барыбер дә кешене тынычландыра торган сүзләр табыла. Бар андый сүзләр, бар. Ә бит ул сүзләр гасырдан-гасырга килгән…

«Талантлы син, Татар кардәшем!..» Моңа җавап бирү җиңелләрдән түгел. Чөнки һәр кешенең — үз язмышы, үз дөньясы. Һәркем үзенчә талантлы. Күп кешенең таланты ачылмыйча кала, дип дөрес әйтәләр. Андыйлар өчен шартлар туып җитмиме? Билгесез. Әгәр дә һәр кешенең таланты ачыла торган булса, дөнья да башкачарак булыр иде.

Әйтик, кем нәрсәгә дә булса сәләтле һәм тормышында аңа нәкъ шуның белән шөгыльләнергә туры килә икән — табигатьтән килгән сәләте ачыла. Әлбәттә, әгәр дә тырыш булса, көч куйса. Руслар әйтә бит: «Талант — это труд», — дип. Дөрестән дә, талант — зур хезмәт бит! Мич башында ятып кына, мин талантлы, дип әйтеп кенә әллә ни эш кырып булмый. Дөрес, мич башында ятып, горурлыгыңнан шартларга мөмкин. «Бүрәнә аркылы бүре куу» дигән гыйбарә бар бит әле. Тик торганнан гына әйтелгән сүз түгел бу, ул сүздә бик тирән мәгънә ята. Эшне «кулыңа тотып», тырышып эшләп карамыйча, үзеңнең нәрсәгә сәләтле икәнеңне ачыклау мөмкин түгел. Шунысы да бар: талантның ачылып бетә алмавы күп кешеләрнең язмышына кире йогынты ясый. Чөнки ул һаман үзен эзләргә-җәберләргә мәҗбүр.

«БӘХЕТ УЛ — КҮҢЕЛ ХАЛӘТЕ»

— Бар шундый кешеләр, чыннан да, без андыйларны укыганда ук сизә идек: йөздән артык бала — студентлар, укыйбыз, кемнең нәрсәгә сәләтле икәнен күрәбез, бу бигрәк тә бер-береңбелән аралашканда сизелә — кемгә нинди фән җиңелрәк бирелә. Бик катлаулы фәннәрне дә бик җиңел үзләштерә торган егетләр бар, кемгәдер кайсыдыр фән бик авыр бирелә иде. Ул баланың бу тармакка дөрес эләкмәгәнен күрәсең. Табигатьтән нәрсәгә сәләтле, уй-фикере ничек корылган кешенең — шуны белү мөһим. Кемдәдер математик акыл югары, кемдер гуманитар фәннәргә һәвәс. Мисалга музыкантларны алыйк. Көй язмыйча булдыра алмый ул. Әле ярый язып, җиренә җиткерергә мөмкинлекләре булса, ә каядыр барып терәлә торган булса, тупик килеп чыкса? Кая куеп бетерергә кирәк ул табигатьтән килгән талантны, мөмкинлекне? Талант хезмәт аша гына күренә ул. Шуңа күрә, менә мин шундый идем, менә мин шундый булдым, дип әйтү бәхәссез фикер түгел. Язмышы шулай килеп чыккан. Мәсәлән, минем бертуган абыем көндәлек эшне ныграк сөючән, бар яктан булган, акыллы, кешелекле иде. Авыл җирендә эш җитәрлек, тавык чүпләп бетерә торган түгел. Ул гел эшләде, шуның белән миңа күбрәк укырга мөмкинлек бирде. Бу бала укуга бирелеп китте, диләр. Укый алмаганының да сәләте аз дигән сүз түгел.

Миннән еш кына сорыйлар: «Әйтегез әле: нәрсә ул бәхет?» Минем моңа үз карашым, үз фикерем бар. Бар кешедә дә бертөрле бәхет була алмый. Мин бәхетне кешенең күңел халәте дип саныйм. Әгәр дә ул аны канәгатьләндерә икән — бәхет шул. Бүгенге көндә яраткан эшем бар, гаиләмдә барысы да

Болгардагы
Ак мәчет

Мәүлед бәйрәме тантанасыннан бер күренеш. 2015 ел

әйбәт, тормышым мине канәгатьләндерә, дип саныйм икән — бәхет шул. Нәрсәдер борчый икән, үзеңне таба алмагансың икән, моны, киресенчә, бәхетсезлек дип санарга була. Әгәр дә үзем хакында әйтсәм: миңа бу төшенчә турында уйларга һич туры килмәде. Институт тәмамлаганнан соң эшли башлаган идем... Һаман эш тә эш, эш тә эш. Әйе, яраткан гаиләң — янында, эшең бара, сине күреп торалар, каядыр тагын күтәрәләр, тагын күтәрәләр... Тормышымда, эшемдә минем бер мәртәбә дә түбән төшкәнем булмады. Тормышның, яшәүнең мәгънәсе хакында олыгая төшкәч күбрәк уйлый башлыйсың икән.

«ТЕЛ БУЛМАСА, ХАЛЫК ЮК»

— Хәзерге мультимедиа, нанотехнология заманында Минтимер Шәрип улының өстәлендә һәрдаим укый-карый торган нинди китап бар икән? Гомумән, китап, татар китабы, классик әдипләребез хакында Минтимер Шәрип улы ни уйлый?

— Ярый әле Болгарны, Зөя-утрауны торгызырга алындым дип еш кына куанып куям. Бу — минем күптәнге хыялым иде. Хәзер минем эш бүлмәсенә кереп карасак, анда тау-тау өелгән китаплар күрербез. Беркая куя алмыйм. Яхшы китап килеп эләгә, шуны карап чыкмыйча, китапханәгә бирергә ихтыяр көчем җитми. Галим хезмәте булсынмы ул, матур әдәбиятмы... Элек бернәрсәгә вакыт юк иде. Шушы акыллы, тарихи китапларны укырга мөмкинлек тууына шатланып бетә алмыйм. Нинди генә акыллы фикерләр тумаган кешелек дөньясында! Ярый әле аларны кешегә җиткерү ысуллары бар. Элек язып калдырганнар. Хәзер инде башка технологияләр бар. Мирас, дибез. Мирасны калдыра да белергә кирәк!

Үзе бер бәхет бит ул — уку! Шуңа канатланып йөрисең. Олыгаеп беткәнсең, ә канатланып йөрисең. Чынлап әйтәм: шул яшәтә кешене. Ходай күпме биргәндер яшәргә... Күпме генә бирмәсен, күңелгә хуш килә торган эш яшәргә хозурлык бирә. Ярый әле бу эш белән шөгыльләнгәнмен дип шатланып куясың.

Китап уку дигәннән... Тормыш ничек кенә авыр булмасын, без яшь чакта, татар авылында, татар булып туу-үсү, ун ел буе татар мәктәбендә уку — туган телгә, татар китабына гомерлек мәхәббәт уятты. Мин моны олы бәхет дип саныйм. Аның авырлыклары да булды. Чөнки 10

нчы классны татарча тәмамлап, Казанга килеп, имтиханнарны рус телендә тапшырырга кирәк иде. Монда тагын язмыш төшенчәсе килеп баса... Нинди яхшы укыган егетләр бар иде! Күбесе, институтка керә алмыйча, кире кайтып китте. Чи татарча укып, башкалага килеп, рус теленнән имтихан бирдек, изложение яздык. Менә нинди дискриминацияләр аша уздык. Татар телен, ана телен онытырга тырышу омтылышы интеллигенция арасында да бар иде. Мин моны институтка керү имтиханнарын биргәндә күзәттем. Татар милләтеннән булган кайбер укытучылар безнең белемебез барлыгын күрә торып, рус телен начар белгән өчен газаплыйлар иде. Менә шундый язмыш. Халкыбыз язмышы иде. Яшь чакларда укыганнар хәтердән дә, күңелдән дә китми. Ә элек бик күп укыла иде. Мин үзем укырга бик ярата идем. Иң четереклесе: өйдәгеләрнең, керосинны бетерәсең дип тиргәүләре иде. Укыр өчен мин башка әйбер уйлап таптым. Яңа барлыкка килә башлаган радиоалгычлар зур батареялар белән эшли иде. Мин аларны өч ваттлы лампочкага тоташтырдым да, укыр өчен яктылык булдырдым үземә. Әнкәй мәрхүмә сөенә иде: «И булдырасың, улым, керосинны саклыйсың», — диеп. Төне буе укыйм да, иртән батареяларны үз урынына куям. Берникадәр вакыттан узгач, әткәй аптырады: нигә бу радио сөйләми башлады соң? Әле күптән түгел генә, шатлана-шатлана алып кайткан иде, югыйсә. Мин дәшмәдем инде...

Район үзәге китапханәсендә булган әдәби китапларның барысын да укып бетердем. Бәлкем безнең китапханә ул кадәр зур да булмагандыр. Китапны алганда ук кайчан китерергә кирәклеген язып куялар. Шул көнне бу китапны башка укучы килеп алып китәргә тиеш. Менә омтылыш ничек иде китапка! Буранмы, түгелме, син китапны вакытында тапшырырга тиешле. Безнең авыл райүзәккә — Пучыга якын иде. Ара чакрым ярым булгандыр. Һава торышына карап тормыйсың, китапны куеныңа кыстырасың да яңгыр, кар тимәсен, дип чыгып китәсең. Алып барып тапшырасың. Кави Нәҗминең, Габдрахман Әпсәләмовның, Гомәр Бәшировның бөтен әсәрләрен, Галиәсгар Камалның, Шәриф Камалның, Таҗи Гыйззәтнең һәм башка драматургларның бөтен пьесаларын укыган малай мин. Без Тукайның, Такташның күп шигырьләрен яттан сөйли идек. Ул Мокамайларны... Әле кем уздыра, әле кем күбрәк ятлаган, дип узыша-узыша сөйлибез. Әти-әниләрне мәктәпкә чакырабыз. Алар балаларының чыгыш ясавына, нәрсәгәдер сәләтле булуына шатлана иде, бу — ата-ана өчен чиксез куаныч иде. Ятлау — әдәбиятны өйрәнүнең бер ысулы. Әле ятларга еш кына китаплары җитми иде. Бер-беребезгә биреп, язып алып ятлый торган идек. Ул чакларда имтиханнар да күп иде бит. Җиденче сыйныфтан башлап, ел саен алтышар, җидешәр имтихан! Шуннан соң ничек белем кермәсен ди!

Яшьлектә укыган әсәрләр сине гомер буе озата бара. Тирән фикерле тарихи әсәрләр ул чагында безнең кулга килеп эләкми иде. Мин аларны хәзер укыйм. Хәзер, нигездә, тарихи китаплар укыйм. Болгар белән Зөя калалары истәлекләренә ныклап тотындык. Үзебезнең татар галимнәренең язган әсәрләрен бик кызыксынып укыйм. Дөрес, кайчагында кабатланулар да була. Анысы инде галимнең нинди фәнни мәктәпкә каравына мөнәсәбәтле. Фаяз Хуҗинның татарча язылган тикшеренүләре бар. Шуларны бик яратып укыдым. ТӘһСИнең хезмәтләре бик күп. Борынгы әсәрләрне дә тәрҗемә итәләр, аларга яңа тормыш өрәләр. Бу — искиткеч мәгънәле, файдалы эш, дип саныйм. Тарих институтыбыз, Аллага шөкер, үзебезнең Фәннәр Академиябез бар. Академияне оештырганда, анда физика-химия өлкәсендә фундаменталь ачышлар булыр дип артык зур максат та куймаган идек. Иң мөһиме: үзебезнең тарихыбызны, әдәбиятыбызны өйрәнү, үзебезнең галимнәргә, зыялылар-

га мөмкинлекләр тудыру иде. Шул ук вакытта без бит Декларация кабул иттек, вәкаләтләребезне бөтен дөнья, Рәсәй алдында игълан иттек. Шуңа күрә Фәннәр Академиясе — дәүләтчелегебезне раслап торучы бер дәлил ул. Хәзерге вакытта күрәбез: дөрес эшләнгән эшләр алар. Ул чакта андый мәсьәләләрне кызу тоту кирәк иде.

Хәзер дә китаплар гел укылмый дип әйтмәс идем. Еш кына истәлекләр чыга. Русча язылганнары, татарчалары... Бергә эшләгән кешеләр турында. Аларны сагынасың да, юксынасың да... Андый китапларны язуда еш кына үзем дә катнашам. Белгән кешеләр хакында сөйләп-язып бирәм. Халкыбыз өчен зур хезмәт куйган шәхесләр белән бергә эшләргә туры килде. Алар турында укыйм. Барысына вакыт кирәк... Шигырьләр, әйтемнәр, Шәүкәт Галиевнең юмористик гыйбарәләре бик ошый.

Мин «Чаян» журналын бик яратып укый идем. Яшьрәк чакта, министр булып эшләгәндә һәр санын яздырып алып бара идем. Алгач, карыйсы, тапкыр, мәгънәле мәзәк укыйсы килә. Безнең язучыларны гына түгел, гомумән, дөнья язучыларының китапларын да карап, укып барырга тырыштым. Ни кызганыч, хәзер күләмле әсәрләр укырга вакыт юк. Шулай да, китаплар белән танышып бару ысулларын табарга кирәк. «Син укы!» дип әйтеп кенә китап укытып булмый балага. Баланы китап укырга мәктәптә үк өйрәтергә кирәк.

Яшь чакта дүрт-биш тел өйрәнү — олыгайгач бер тел өйрәнүгә караганда җиңелрәк. Баланың мөмкинлеге чиксез аның. Ана карынында ук компьютерга өйрәнеп туа бит алар хәзер. Мәгълүматны губка кебек үзенә сеңдереп бара. Безнең әле кечкенә баланың мөмкинлекләрен тулысынча файдалана алганыбыз юк. Ә бит нәкъ менә кечкенә чагын файдаланырга кирәк. Әгәр бала нәни чактан ук татар телен яхшылап өйрәнсә, ул аның үз гомеренә җитә, аннан соң ни генә укыса да, кечкенәдән сеңгән тел онытылмый. Татар теле — дәүләт теле бит.

— Бу мәсьәләдә гаилә дә җаваплыдыр, дип уйлыйм мин.

— Гаиләнең дә төрлесе бар. Дөнья мәшәкатьләре күп. Барлык сабыйлар да балалар бакчаларында тәрбияләнсен өчен, бөтен мөмкинлекләрне тудырырга тырышабыз бит. Президентыбыз Рөстәм Нургалиевич Миңнеханов та моны

контрольдә тота: күпме балалар бакчалары, мәктәпләр төзелә. Болар — шушы ихтыяҗдан чыгып эшләнә торган эшләр. Аның барыбер дә уңай нәтиҗәсе була.

Мисал өчен, «Башваткыч» тапшыруы. Әгәр төптән уйлап карасаң, экран каршына беркем беркемне көчләп утыртмый, ә мин аны гел карап барам. Шул ук вакытта уйлыйм: тапшыру үзенә җәлеп итә бит! Менә шундый ысуллар кирәк. Сүз дә юк, сабыйларга балалар бакчасында, мәктәпләрдә татар телен укытып була, укытырга кирәк тә! Күпме тырыштык! Көрәш һаман бара бит бу мәсьәләдә. Акрынлап үз эшебезне эшлибез. Бу эшләр халкыбызның мәнфәгатеннән чыгып эшләнә. Хәрәкәт кирәк. Хәрәкәтсез булмый. Дөрес, ата-анадан күп нәрсә тора. Ләкин ата-аналарның да телне юньләп үзләштерә алмый калганнары күп, катнаш гаиләләр бихисап. «Башваткыч» тапшыруы шикелле, барлык ысулларны кулланырга кирәк. Нинди генә адым ясасак та, зур адыммы ул, кечкенә адыммы — барысы да файдага булачак. Соңгы акытта ТНВ телеканалында кызыклы тапшырулар барлыка килде. Хәзер сабыйлар өчен бик матур дәреслекләр чыга. Балалар бакчаларында тәрбияләнә торганнары өчен дә рәсемле китаплар бар.

Ничек кенә авыр булмасын, бу юнәлештә хәрәкәт итәбез икән, алга атлаган саен мөмкинлек тә арта бара. Үзгәртеп кору чорында комачаулыклар искиткеч көчле иде бит. Аның барысын да сөйләп бетереп булмый. Рәсәй министрлары белән кискен ачуланышуга чаклы барып җиткән вакытлар булды. Үз эшебезне үзебезгә эшләргә кирәк безгә. Тел булмаса, халык юк.

«МИН БЕРКЕМНЕ ДӘ ГАЕПЛӘМИМ»

— Татар халкы «Дөнья — куласа, әйләнә дә бер баса» ди. Сезнең тормышта шушы әйтемне искә төшергән хәл-вакыйгалар булдымы?

— Әйтеме матур аның. Мин турыдан-туры алай дип әйтмәс идем. Мөгаен, балачакта күргәннәрем шушы «әйләнә дә бер баса»га туры киләдер. Безнекеләр хәлле тормышта яшәгән. Аларны «раскулачивать» та иткәннәр. Ләкин сөрмәгәннәр. Шул вакытта йортларын, бөтен милекләрен тартып алу сәбәпле, чит кешеләрдә яшәргә мәҗбүр иткәннәр. Авылдашларның бабайга карата хөрмәте зур булган. Кемдер яшәргә урын биргән, арада, тынычлана алмыйча, барып әләкләп йөреп, безнекеләргә тагын да начаррак булсын дип йөрүче кешеләре дә очраган. Кайчагында әти «кулыннан эш килмәгән шушы гаилә һаман шулай кеше өстеннән әләкләп йөрүдән туктый алмый» дип әйткәләп алгалый иде. Бу нәселдән-нәселгә бара. Бераздан, тормыш үзгәреп китеп, әтине колхоз рәисе итеп сайлап куялар. «Әйләнә дә бер баса» шушы була инде. Күз алдына китереп булмаслык хәл: кулак малае — колхоз рәисе! Ул бит яшь чакта күпме таланган бала! Минем әни мулла нәселеннән. Әни «мәчет манарасын кискән, аны аударган кешеләрнең язмышлары матур тәмамланмады», — дип әйтә торган иде.

«Дөнья — куласа...»лар көндәлек тормышта еш булгалады инде ул. Мин беркемне дә гаепләмим. Минем ул яктан күңел киң, дип әйтимме... Кеше кабахәт булмаса, аның кылган ялгышларын кичерергә кирәк. Нәфрәт, ачу саклау җитәкче кешегә бигрәк тә килешми.

— Сезнең Лев Овруцкий белән булган әңгәмәгездә дә бу фикер сизелә иде.

— Сизеләдер. Чыннан да шулай ул. Ул шулай булырга тиеш, дип саныйм мин. Әгәр дә зур эштә икәнсең, кешеләр язмышы синнән тора икән, кара эчле булып, кеше язмышын хәл итәсең икән — бу җинаятькә тиң. Андый нәрсә булырга тиеш түгел.

— Сез, таш атканга аш ат, дип җавап бирәсез инде...

— Бик дөрес. Чынлап та, кешеләрнең язмышын син хәл иткәндә, ачу тоту, нәфрәтләнү булырга тиеш түгел. Әти дә гел җитәкче эшләрдә эшләде, бик кешелекле иде. Авыл халкына

рәхмәтле дә булгандыр инде. Себергә сөрелмәгәннәре өчен.

«БЕЗНЕҢ ҮЗ ЮЛЫБЫЗ БАР»

— Татарстаныбызда — кыска гына вакыт арасында — күпме хыяллаНЫП та гомер булмастай тоелган нәрсәләргә ирешелде. Безгә Татарстан, Казан турында ишетеп кенә белгән кунаклар еш килә. Элек булып киткәннәр исә, Казан nык үзгәргән, Казан танырлык түгел, диләр...

— Казанны гына түгел, башка шәһәрләребезне күргәч, мин үзем дә гаҗәпләнеп куям. Зур булмаган район үзәкләрен карагыз: мәсәлән, Әтнәне, Кама Тамагын, Чирмешәнне, Әлкине, Болгарны... Мин бик еш вертолетта очам. Элек салам түбә шиферга алышынганын күреп шатлана идек, аннары алар калайга алыштырылды, калайдан соң профнастилга күчелде. Кирпеч йортларның барлыкка килгәнен күреп торабыз. Әйе, бер кеше гомерендә тормыш нык үзгәрде. Мин Аллага шөкер, дип әйтер идем. Безнең үзгәрешләр бик зур. Иң зур казанышыбыз: үзгәртеп кору елларында мөстәкыйльлек турында Декларация кабул иткәч, халыкның үзаңы нык үсте, без үзебезнең милләтебезне нык күтәрдек. Татар халкына караш үзгәрде. Нигездә үзгәрде. Көндәлек тормышта аңа бәһа биреп бетереп булмый. Үзгәртеп кору чорында узган юлыбыз халкыбызның дәрәҗәсен күтәрде. Мин моны хәлиткеч тарихи чор, дип атар идем. Шушы чорда үзебезнең хокукларыбызны яклап, авыз тутырып әйттек. Республикабыз сәясәте, икътисады башкаларга үрнәк булып тора. Ул башкаларга комачаулый торган юл түгел. Без демократик җәмгыять төзергә телибез. Безнең әле андый җәмгыять төзегәнебез, андый җәмгыятьтә яшәгәнебез булмады. Бигрәк тә Рәсәй кебек иң катлаулы федераль дәүләт кысаларында. Шулар турында әйткәч, Мәскәүдә дә аңлый башлаганнар иде. Шуңа күрә, кайчагында безгә гаеп ташлаганда, шикләнүләр булган вакытта, саллы дәлилләр китереп, уртак тел табып киләбез. Без дә әйтмәсәк, кем әйтергә тиеш, дип әйтәбез. Беркемгә дә бернинди дә кагыйдәләр язып куелмаган. Сүз дә юк, бар шундый егетләр — татар җанлы егетләр, язмышыбыз, халкыбыз турында уйлап җан аткан егетләр. Бу һәр милләткә хас.

Болгарга тотыну, Болгар истәлекләрен торгызу — изге җиребезне күтәрү, халыкка кайтару ул. Исламны бит безнең борынгы бабалар, дәүләт дине буларак, руслар православие диненнән алганчы ук кабул иткәннәр. Болгарны төзекләндерү — тирәнтен уйланган эш ул. Әгәр дә ул эшне үзебез эшләмәсәк, үз хәтеребезне яңартмасак, үз мирасыбызны аякка бастырмасак, дөньяга күрсәтмәсәк, бу эшләрне читләр килеп эшләмәс.

«ЗӨЯНЕҢ ТАРИХЫ ФАҖИГАЛЕ»

— Изге Болгар... Минтимер ага, Сезнең соңгы елларда кылган эшгамәлләрегезнең күркәм нәтиҗәсен күргәч, һәркемнең «үз Болгары» булырга тиеш, дигән фикергә киләсең... Әйтик, кемдер туган авылын яңартырга тели: иске йортларны, каралты-кураларны сүтә, яңаларын төзи, утлар, сулар керттерә, юлларга асфальт түшәтә... Мин моны да ул кешенең үз Болгары, дип атар идем.

— Үз Болгары? Дөрес әйтәсез. Үз кыйбласы... Кыйбла, бәлкем, бердер, әмма үз Болгары дип дөрес әйтәсез.

Хәер, Болгар, бер яктан караганда, безнең кыйбла да бит әле ул. Беренче мәртәбә ислам дине шунда кабул ителгән. Аннан гасырлар аркылы — Алтын Урда, Казан, Әстерхан, Себер ханлыклары аша хәзерге Рәсәй территориясенә ислам таралган. Бу — безнең тарих, безнең ата-бабаларыбыз эшләгән эш, безнең зур мирасыбыз. Биредә кемнән кем килеп чыкканын тикшерү максат түгел. Болар — бәхәсле әйберләр. Алты ай буе кар ята торган җирләрдә ислам диненең

таралуы — уникаль күренеш. Ислам динен тотучылар Рәсәйдә дә, СССР киңлекләрендә дә күп. Менә шушы дәрәҗәдә бер халык та аны күтәреп чыга алмады. Аның мәгънәсе тирән дип әйтер идем. Без бит Болгарны ЮНЕСКО исемлегенә кертүгә ирештек. Болгар — бөтендөнья хәзинәсе, бу ЮНЕСКО тарфыннан танылган, расланган факт. Болгарны ЮНЕСКОга кертү зур тарихи гамәл булды.

Без ике проектны алып барабыз: Болгарны һәм Зөяне. Һәр халыкның үз язмышы, үз тарихы. Кан да коелган, нәрсә генә булмаган, дәүләтчелекне югалтулар да булган. Бу — безнең тарих. Хәзерге вакытта Зөя-утрауда да зур эшләр бара. Бөтендөнья мирасы күзлегеннән караганда, без төп игътибарны Успенье соборына юнәлттек. Троица агач чиркәве буенча да тикшеренүләр бара. Баштагы мәгълүматлардан күренгәнчә, ул Идел буенда сакланып калган бердәнбер агач чиркәү дип санала иде. Хәзер башка чиркәүләр дә булуы мөмкин, дигән фаразлар бар. Хәзерге вакытта ул эшләрнең юнәлеше түбәндәгеләрдән гыйбарәт: ул чорларда нинди соборлар ничек төзелгән, нинди иконалар ничек эшләнгән, рәсемнәр ничек ясалган, кемнәр ясаган, нинди технология белән ясалган, бүгенге көнгә кадәр ничек сакланып калган — шуларны ачыклау. Менә шушыларга игътибар бирелә. Һәм, әйткәнемчә, төп игътибар менә шушы ике тарихи истәлеккә төшә.

Зөя утравының тарихын карасак, ул совет чорында нинди генә кабахәтлек күрмәгән. Анда бит ГУЛАГ булган! Безнең Хәсән Туфаныбыз да сөргенгә кадәр анда утырган. Биредә нинди генә зыялыларыбыз газап чикмәгән. Руслар да, чит ил кешеләре дә интеккән. Күпмесе шунда корбан булган. Без, бер фикергә килеп, Зөя-утрауда репрессия корбаннарына һәйкәл куйдык. Һич онытасым юк: бер хатын-кыз чыгыш ясады. Ул шунда туган бала. Төрмәдә туган. Әнисенең сөйләвенә караганда, төрмә начальнигы мәрхәмәтлерәк кеше булып, баланы анага имезергә биргәннәр. Шулай итеп бала исән калган. Анда бик күп кеше атып үтерелгән. Троцкий килеп, Казанны ак чехларга биргән өчен, кызылармеецларны сафка бастырып, һәр ун кешенең берсен аттырып үтерткән. Зөя-утрауда юләрләр хастаханәсе эшләгән, караучысыз, тәртипсез балалар да шушында тәрбияләнгән. Социализм чорында кылынган барлык тискәре эшләрнең Зөядә тирән эзе калган. Аның тарихы фаҗигале. Шундый тарих бар икән, без бит аны күрсәтмичә кала алмыйбыз. Бу тарихны халык белергә тиеш.

Сүз уңаеннан, археологлар Зөядә борынгы Татар бистәсен казып таптылар. Татар бистәсенә бәйле гаҗәп күренешләргә тап булдык: утрауны су баскач, андагы агач корылмалар, аларның нигезләре — барысы да исән калган. Агач исән, чөнки, су астында булгач, аңа кислород керми. Агач археологиясе дигән төшенчә бар. Агач дүртәр-бишәр йөз ел тирән катламда сакланган. Хәзер анда шундый музей ачабыз. Казан федераль университеты анда Тикшерү үзәге оештыра.

Җыеп кына әйткәндә, утрауда яшәгән, анда эшләгән халык юньле тормыш күрмәгән. Көн саен шунда эшләп кара әле! Төрмәләрдәге тоткыннарга хезмәт күрсәтеп, психик авыруларны карап, нәрсә күргәннәр алар? Алар бит соңгы елларга кадәр монах хөҗрәләрендә, туганнар корпусындаа яшәгән халык. Шуңа күрә, фатирлар төзеп, кешеләрне куандырдык. Дөрес, алар анда күп тә түгел — 200гә якын кеше.

— Мин дә монда тудым, дип кемнәрдер килергә дә мөмкиндер бит?!

— Анысы да гадәти хәл инде. Без шулай буласын белеп тордык. Анда җир бәясе дә Боровое Матюшинодагы кебек булачак, кыйммәтрәк тә булмаса әле, дигән идем. Утраудагы рус халкы, православныйлар — барысы да безнең гражданнар, безнең кешеләр. Без шулай итеп кешеләргә тигез караш, үзара килешеп яшәү үрнәген күрсәттек. Болгар да, Зөя дә — федераль истәлекләр.

Аларның икесе дә Идел ярында, иң матур урыннарда урнашкан. Аларны без бөтен дөньяга күрсәтергә тиеш. Чит ил туристлары Идел буйлап теплоходларда йөреп тора. Киләсе көзләргә, Алла боерса, теләсә нинди теплоход килеп туктый торган итәчәкбез. Иделнең түбән тирәнәйтү юнәләшендә дә эшләр бара. Бу да бер казаныш. Ул, һичшиксез, кирәк иде. Бу үзебезнең халыкның йөзен, дәрәҗәсен күрсәтүдә кирәкле адым. Монда яши торган башка милләт вәкилләре өчен дә Татарстан — туган җир. Биредә аларның ничәмә-ничә буыны яши. Татарстан — аларның язмышы. Әгәр без моны күрмәсәк, нинди халык булыр идек?!

Һәркемнең үз Болгары бар дип әйттегез... Уйланып алдым. Дөресен генә әйткәндә, тузган торакны бетерү программасы булмаса, бүгенге Казанны күз алдына да китереп булмас иде. Яңа йортлар төзеп, кешеләрне искеләреннән чыгардык. Бушка бит ул! Мондый масштаблы эшне хәзергәчә бездән гайре беркем эшләмәде. Гомумән, Рәсәй буенча бер өлкә-республика да эшли алмады. Дөрес, тырышып карадылар. Рәхимов тырышып карады. Аларга нәрсәдер җитмәде. Аларны зур оешмалары тыңламады. Ә без тыңлата алдык. Без үзләре җитештергән продукциянең 1%ын салым итеп түләттердек. Моның өчен миңа карата «эшләр» дә кузгатырга тырышып карадылар. Мин әйттем: ярар, ләкин суд ачык булырга тиеш: «За ликвидацию ветхого жилья». Шуннан соң туктадылар. Әллә ниләр кичерергә туры килде инде, язмышың, эшең шул булгач. Аннан каһарманлык та ясарга кирәкми. Аллага шөкер, бар да уңышлы килеп чыкты. Уйлап карагыз: бартер заманында, Рәсәйдә беренче булып, бөтен йортларга газ керттек. Әле дә Рәсәйдә 100% газлаштырылган бер төбәк тә юк. Бу — безнең халык өчен оҗмахка керү кебек булды. Без бит кизәктән ягулык ясап үскән балалар.

Тәрәзәне, кыш көне җылы чыкмасын дип, кечкенә итеп ясыйлар иде. Авылда бер кеше мунча якса, күршетирә, чират торып, шул бер мунчага керә иде. Бер ягылган мунчаның җылысы беткәнче, дип. Аннан икенче кеше яга иде. Ишекне озаклап ачып керсәң, безне ачуланалар иде. Син ишекне тиз генә ачып, тиз генә керергә тиешсең. Газ кертү безнең халыкның тормыш дәрәҗәсен бик нык күтәреп җибәрде. Йортларны ничек зур итеп сала башладылар! Без инде утынны оныттык, дияргә була. Программаның тормышка ашырылуына дә 10 ел тулды инде. Тоташ газлаштыруны 2003 елның августында тәмам иттек. Гомумән, бу катлаулы елларда үзебезнең халык, үзебезнең республика мәнфәгатьләре өчен байтак изге гамәл кыла алдык.

Авыл хуҗалыгын саклап калу да зур эш булды. Авыл хуҗалыгы икътисад кына түгел. Авыл хуҗалыгы ул — әхлакый-икътисади төшенчә! Ул — җир эшкәртү генә түгел, ул — халыкның тормышы, язмышы, халыкның мәдәниятен саклап калу дигән сүз.

Спортны үстереп, спорт корылмалары төзеп, шулар нигезендә Универсиада үткәрдек — булдыклы, сәләтле халык икәнебезне бөтен дөньяга күрсәтеп тагын бер баскычка күтәрелдек. Хәзерге кискен конкурентлык шартларында инвестицияләр җәлеп итү буенча Татарстан алдынгы сафларда. IT-технологияләр үстерү, информатизация кебек тирән фәнни гыйлем таләп итүче үтә заманча юнәлешләрдә дә уңышка беренчеләрдән булып ирешеп барабыз. Нәкъ менә шундый казанышлар этәргеч була да инде. Кеше ниндидер зур эшкә катнашып, аны булдырып чыга икән, аның үзенә ышанчы бермә-бер арта, ул алга омтыла һәм «үз Болгарын» таба.

— Эчтәлекле, кызыклы әңгәмәгез өчен Сезгә бик зур рәхмәт!

— «Безнең мирас»ны бик матур чыгарасыз. Ихлас күңелдән әйтәм. Бигрәк тә соңгы айларда чыккан журналларыгызның эчтәлеге һәм бизәлеше шатландыра.

30 гыйнвар, 2015 ел ■

КЕМНӘР СОҢ БЕЗ – ТАТАРЛАР?

Рабит Батулла

Чыңгыз хан. Барельеф

Чынгыз хан исеменең иске монгол телендә каллиграфик язылышы

Дәвамы. Башы 2 нче санда.

ЧЫҢГЫЗ ХАН *(тууына 860, үлеменә 788 ел)*

Чыңгыз ханның нәсел байрагы — ак җирлек уртасында тырнаклары белән кара карга тоткан карчыга сурәтле, тугыз чуклы, сөңге саплы, ат койрыгы тагылган туг[1].

Уникенче йөздә Көнчыгышта көчле Чин (Җин, Цзинь) империясе барлыкка килә. Аны «Алтын (Алтаң) дәүләт» дип тә йөртәләр. Чиннар белән бөрҗигин нәселле монголлар арасында еш кына сугышлар булып тора. Монголларның башлыгы Кабул (Хабул), Чин сараена килгәч, бәхәс чыгып, императорның сакалын учлап тота да үзенә тарта. Урта гасырларда ир кешенең (бигрәк тә илбашының) сакалына йогыну — илнең чикләрен бозып, сугыш башлауга бәрабәр санала. Бу эшкә хан ничек җөрьәт иткәндер, билгесез, әмма ул исән-сау килеш ватанына кайтып китә. Аның бу гамәле гасырлар буена зур батырлыкка тиңләнә, оныклары, торыннары озак вакыт:

— Безнең бабабыз Чин патшасын сакалыннан сөйрәп йөргән, — дип мактана.

Кабул ханның углы Бартан була.

Бартан баһадирның углы Ясүгәй була.

...Ясүгәй бервакытны атына атланып, өйрәтелгән ау кошы — сапсан белән ауга чыга. Юлында дөягә җигелгән, бик бай бизәлгән ике тәгәрмәчле туй арбасы очрый. Баһадир арбаны саклап баручы Җиләдүне (күршедә җәйләү тоткан мәркит кабиләсе башлыгының төпчек энесе) танып ала. Җиләдүнең яшь кәләшен үз ыруына алып кайткан чагы була. Ясүгәй баһадир арбага корылган күләгәле чатыр астында утырган искиткеч гүзәлне бер күрүдә ярата. Кызның кайсы кабиләдән икәнлеген тану һич тә кыенлык тудырмый: киемнәре, бизәнгечләре аның Көнчыгыш тарафтагы татарларга якын җәйләүдә тормыш кичерүчеләр токымыннан булуын күрсәтә. Сунарын да онытып, Ясүгәй өенә томырыла. Ике кардәшен ияртеп, туй арбасын куа чыга. Җиләдү өч батырга каршы сугышырга куркып, яшь хатынын ташлап кача. Шулай итеп, Оялын исемле (Оэлун, Хелун) бу кәләш Ясүгәйнең хатынына әверелә. Аңа өйләнеп, беркадәр гомер бергә яшәгәч, баһадир татарларга каршы яуга китә. Сугышта алты ай вакыт уздырып, кире кайтканда, Оялын аны көмәнле килеш каршылый.

...Бикә тулгаклый башлагач, тирмәгә кендекче хатын керә. Бәбине кабул иткәч, яңа туган сабыйның йодрыгында оешкан кан кысылганына игътибар итә. Кендекче хатын баланың аягынкулын, башын-күзен барлап чыкканнан соң әйтә: бу сабыйны алда хыянәтләр, аннан соң зур җиңүләр көтә, ди. Бәбине юындырып, елкы мае белән майлап, куй тиресенә төрәләр, биләүлиләр.

Булачак Чыңгыз хан шул рәвешле 1155 елда дөньяга килә.

ИСЕММЕ, КУШАМАТМЫ?

Дошманнарын җиңгәч, Ясүгәй Тимучин атлы татар юлбашчысын әсир ала, аны өенә алып кайта. Монголларда җиңелгән көндәшеңнең исемен үз углыңа кушу йоласы була. Ясүгәй дә бу гореф-гадәткә тугрылык саклый.

Тимучин исеме хакында төрле фаразлар бар, аны монгол теле аша да, кытай теле аша да аңлатырга тырышып карыйлар. Бәгъзеләре (мисал өчен, XIII гасыр голланд сәяхәтчесе Рубрук) «Төмөрҗын» (Тимерҗан), «Төмөрчин» (Тимерче) кебек татар сүзләре аша аңлата. Инглиз тарихчысы Җаһн (Джон) Мэн: *«Фарсыча чыганакларда Тимучин исеме «Темурҗин» рәвешендә языла»*, — ди. «Тимерче» икән, ни өчен ул исем [р] авазыннан башка «Тимучин»

[1] Туг — байрак сабы.

булып яши соң?» — дигән сорау туа. *«Чөнки,* — ди Җаһн Мэн, — *монгол исемнәрендә [р] авазы гомумән юк»*.

Көннәрдән бер көнне Ясүгәй, хатынының ата-анасына барып, үзара аңлашырга, дуслашырга, туганлашырга, алай гына түгел, сигез яшьлек Тимучинны берәр кызга өйләндерергә дә уйлап, сәфәргә чыга. Әмма ерак җәйләүгә барып җитә алмый, юлда башка бер кабилә очрап, бу кабилә башлыгы Дәйнең Бөртә *(Бортэ, Бөртәй, Бүртә, Буртә)* исемле тугыз яшьлек кызы барлыгы ачыклана. Ясүгәй углына шуны кодалый. Ике ата туганлашырга ант эчә. Булачак хатынына ияләнә торсын, дип атасы Тимучинны Бөртә янында, кодасы Дәй йортында калдырып кайтып китә.

Кайтканда ул дошманнары белән очраша. Дала кунакчыллыгы кушканча, татарлар юлчыны киез йортка чакырып кертә, бәйрәм ясый, сыйлый һәм, кайбер тарихчылар раслаганча, эчемлегенә агу куша. Бу — фараз гына. Бәлки, Ясүгәй алдан ук хаста булгандыр, артык сыйланып, авыруы көчәйгәндер, дип әйтүчеләр дә бар. Ләкин шунысы хак: өенә кайтуга, Ясүгәй үлем түшәгенә ава. Озак та узмастан, Оялын үзенең дүрт баласы, асрауга алган ике ятиме белән тол кала. Ясүгәйнең ыруы ятим гаиләне калдырып үзгә урынга күчеп (качып) китә, һичнинди ярдәм кылмый.

Тимучин анасы ярдәмендә барыбер акрынлап фәкыйрьлектән чыга, аягына баса, өлгереп җитә...

Тимучин ярәшелгән кызына өйләнә. Әмма озак та узмый, мәркитләр Бөртәне урлап кача. Хатынын әсирлектән коткару чараларын күрсә дә, Тимучин теләгенә ирешә алмый. Берничә ай уза. Ниһаять, Тимучин үзенең баһадир егетләре белән мәркитләрнең эзенә төшә, җәмәгатен коткара — дөрес, бу вакытка Бөртә йөкле була инде. Бераздан ул тәүге углын таба. Аңа Җучи исеме бирәләр (Риза Фәхреддин Җуҗи, Җаучы, Җулчы нөсхәләрен дә китерә). Җәйләүдә: «Булачак ханның беренче углы үзенеке түгел икән, ул мәркит юлбашчысының баласы икән», — дигән сүз тарала. (Киләчәктә Тимучинның башка угыллары да Җучины: «Син башка атадан!» — дип, җай чыккан саен төрттерә торган була.

...Олы яшькә җиткәч, хатынның берсе Ясуй Чыңгыз ханга әйтте:

— Гәүдәң карт вә корымыш бер агач кеби шатырдап җиргә ауган заманда халкыңны кемгә әманәт итеп калдырачаксың? — диде.

Чыңгыз хан хатынын бик яхшы аңлый иде. Йола буенча тәхеттә аның иң олы углы калырга тиеш: Җучи! Ләкин икенче углы Чыгытай кискен рәвештә каршы килде:

— Хан атабыз! Син безне шушы мәркит нәҗесенең кул астында калдырмак буламсың? — диде.

Җучи әйтте:

— Хан атабыз минем сездән аермалы булганымны һичбер вакыт әйтмәде! Син үзең нәҗес! — диде...

Ике туган бер-берсенең якасынаябыша. Богурчы (Бавырчы), Мукхали һәм Көкчү (Күкчә) шаман бәхәсчеләрне аера. Чыгытай сабырлана да:

— Ярар, мин Җучи белән бергә! — ди. Үгәдәй батыр да Җучины яклап сөйли.)

Ләкин Тимучин хатынын битәрләми, яратудан туктамый, Җучига кырын карамый. Бәлки, бөек хан Җучиның үз баласы булуына шикләнмәгәндер?! Җучи аның иң ышанычлы ярдәмчеләренә әверелә, зур дәрәҗәләргә ирешә. Чыңгыз хан аңа Иртыш елгасыннан алып Урал тауларынача туфракларны, Уралдан алып көнбатышка таба барлык җирләрне бүләк итә. Ул өлкә хәзер Олуг Олыс (Алтын Урда) буларак мәгълүм. Җучи үзенә бирелгән җирләрнең Каракорымнан (Монгол иле мәркәзеннән) бик еракта урнашуы сәбәпле, атасы янына сирәк кайта. Зур үҗәтлек белән үзенең дәүләтендә тәртип урнаштырырга алына. Кыпчак ягын үз итә.

1221 елда Чыгытай белән Җучи гаскәрләре Үргәнечне (Гүргәнеч) чолгап ала. Чыгытай шәһәрне җимереп, халкын таларга ниятли. Җучи аңа каршы төшә, кирмәннең төзек килеш саклануын тели (чөнки бу бай кала аның булачак ханлыгы туфракларында салынган). Нәтиҗәдә, бәхәс аркасында шәһәр алынмый кала. Чыңгыз ике углы арасындагы гауга турында ишетеп, өч гаскәр башына да Үгәдәй ханзадәне җибәрә һәм Үргәнеч тар-мар китерелә.

Җучиның бу кыланмышлары турында Чыгытай атасына:

— Ул синнән аерылып, үзбаш ханлык корырга йөри, — дип әләкли. Җучи үзенең яраннарына: «Акылдан язган ул! Чыңгыз шулкадәр халыкларны, җирләрне харап итте. Шуңа күрә, аны ау вакытында үтерергә дә, мөселманнар белән берләшергә кирәк!» — дигән, имеш.

Бу — гайбәт кенә булгандыр, бәлки? Әмма Чыгытай, үз чиратында, атасына:

— Сиздерми генә Җучины агулыйк! — дип киңәш бирә һәм, чыннан да, озакламый Җучи билгесез шартларда, атасыннан алты ай алда (1227 елның февралендә) үлеп китә.

Инде беркадәр артка чигеник.

1206 елда бөек корылтай Тимучинга «Чыңгыз» аты бирә. «Чынгыз», «Чингиз», «Чингис» язылышларында очрый торган бу исемнең килеп чыгышы турында да галимнәр арасында уртак фикер юк. Берәүләр аны «тенгиз» («диңгез») кәлимәсенә китереп бәйлиләр. Янәсе, Чыңгыз хан диңгезгәчә җирләрнең падишасы. Икенчеләр «Тәңре», «Тәңгәр» сүзе үзгәртелгән, дип фараз кыла. Диңгез дигән уйгыр каһарманы мәгълүм. Атилланың углы да Денгиз исемле була. Әмма монголларда андый сүз юк. Ә татарларда (төркләрдә) ул йөрештә булган һәм хәзер дә йөрештә әле. «Тимучин»ның да, «Чыңгыз»ның да татар-төрк сүзләреннән ясалганы көн кебек ачык.

Мин дә үз фаразымны язып карыйм әле. «Чин-гиз» дип таркатып карасак,

Чыңгыз ханның нәсел байрагы

ике сүз килеп чыгар иде: «чин» — «кытай» һәм «гиз» — «сәяхәт», «сәфәр», «яулап алу», «йөрү». Ягъни, Чингиз хан — «Кытайны яулаган бөек хан» булып чыга. «Чынгиз»ны таркатсак, «чын» — «хакыйкый», «гиз» — «хәрәкәт», ягъни «хакыйкый сәфәрче» мәгънәсенә юлыгабыз.

ТАТАРЛАР МОНГОЛМЫ, МОНГОЛЛАР ТАТАРМЫ?

1196 елдагы Буйр-Нур тирәсендәге сугышта *(мәкаләнең 2 нче сандагы өлешен карагыз. — **Ред.**)* татарларны тар-мар китергәннән соң, Чыңгыз хан исән калган бер баланы күрә. Оланның өстендә кыйммәтле кештән тегелгән атлас көртәй (куртка, кыска җиңле камзул), уң колагында алтын сырга, борынында алтын алка була. (Борынгы татар угланнарының, ир-егетләренең колакка алка-сырга тагып йөрүе мәгълүм. Билгесез рәссамның мәшһүр рәсемендә Үтәмеш тә сыргалар таккан. Димәк, рәсемдә кыз бала түгел, чын-



Чыңгыз хан һәм аның гаскәр башлары чапкан яулар

нан да, колагына кашлы алка таккан Үтәмеш Гәрәй хан басып тора!) Шиги Коткы исемле бу татарны Чыңгыз хан ыстанга алып кайта, анасы Оялын бикә аны үз баласы кебек егерме ел тәрбияли. Егет тора-бара Чыңгызның ышанычын яулый, кодрәтле монгол чирүенең шөһрәтле гаскәрбашы дәрәҗәсенә күтәрелә. Чыңгызның Шигига карата ышанычы шулкадәр куәтле була ки, ул аны дәүләтенең яргулаучысы (судьясы) итеп куя.

Чыңгыз хан:

— *Мин Мәңгелек Җәннәтнең сагы астында бөтен илемне тәртипкә салуны сиңа тапшырам. Син минем күзләрем бул! Минем колакларым бул!.. Син чатырдагыларны сыйныфларга бүл. Алар арасындагы каракларга, алдаучыларга, кем җәзалауга лаек, җәза бир! Кем үлемгә лаек, үтер! Мал-мөлкәтләренең күләмен билгелә. Кагыйдәләрне «зәңгәр дәфтәрнең ап-ак сәхифәләренә» яза бар! Язылганнарны берәү дә бозмасын!* — дип әйтә аңа.

Шигиның бу зәңгәр дәфтәре «Бөек Яса» (Ясак, Җасак) буларак билгеле. Аның төп нөсхәсе юкка чыккан. Ләкин «Яса»ның Бөек Монгол илендә Ана Кануны (Конституциясе) булып торуы һичшиксез. Кытайдан Ирангача җирләрдә табылган чыганаклар шуны күрсәтә.

Чыңгыз хан татар токымлы бу кешене шулкадәр хөрмәт итә ки, хәтта аның иң олы хаталарын да кичерә. Шиги Коткы утыз меңлек чирү белән Валиян шәһәрен камап ала, әмма Җәләлетдин шаһ аның гаскәрен пыран-заран китереп ташлый. Коткы бик күп сугышчыларын югалтып, пошаманга төшеп, хан янына кайта. Мондый җиңелүдән соң күпме яубашының башы очканын яхшы белә ул. Ләкин ил җитәкчесе яугирнең җиңелүен сабыр кабул итә һәм:

— Нойон Шиги гел җиңәргә өйрәнеп китте, ул әле җиңелү хурлыгын татып карамаган иде, алга таба саграк кыланыр! — ди.

Чыңгыз ханның тууы да, яшәеше дә, җиңү-җиңелүләре дә «татар» атлы кабилә белән нык бәйләнгән, аның тумыштан килгән «Тимучин» исеме дә, титул-дәрәҗә буларак бирелгән «Чыңгыз» кушаматы да татар сүзеннән

алынган, иң якын ярдәмчесе, үги туганы Шиги Коткы да — татар кешесе.

Совет чорында «татар» сүзе ишетелүгә үк Алтын Урдадан, хәтта Казан ханлыгыннан да баш тартучылар аз түгел иде.

Мәсәлән, Мәскәүдә, Съездлар сараенда, СССР язучылары корылтае вакытында мондый хәл була. Диварга картина элеп куйганнар: мәһабәт урыс воеводалары чепи-трахомалы күзле татарларны акыртып суя. Җыелыштан тарала торган халык, телиме-теләмиме, шушы рәсем янынннан узарга мәҗбүр. Баскыч буйлап татар әдипләре төшеп килә: Мирсәй Әмир, Афзал Шамов, Гази Кашшаф, Шамил Рәкыйпов, Шәриф Хөсәенов... Арттанрак төшүче әрмәннәр, грузиннар:

— Әнә татарларны чалалар! — ди.

Безнең классиклар ләм-мим, Гази Кашшаф кына:

— Без ул татарлар түгел бит, — дип әйтергә җөрьәт итә.

— Ә сез нинди татарлар? — ди әрмән.

— Без тәти татарлар, — диде Гази Кашшаф.

— Чыннан да, — ди грузин язучысы. — Сез кешегә охшагансыз, ичмасам. Болары бигрәк иләмсез (уроды)!

— Бу рәссам шулкадәр иләмсез затларны каян тапты икән?

Сүзгә Шәриф ага килеп катыша:

— Татар арасында бу кадәр иләмсезләр юк, рәссам аларны урыс арасыннан тапкан булса кирәк...

Чыннан да, нинди, кайсы татарлар соң без? Чыңгыз гаскәренең алгы рәтләренә тезелгән татарлармы? Тәңречә, толым-толым үрелгән озын чәчле, колакларына алтын алкалар, алтын сыргалар таккан, утрак тормышның, мунчаның ни икәнен белмәгән, аяусыз татарлармы? Әллә үз хокукын да яклый алмаган, кимсетелгән, мескенәйтелгән татарлармы?

Болгар бабаларыбыз дөнья тарихында булмаган батырлыклар кылып, Сүбәдәй (Чыңгыз ханның иң атаклы баһадиры) гаскәренең билен сындырган кавем! Монгол чирүендә иң алда татарлар сугышкан, болгарлар шуларның борынын канаткан, аларның курку белмәс йөрәгенә курку салган. Элгәреләребез татар-монгол хәтәренең урыс-славяннарга, Аурупага бәреп керүен берничә елга тоткарлый. Әмма ул тарафлардан ярдәм килмәгәч, Болгар, ахыр чиктә, барыбер тар-мар ителә.

Шуннан соң ике халык туганлашып китә, тел охшашлыгы аркасында, уртак никахлар күбәя, татарлар ислам кабул итә, җирле болгарларга үз аталарын, яңгыравыклы исемен тага. Димәк, уены-чыны белән: «Безнең анабыз — болгар, атабыз — татар», — дип әйтергә тулы хокукыбыз бар.

Әлбәттә, җиңелгән кавем баскыннарның исем-атын алырга әүвәл риза да булмагандыр. Ләкин вакыт үзенекен иткән. Без «татар» дигәннән куркып, оялып, кимсенеп яшәрдәй халык түгел! Татар булсаң, татар бул — дошманыңны ватар бул!

Урда, Казан ханнары үзләренең «чыңгызлы» булуы белән бик нык горурланган. Патша заманнарында зыялыларыбыз да җай туры килгән саен: «Без — Чыңгыз хан оныклары», — дип шыттырырга яраткан. Тукай да аратирә аны мактап искә ала. Галимнәребез генә төрлечә сөйли. Чыңгызга, монголларга һичнинди катнашыбыз юк, дип әйтүчеләр бар.

Чыннан да, Ерак Көнчыгышта яшәгән монголлар белән татарларның уртаклыгы бармы соң? Тарихчыларга ышансак, татар белән монгол икесе бер тамырдан чыккан, шул ук бөрҗигиннәрнең бер кавеме «монгол», икенчесе «татар» дип аталган, имеш. Тарихчылар әйтүенә караганда, Чыңгыз ханга чаклы «монгол» атамасы гомумән кулланылмаган, бары тик «мыңгу», «мангыт» кабиләләре генә булган. Имеш, Чыңгыз үзара сугышып яткан шул кабиләләрне берләштереп, аларга бу атаманы таккан гына. Монголларның тайчуит, хонкотат, мәркит, кәраит исемле телдәш

кавемнәре дә гомер кичергән. Татарларга якын телдәш, йоладаш аргын, буйрак, карлык исемле кабиләләр яшәгән. Шулай да, монгол белән татар арасында уртаклык юк түгел, сүзләребезгә генә күз ташлыйк: мерген (мәргән), миңгә (миң), жөргө (йөрге, чабышкый ат), хара (кара), өрөм (өре), архи (аракы), жили (җыл, ел), күрен (күрән), эр (ир), өкүз (үгез), баатор (батыр), багатур (баһадир), худа (кода), анд (ант), тархан (тархан), юртчы (йортчы, йорт карауччы), хатун (хатын), улус (олыс), яргучы (яргулаучы, хөкемче)...

Дала халыклары өчен уртак йолалар да шактый. Килен кешенең каенатасыннан тел яшерүе, үз иренә исеме белән дәшәргә ярамаганлыгы, елкыга кагылышлы йолалар: казы, кымыз, корт ясау, ат узыштыру, кузна уйнау, пакьләнү өчен учак аша сикерү, җиде бабаның исемнәрен, аларның кылмышларын балаларга өйрәтү, килгән кунакка салынган ашны, эчемлекне иң беренче хуҗаның татып каравы (керәшеннәрдә бу йола һаман да саклана), үлгән ирнең хатыны аның туганына калуы, ир оланга башка ырудагы кыз оланны сабый чактан ук кодалау һ.б. Бу йолаларның байтагы бездә онытылган инде, ә монголларда һаман да саклана әле.

Бүгенге татарлар арасында антропологик типлар берничә. Һинд кешесенә охшаган каракучкыл чырайлыларыбыз да, житен чәчле, зәңгәр күзлеләребез дә бар, кысык күзлеләребез дә бихисап, туры яки кылыч борынлы мәһабәт йөзләр дә тулып ята. Габдулла Тукай, Хөсәен Ямаш, Сәхипҗамал Волжская, Гөлсем Болгарская, Галиәсгар Камаллар — монгол каны катнашмаган токым варислары, юнан классик типлы, төрек кыяфәтлеләр. Урал артында, Себердә, Әстерхан якларында яшүче татарлар — монголоидлар...

Чыңгыз хан илләрне яулап алганда кемнең кем булуына карап тормаган, татармы ул, кытаймы, уйгырмы, мөселманмы, буддачымы, тәңречеме — үзенә баш ормаганнарның барысын да кырган. Һәм бу гамәленә аклану да тапкан әле. Мәсәлән, Бохараны буйсындырганнан соң, шәһәр халкына болай ди ул:

— *Бик күп гөнаһлар кылганыгызны сез үзегез дә беләсез һәм үз арагыздагыларның нинди гөнаһлар эшләгәнен дә күреп торасыз. Моны ни өчен сөйләгәнемне сорасагыз, әйтермен: сезне җәзалар өчен мине Тәңре үзе җибәрде. Әгәр дә сез бу зур гөнаһларны кылмаган булсагыз, Тәңре минем кебек берәүсен (җәза итеп) сезгә күндермәгән булыр иде.* («Яшерен тарих», инглизчә — «The Secret History», кытайча — «Юань-Чао биши» («Юань нәселенең яшерен тарихы») дигән китаптан.)

Вакыты җиткәч, Аксак Тимер дә җирле хакимнең «Син нигә үзең мөселман була торып мөселман болгарларны кырдың?» дигәненә каршы:

— Алар динне дөрес тотмыйлар иде! — дип, Чыңгыз хан сүзләре белән җавап кайтарачак.

Илләрне басып алу өчен шәп сафсата! Демагогия!

Чыңгыз хан Күк-Тәңрегә (төркләр Тәңресенә), Мәңгелек Җәннәткә инанган кеше, үз дәүләтендә диннәргә ирек куйган кеше. Ни хикмәт, үзе монгол, шаманчы-тәңречe булуга карамастан, тора-бара аның нәселе мөселманлашып бетә.

Бөтен татар дәүләтләренең (Алтын Урда, Себер, Кырым, Казан, Әстерхан, Нугай, Касыйм ханлыклары) башында Чыңгызның торыннары утырган. Алар татарлашкан, мөселманлашкан монгол. Бүгенге монгол белән бүгенге татар арасында уртаклык юк дәрәҗәсендә. Диннәребез дә аерым: алар — буддачылар (Чыңгыз хан үлеменнән соң кабул итәләр), без — әлхәмдүлилләһи, мөселманбыз. Телләребез дә аерым. Шулай булгач, тарихта безне Чыңгыз токымлы ханнарыбыз гына үзара бәйли түгелме?

Дәвамы бар ■

КЕРӘШЕН ЕВАНГЕЛИСТЛАРЫ

Николай Петров-Текин

(1920-1941 елларда Арча, Мамадыш кантоннары керәшеннәрендә протестантлык хәрәкәте)

Дүрт ел өзлексез барган Беренче Бөтендөнья сугышы тыныч елларда да ярлы яшәгән авыл халкын бик начар хәлдә калдыра. Тормыш чынбарлыгын тупикка китереп терәгән идеология, традицион дини инанулар реаль тормыштагы сорауларга җавап таба алмый, заман таләбен канәгатьләндерми башлый. Халыктагы өметсезлек, төшенкелек, киләчәк өчен борчылу илдәге идеологик-әхлакый киеренкелекнең көчәюенә китерә.

Дәүләт, кирәк вакытта халыкның аңын томаларлык «яңа фикерләр», кеше ышандырырлык уйдырмалар корырга өлгерә алмаса, банкротлыкка чыккан иҗтимагый-дини идеология урынына халык тарафыннан үзешчән рәвештә яңалары эзләнә, яңалары табыла. Үзгәртеп кору елларында киң таралган НЛОлар, чит планеталылар, Чумак-Кашперовскийлар, «мыльный» сериаллары, төрле чемпионатлар халыкның игътибарын читкә юнәлдерү, төп-нигез проблемаларны яшерү өчен кулланылып, идеологик «аптыраштан» вакытлыча чыгуның бер ролен үтәде…

Андый авыр елларда халыкта дәүләт (рәсми) чиркәвеннән аермалы яңа диннәр, дини карашлар, секталар тиз таралуы шуңа мисал булып тора. Дөньяда мондый диннәрнең, секталарның саны бихисап күп. 1920-1941 нче елларда ТАССРның Арча кантоны Мишә буендагы Кибәч, Кәвәл, Урвыкино, Козловка, Тенишевка, Пановка, Янсуар, Раевка, Шармаши һәм Керәшен Сәрдәсе, Иксуар, Көлкәмәр кебек керәшен авылларында киң таралып өлгергән евангелист христианнары дини җәмгыяте шул исәптә. Шулай ук, архив чыганакларында дөньяга, дингә үзгә карашларның Мамадыш якларындагы рус, керәшен авылларында да киң таралып өлгерүе турында хәбәрләр бар. Теоретик нечкәлекләргә бик исе китмәгән гади авыл халкы аларны баптистлар дип тә йөргән. Евангелист христианнар протестант чиркәвеннән аерылган җәмгыять булып санала. Алар Инҗил принципларын пропагандалап, Иисус Христосның Тау вәгазе васыятьләрен (заповедь) халыкка таратуны иң олы бурыч дип саный. Евангелист христианнар чиркәүнең күпчелек серле йолаларын, диннең изге шәхесләрен (церковные святые), изге тәреләрне (святые иконы), хачны танымый, православие чиркәвен кире кага. Христиан диненә нигез салучы Иисус Христос яшәгән заманда чиркәүнең, төрле-төрле катлаулы йолаларның, шулай ук күп санлы дини хезмәткәрләрнең, профессиональ югары һәм түбән рухани чиннар иерархиясенең дә булмавын үрнәк итеп, аларның артыклыгын, Ходайга ышанучылар өчен кирәк түгеллеген дәлилиләр…

Алар изге китаплардагы (Тәүрәт

(Библия), Коръән) һәрбер кеше үзенең шәхси хезмәте хисабына, башкалар өлешенә кагылмыйча көн күрергә тиешлеге турындагы кагыйдәне үтәргә өнди. Бәндә Ходай Тәгалә белән турыдан-туры мөгамәләдә булырга тиеш дип, махсус арадашлык итүчеләр төркеменең, бу очракта руханиларның, аларга хәерхаһлы җитәкчеләрнең, байларның әрәмтамаклыгын фаш итәләр. Бу сүзләр халык җилкәсендәге дәүләт түрәләрен бик шомландыра, күңелләренә тетрәндергеч шөбһә сала, аларга дөнья рәхәтенә туйганчы ләззәтләнергә комачау итә.

Евангелист христианнар чиркәүдә сабый балаларны чукындырылуны ялгышлык дип, яше җиткән кеше вөҗдан ирегенә таянып, үз ихтыяры белән, табигатьтәге ачык суда чукынырга тиеш, дип аңлаталар. Христос үзе һәм беренче христианнар чиркәүдә поплар кулыннан чукындырылмаган, дип сөйлиләр. Моннан инде үзеннән-үзе чиркәүнең, попларның кирәк түгеллеге килеп чыга, аннан ары Инҗил принциплары белән яшәгән халык өчен дәүләтнең дә тормыш өчен артык, паразит орган икәнлегенә ерак калмый.

Евангелист христианнар, үзләренең халык арасында тараткан үгетнәсыйхәтләрендә (проповедь, вәгазь), кеше дөньяда Иисус Христостан үрнәк алып, яхшылык кылыр өчен яши дип сөйлиләр, шуның мисалында шәхси үрнәк күрсәтәләр. Кешене кыерсыту, бигрәк тә яшәү сәләтеннән мәхрүм итү, хәтта сугышта үтерешү иң зур кабахәтлек дип, бу гамәлләрне Тәңре-Тәгаләгә каршы килү, дип санныйлар. Шунлыктан кулга корал алудан баш тарталар. Мондый тәгълимат, һичшиксез, коммунистларның корал көче белән бөтен дөньяда пролетариат, эшче-крестьян сыйныфы диктатурасын урнаштыру өчен кирәкле корбаннарның санын чикләмәскә дигән чакыруы белән бер дә килешми. Шунлыктан аларның, ягъни бу ике идеология вәкилләренең бергә яши алуы һич тә мөмкин түгел. Хакимият башында утыручылар бу хакыйкатьнең үзләренә куркыныч китерүен бик тиз сизеп алалар.

Шулай итеп, евангелистлар дәүләт чиркәвенә, дәүләт тарафыннан алып барылган дини идеологиягә каршы торалар, аның халыкка сеңдерелгән йогынтысын юкка чыгарырга омтылалар. Бу өйрәтү кайбер яклары белән Михаил Александрович Бакунин (1814-1876), Пётр Алексеевич Кропоткин (1842-1921) һәм Лев Николаевич Толстой (1828-1910) тәгълиматлары белән уртак. Дингә үзенчәлекле карашлары белән алар XIX гасыр-XX йөз башында киң таралыш тапкан вәисиләр хәрәкәтен искә төшерә. Ә кайбер мәсьәләләрдә исә ислам диненең төп чыганакларына, нигезенә кайтырга чакыручы радикаль төркемнәрне хәтерләтәләр.

Тормыш авырлыклары чиксез арткан заман — 1920 елларда Арча кантоны Пановка волостена кергән Кибәч исемле керәшен авылында бу якларда гомердә күренмәгән хәлләр башланып китә.

Кибәч, Иван Грозный заманында күчерелеп китерелгән йомышлы керәшеннәр авылы булса да, күршетирәдәге башка керәшен авылларыннан тормыш үзенчәлеге, яшәү рәвеше белән аерылып торган. Беренче мәртәбә авыл исеме 1602-1603 елларда салым җыюны тәртипкә кертү өчен Иван Болтин төзегән җир теркәү кенәгәләрендә искә алына. Анда йомышлы керәшен Кузьма Башиев (Текей Азинның дәдәсе Баши Азинның улы) һәм ясаклы керәшеннәр Семён Сонин, Парфен Иванов, ясаклы татар Есекей Касымов яшәгәне язылган. Күрше Әтрәч авылы җирләре атаклы керәшен кенәзе Яков Асанмурзин биләмәсендә булган. Ясаклы татар Есекей Касымов Кузьма Башиев белән бер ыруглан, Текей Азинның энесе Касыймның улы. Касыймның нәселләре Кибәчтә һәм күрше Керәшен Казысы авылла-



Архив У…
следствен…
Том 1
Копия вер…

Характеристика.

На гр-на дер. Кибечи Кибечинского с/…
Тюлячинского р-на Тат АССР Крысов…
Иванович родился 1895 году по соци ал…
крестьян-колхозник. Женатый, состо…
человек. До и после революции занимался…
1919 года отделился от отца и стал…
стоятельно и управлялся своем хозяйс…
нимался хлебопашеством. С 1919 года та…
ганизовать группы евангелистов и на…
…тив против Советской власти. В груп…
ганизовал много семейство, одновременно…
ысова Афанасия Ивановича, Крысова Ил…
ысов Николай Иванович был организат…
ой группу него в группе находился…
гитировал против организацие к…

что было взят через …ский Орг. НК.В…
еден в тюремный заключение на 3 г…
…в к-зы и советской власти. В. 193…
. Кроме того он срывал от учебы…
ов Василий бросил ходить в школу (…
за Анна имеют 7 плохих отметок (учени…
, родные мать и отец деть…
гелистов, В данное время де…
ской власти и не подчинает…

Афанасий Иванович Крысов



ВЫПИСКА ИЗ ПРОТОКОЛА

…Особого Совещания при Коллегии ОГПУ от „26“ июня 1929 г.

…АЛИ:	ПОСТАНОВИЛИ: доп.3
…по обв. гр. …Ивановича и …Ивановича	КРЫСОВА Николая Ивановича и КРЫСОВА Афанасия Ивановича заключить в концлагерь, сроком на ТРИ года, считая срок с 16/3-29 г. Дело сдать в архив.

Архив УФСБ … РТ
следственное … 2-8614
Том 1 … 80
Копия верна …

…арь Коллегии ОГПУ

Николай Иванович Крысов, 1941 ел

рында яши. Православие диненә кайчан күчүләре билгеле түгел. Алардан тыш, Кибәчтә Муллин, Болгар, Ихсан атамалы керәшен нәселләре бүген дә яши. Кибәчлеләр күрше мөселман авылы Чыты белән гомер-гомергә кыз алыш-бирешеп, кода-кодагый булып, туганлашып, гөрләшеп яшәгән. Башка керәшен авылларында мөселманнар белән мондый туганлык бәйләнешләре элек очрамаган. Хәзер инде андый туганлык гадәти хәлгә әйләнде. Бу чиркәү-мәчетнең, руханиларның эшендә «идеологик җитешсезлекләр» булганлыгын күрсәтә.

Кибәчлеләрнең беркайчан да үз авыл чиркәве булмаган. Алар Керәшен Сәрдәсе, Иксуар, Көлкәмәр, Әтрәч авыллары белән бергә күрше Рус Сәрдәсендәге «Ходайның үзгәрүе» (Перображение Господня) чиркәвенә беркетелгән. Рус Сәрдәсе авылы Кибәчтән ике-өч чакрымда гына булса да, авыллар арасындагы күп сулы Мишә елгасы, күперләр юклыктан, киң болыннарны тутырып аккан язгы ташулар вакытында атналар-айлар буена чиркәү белән элемтәне өзә, приход (мәхәллә) халкын дини күзәтү астыннан ычкындыра. Авыл халкы да чиркәүгә килеп йөрми, поп та аларны эзләп йөри алмый. Шунлыктан яз айларында туган балалар өчен метрика кенәгәләрендә «Әби чукындырган» («Крещён бабкой») дигән ярым рәсми термин язылган. Юллар өзелеп торганда кибәчлеләр вафат булган кешеләрне дә попсыз гына, үзләре аңлаганча, йолалап күмгәннәр.

Мишә буендагы башка керәшен авылларында да рәсми дин өчен җан атып йөрүчеләр булмаган. Сирәк кенә чиркәүдә күренүне, попларга сәдака бирүне мәҗбүри вазифа итеп караганнар. Шуның өстенә бу тәртип, чиркәү хезмәткәрләре күзәтүеннән чыгып, земский становойлар тарафыннан да кисәтелгән.

Кибәчтә әле соңгы елларда да яңгыр кирәк булганда авыл картлары җыелып, тирә-юньдәге чишмәләрдә келәү йоласы уздыралар. Бу чараның файдасы күрше мөселман авылы кырларына да иңгәнлектән, яңгырлар озак яумый тора башласа, өлкән яшьтәге татар агайлары килеп: «Ходайга келәүләрегезне уздырырга кирәк!» — дип, керәшеннәрнең исләренә төшерә башлыйлар.

Әйтеп үтелгән хәлләр авыл халкында чиркәү кагыйдәләренә бик иркен караш, кешеләрдә үзара толерантлык мөнәсәбәтләрен китереп чыгара, рәсми диннең йогынтысын нейтральләштерә. Фанатизмнан ерак торып, дингә үзләренчәрәк карагангылыктан керәшеннәр, чиркәү белән каршылыкка кермичә, ярыйсы гына җайланып барган үзара битарафлыкта тыныч кына яшәп килгән.

Дөньяга, дингә яңача карашларның беренче вәгазьчесе, пропагандисты Беренче Бөтендөнья, Гражданнар сугышларында катнашкан Кибәч авылы кешесе Николай Иванович Крысов (1895-1942) була. 1915 елда патша армиясенә алынып, башта Владивостокта, 1916-1917 елларда Двинск янында, Бессарабия фронтларында сугыша. Шул елларда, дәүләт тарафыннан оештырылган массакүләм кеше үтерү күренешләре, күз алдында чиркәүдә сөйләнгән әхлакның бозылу үрнәкләре гади авыл егетенең күңелендә тирән яра эзләре калдыра. Салкын, юеш окопларда үлем көтеп утырганда, дөньяга карашлары бераз киңрәк булган фронтташлары ярдәмендә, Аллаһы Тәгалә биргән изге кенәгәләр, ул кенәгәдәге васыятьләр аша кешенең җанын кою дөньядагы иң зур язык икәнлеге белән таныша. Язмалар кеше үтерү коралларын кулга алмаска, хакимиятнең Алла сүзенә каршы килгән җинаятьчел боерыкларын үтәмәскә өйрәтә. Шул сүзләргә ияреп, ул кулына корал алудан баш тарта. Әле патша Россиясе заманы булганлыктан, кешенең вөҗдан ирегенә хокукын танып, башына «ялгыш»

идеяләр керә башлаган эчкерсез авыл егетен санитар хезмәтенә күчерәләр. Фронтта күргән җан тетрәткеч тирән борчулар аңа гомере буе кеше булып калырга, дөреслекне яклау юлында башкаларга шәхси үрнәк күрсәтерлек зат дәрәҗәсенә үсәргә этәргеч була.

1917 елны фронттан кайтып бер ел авылда эшләгәннән соң, 1918 елның көзендә Кызыл Армиягә алына. 1921 елга кадәр Казандагы 21 нче кавалерия полкында хезмәт итә, полк белән бергә Нократ елгасы буйларында Колчак фронтына каршы көрәшә. Хезмәт елларында, үзенең инанган карашларыннан чыгып, кулына корал алудан баш тарта, тагын санитар итеп билгеләнә.

1919 елның октябрендә ул Казанның 1910 елларда оештырылган евангелист христианнары җәмгыятенә керә.

1921 елда армия хезмәтен тәмамлап туган авылына кайтканда Николай Иванович Крысов инде актив, нык ышанган, тайпылмас карашлы евангелист, шактый тәҗрибәле проповедник була. Үзенең яңа карашлары белән туганнарын, иптәшләрен таныштыра башлый. Тәгълимат шактый гади: кешене кыерсытма, үтермә, кеше өлешен урлама, үз хезмәтең белән яшә, уйнашлык кылма, ялган сөйләмә, дөрес сүзне сөйләргә курыкма, бар кешене дә туганнарың итеп күреп, аларга яхшылык кына эшлә, җәберләнгәннәрне якла. Шуларны өйрәнеп, тормышта Иисус Христостан үрнәк алып яшә. Бер караганда, берәүгә дә зыян китерерлек әйбер юк шикелле. Тик, алга узып әйтеп куйыйк: дәүләтнең, хакимият тотучы түрәләрнең үз логикасы, үз карашлары, эшче халыктан үзгә ихтыяҗлары бар. Тарихи материализм өйрәтүеннән билгеле булганча, байлык сарайларында яшәүчеләрнең уйлау рәвеше алачыкларда яшәүчеләрнекеннән бик нык аермалы. («В хижинах мыслят иначе, чем в дворцах». Людвиг Фейербах.)

Үзләренең гаделлекләре белән сокландырган сүзләр авыл халкы арасында бик тиз тарала. Яңа саналган гадәтләрне өйрәнү дәверендә Кибәчтә үзеннән-үзе евангелист христианнар җәмгыяте оешып китә. Ике-өч елдан инде җәмгыятьтә 60тан артык кеше була. 3-4 класс белемле яки бөтенләй «шкул»да укымаган крестьян мужикларыннан 15тән артык мөстәкыйль эш итәрлек проповедниклар үсеп чыга. Җәмгыятькә ирләр үзләренең хатыннары белән кереп яңа йолалар, яңа мөнәсәбәтләр, яңа гадәтләр үзләштерә башлыйлар, бергәләп изге кенәгәләр укыйлар. Ә анда, чыннан да, югарыда санап кителгән кагыйдәләрне Алла улы Христос үзе әйтеп, язып калдырган. Җәмгыятькә яше җиткән олы кешеләр үз ихтыярлары белән ачык сулыкларда яңадан чукындырылып алына. Бала вакытта чиркәүдә чукындырылган булу исәпкә керми.

Җитәкчеләре Николай Иванович Крысов, Христос васыятьләре буенча яшәп булганлыгын исбатлап, үз тормышы белән кешеләргә үрнәк күрсәтә. Аның белән бергә Кибәч кешеләре Медведев Кирилл Васильевич, Крысов Афанасий Иванович (бертуган энесе), Тлитов Михаил Николаевич, С.Н. Золин, Елыткеев Иван Артемьевич һәм Керәшен Сәрдәсе авылыннан Тимофеев Фёдор Антонович, Тимофеев Иван, Романов Николай, Трофимов Семён Михайлович, Цыганов Егор Родионовичлар үзешчән проповедниклар булып йөри башлыйлар. Шунысын да исткәртик, бертуган энесе Афанасий Иванович җәмгыятькә комсомол оешмасын ташлап килә.

Бу елларда Николай Иванович Крысов Казандагы евангелистлар оешмасы белән тыгыз элемтәдә тора, алар аркылы Ленинград җәмгыятеннән кирәкле китаплар, журналлар, белешмә брошюралар ала. Казан оешмасының җыелышларында тулы хокуклы вәкил булып катнаша.

1928 елның июль аенда Кибәч авылы җәмгыяте, оешма буларак, тиешле дәүләт органнарында теркәлә. Евангелист христианнар җәмгыяте үзенең

эшчәнлеген күрше Кәвәл, Урывкино, Козловка, Райково, Янсуар, Тенишевка, Шармаши, Керәшен Сәрдәсе кебек керәшен һәм рус авылларына җәелдерә башлый. Кыр эшләре тынып торган арада, тирә-як авылларда такта ярып, бура бурап, башка төрле эшләр башкарып йөргән үзешчән проповедниклар да тиз арада халыкта теләктәшлек таба. Аларның авылларда җыелышлар уздырып, халыктан таяныч табулары һәм хуплау күрүләре түрәләрне бик нык борчуга сала.

«Красная Татария» газетасының 1929 елгы 9 гыйнвар санында кулакларга каршы көрәшне кискенәйтү кирәклеге дәлилләнеп, евангелистларның да Совет власте өчен бик куркыныч булулары аңлатыла. Имеш, Христос коммуна булып яшәргә өйрәткән, Христосның васыять сүзләрен үтәмичә, барлык коммунистлар да христианлыкка күчмичә илдә коммунистлар җәмгыяте, коммунизм төзү мөмкин түгел. Газета бу сүзләрнең «контрреволюцион асылын» халыкка аңлата, дингә каршы көрәшне көчәйтергә кирәген ассызыклап, әлеге «зарарлы» карашларны фаш итә. Аларның сайлаулар нәтиҗәсендә хакимияткә килүләре куркынычы турында кисәтә.

Хакимият түрәләре, евангелистлар җәмгыяте җитәкчеләрен рәсми булмаган рәвештә берничә мәртәбә җитди кисәткәннән соң, 1929 елның 12 мартында Крысов Николай Иванович һәм энесе Афанасий Иванович Янсуар авылының мәктәп директоры запискасы нигезендә кулга алына.

1929 елның 26 нчы июнендә ОГПУ гаепләнүчеләрне җинаятьләр кодексының атаклы 58 маддәсе нигезендә 3 елга концлагерьга ябарга хөкем чыгара.

Сорау алу вакытында Н.И.Крысовның авылдагы җыелышларда: *«Коммунистлар — икейөзле, сатлык җанлы кешеләр, халыкны алдалыйлар. Үзләре халыкка әшәкелекләр, усаллыклар кылып, эчкечелеккә бирелеп, дәүләт малын урлап яшиләр»*, — дигән сүзләре ачыкланган. Әйткән сүзләреннән гаепләнүчеләр үзләре дә баш тартмый. Авылның комсомол яшьләре Докучаев, Мышев, Ивановлар күрсәтүенчә, алар комсомол эшенә дә зур комачаулык китергәннәр, коммунистларны яманлаганнар.

Менә Афанасий Иванович Крысовның сорау алу беркетмәсенә язылган йомгаклау сүзләре: *«Мин бүген кулга алынып, Христоска ышанган өчен газап чигәм, ләкин бу мине бер дә куркытмый, хәтта җәзалаулар да мине үз карашларымнан чигендермәс. Әгәр дә иреккә чыгарсалар, мин яңадан, бернинди каршылыкларга карамыйча, Ходай сүзләрен халыкка җиткерүне дәвам итәрмен».*

Китерелгән җавап сүзләренең мораль-әхлакый югарылыгы таң калдыра. Идеягә шундый тугрылык безнең «сөекле» обком секретарьларында да булган булса, инде илдә күптән коммунизм чәчәк атар иде.

3 ел срокны тулысынча утырып, 1932 елны концлагерьдан чыкканнан соң, агалы-энеле Крысовлар өйләренә, Кибәчкә кайталар. Сораштыру вакытында әйткәннәренә тугры калып, эшләрен яңадан активлаштыралар. Ике айдан соң Николай Иванович, «лишенец» буларак, «трудармия»гә алына. Казанда бер ел хезмәт итеп, 1933 елны яңадан туган авылына кайта.

ВСЕХның (Всероссийский Союз Евангелистов Христиан) Х съездында (1929 ел) армиядә кулга корал тотып хезмәт итүне Аллаһы Тәгаләнең рөхсәт итүе турында карар кабул ителә. Н.И.Крысов, бу карар белән килешмичә, евангелистларның Казандагы оешмасыннан чыга. Карарны съездда үткәрү өчен махсус задание белән Үзәктән эмиссар булып М.С.Капустинский килә. 1929 елның 27 маенда уздырылган җыелышта «армиядә кулга корал алып» хезмәт итү тиешлеге, Совет властена вөҗдан чисталыгы белән һәрьяклы булышлык күрсәтү кирәклеге шул ук изге

кенәгәләргә таянып бик нык дәлилләнә. Казан оешмасына кушылып, Ленинград оешмасы җитәкчесе Котожыгин да Н.И.Крысовны үгетли, «яңа карарның» оешмаларны саклап калу өчен кирәклеген аңлатырга тырыша. Заманалар үзгәреп киткәнлектән, ВСЕХ идеологиясен яңа хакимият идеологиясенә, дәүләт кануннарына яраклаштырырга кирәк була, күнмәгән кешеләрдән арыну, котылу башлана. Үҗәт проповедник барыбер үз сүзендә кала — эшен Казан оешмасыннан аерым, Беренче Проповедникның Тау вәгазендәге васыяте нигезендә дәвам итә. Тормыш авырлыгын бераз җиңеләйтү максатыннан, ачлыктан качып, башка крестьяннар кебек үк, ул да читкә эшкә киткәләп йөри. 1936-1938 елларда Дәрвишләр посёлогындагы «Вагонстрой» дип исем алган 137 нче номерлы завод төзелешендә эшли. Анда да ул үзенең эшчәнлеген туктатмый, фикердәшләре белән тыгыз элемтәдә тора.

Авылга яңадан кайткач та шул ук хәлләр башлана. Инде түрәләр аларның эшләрен күзәтү астында тотып, һәр адымнарын «учётка» ала башлыйлар. «Уяу-сак гражданнар» Николай Крысовның бергә ял итеп утырганда әйткән сүзләренә хәтле «тиешле җиргә» язып, җиткереп тора. Җирле Советлардан, колхоз җитәкчеләреннән аның турында, авылның яңа хуҗалары өчен һич килешмәгән зарарлы сүзләре язылган тасвирлама кәгазьләр килеп җитә. Совет власте, ВКП(б)ның җитәкче бөек юлбашчылары турында әйтелгән «оятсыз ялалары» («коммунистлар ялганчылар»), дөньядагы «иң гадел» Конституциягә яла ягуы («илдә гражданнарның вөҗдан ирегең саклау үтәлми»), берсе өстенә берсе өелеп, НКГБ органнарының агымдагы оператив эш архивында җыела бара. Нәтиҗәдә, дәүләтнең түзәр хәле бетә. Кибәч авылында сөйләнгән «ялгыш» сүзләргә каршы җитди чаралар күрү кирәклеге ачыклана.

Җыелган «оператив материаллар» нигезендә 26 апрельдә ТАССР НКГБның оперуполномоченные, кече лейтенант иптәш Мурадымов 16494 номерлы «Дело» башлап җибәрә. Николай Крысовка тентү ясарга һәм кулга алырга дигән карар чыгарыла. «Дело» документында шаһитлардан җыелган «хәбәрләр»нең кайберләрен укып үтәбез:

«Совет власте газеталарында колхозчылар яхшы яши башлады, дип язалар. Бары да ялган. Колхозчылар көне-төне эшлиләр, ашарларына бирмиләр, барлык җыйган икмәкне дәүләт тартып ала, кибетләрдә товарлар юк. Болай яшәү мөмкин түгел, большевиклар алар антихристлар, газеталар халыкның күзен генә томанландыра...»

«Мине төрмә дә, янаулар да куркытмый. Ахыргача дөреслекне әйтәчәкмен, Соввласть халыкны алдый, бик күпне дә вәгъдә итә, тик әйткән сүзен үтәми...»

«Патша вакытында вөҗдан иреге бар иде, хәзер инде аны да бетерделәр, әүвәлеге тормышны искә алып сөйләшү дә гаеп санала...»

Һәрбер сүзнең әйтелгән урыны, елы, көне, хәбәр итүче кешеләрнең фамилияләре китерелә.

ТАССР Куркынычсызлык халык комиссары капитан Морозов 1941 елның 30 апрелендә раслаган кулга алу турындагы карар гамәлгә аша. Карарга шул ук көнне ТАССРның прокурор ярдәмчесе ризалык биргән.

1941 елның 14 маенда Н.И.Крысов йортында тентү ясала. Аны кулга алалар һәм ТАССР НКГБ Арча МРОсының «Домзак»ына озаталар. Өйдә биш бала белән хатыны кала. Олы уллары Василийга — 15 яшь (ике елдан соң Бөек Ватан сугышында һәлак була), кечесе Пётрга — 2 яшь.

15 май көнне ТАССР НКГБ МРОсының Арча оперуполномоченные сорау ала башлый. Иң беренче сорау аның ят кулак элементлары белән

нинди элемтәләрдә булуы турында. Кайбер документлардан күренгәнчә, кулга алулар ВСЕХны тар-мар итеп евангелистлар җәмгыятьләрен бетерү планы буенча башкарылган булырга тиеш. Сорау алулар, тикшерү эшләре бер айдан артык бара.

29 июльдә ТАССР Югары Суды гаепләнүче Николай Иванович Крысовны югарыда күрсәтелгән җинаятьләре өчен 58 нче маддә нигезендә 10 елга төрмәгә ябарга, өстәп, өч ел сайлау хокукыннан мәхрүм итәргә, дигән хөкем карары чыгара.

Хөкем ителгән Крысов Николай Иванович Казандагы 1 нче номерлы төзәтү-хезмәт колониясенә ябыла. 1942 елның 19 маенда 45 яшендә ачлыктан үлә. Төрмәдә үлгән башка кешеләр кебек Казанның Архангель зиратына күмелгән дип санала. Күпсанлы исемсез һәм ташсыз каберләренең урыннары билгеле түгел.

Энесе Афанасий Иванович (Апач бабай) Крысов исә Бөек Ватан сугышыннан бер кулын калдырып кайтты. Бер кул белән печән чабарга, балта эшләре эшләргә, җир сөрергә җайлаша, оныкларын тәрбияләп, йорттагы барлык эшләрне башкарып гомер итә. Гомеренең ахырына хәтле үзенең иманына, ышанган карашларына тугры булып кала. Уллары Константин һәм Иван Афанасьевичлар җидешәр ел Совет иленең Хәрби-диңгез флотында хезмәт итеп кайтып, читтән торып белем алдылар, укытучы булдылар, гомер буе авыл мәктәпләрендә гыйлем бирделәр.

1993 елда Крысов Афанасий Ивановичның, 1994 елда Крысов Николай Ивановичның Россия Федерациясе Югары Суды карары нигезендә барлык гаепләре дә акланды. Чиксез җәбер-газап күргән изге затларның урыннары оҗмахта булсын.

***

Соңгы елларда Россия Федерациясендә, шул исәптән Татарстан Республикасында да протестантлык хәрәкәте, аның евангелистлык агымы югарыда санап үтелгән рәвештә киң колач җәеп эшләп килә. Рәсми диннәр тирәсендәге керем-төшемлерәк урынга сыенып өлгермәгән кичәге обком, райком активистларының күбесе шунда кайнаша. Эштән күптән бизеп азынган, башка гамәлгә җүн юк, бизәкле яшәргә кирәк — кая барасың! Бу оешмаларда, җәмгыятьләрдә гади халык, яшьләр дә бик актив катнаша. Араларында татар, керәшен егет-кызлары да шактый. Биредә урлашуга юнәлтелгән җәмгыятьтән, чиксез алдауга корылган дәүләт сәясәтеннән, түрәләрнең оятсыз, намуссызлыгыннан котылу юлын изге кенәгәләрдән, пәйгамбәрләр сүзләреннән эзлиләр... ■

КЕМ УЛ МОРАД МУЛЛА?

Раиф Мәрданов

Мулла Морадның чордашы һәм фикердәшләреннән **Нияз Бикмәт улы**ның әлеге хәрәкәткә турыдан-туры бәйле, бик тәэсирле бер шигъри әсәре дә бар. Ул бу хәрәкәтнең асылын ача торган җитди дәлилләрнең берсе буларак зур әһәмияткә ия. Аны мулла Морад тарафдарларының зикере кебек яисә дәрт өсти торган гимны сыйфатында диярга дә ярый. 17 дүртьюллыктан торган ул текстны без XIX гасыр башындагы бер кульязма җыентыктан күчереп алдык. Төп нөсхәдә аның исеме итеп борынгы текстларга хас булганча, «Илаһи бәет» дигән гомуми атама гына язылган.

ИЛАҺИ БӘЕТ

Кичә-көндез фикер идеңләр,
Аллаһ адын зикер идеңләр.
Телдин салма Аллаһ адын,
Шәһри Болгара кидеңләр.

Аңлаңыз бәндин моный,
Фикер идеңләр төне-көни.
Малы Мәннан җандин кисмеш,
Сәйер идеңләр Болгар юлый.

Ошбу юлның имамы вар,
Инанганның иманы вар.
Һәркем аны раст дип белсә,
Яри кылсын сахибе гар.

Мөхәммәддин мөршиде вар,
Мулла Морад — мөриде вар,
Ходаемдин өмидем вар.
Гүзәл, мәкъбүл Болгар юлы.

Вәлиләрдин рөхсәт алган,
Халаикъга чалма чалган,
Рәхмәт деләб дога кыйлган,
Нә хуш, гүзәл Болгар юлы!

Ике күзең йомык улса,
Хәтерең һәм сынык улса,
Җөмлә хаҗәт кабул улса,
Гаҗәп ирмеш Болгар юлы.

Мулла Морад сафи улган,
Мөридләре кяфи улган.
Ошбу хәлне фәкыйрь күргән
Кәнд үзенгә җафи улган.

Бу фәкыйрьнең догасыдыр,
Мөридләр чук уласыдыр,
Мәүлясенә зикер айган
Мәрсус кеби уласыдыр.

Ошбу дин кави улсун,
Хакъга карин вәли улсун!
Дәрәҗәсе көндин-көн
Халык ара гали улсун!

Болгарның вәлиләре,
Даим килүр хуш исләре.
Анда варган ирәнләрнең
Сил тик акар күз яшьләре.

Шәүкы шәраб эчкем килүр,
Канат йәйеб очкум килүр.
Астанәне кочкум килүр,
Гүзәл, мәкъбүл Болгар юлы.

Тәвафчылар күчә-күчә
Диңгез белә айрык кичә.
Догалары кабул улса,
Нә хуш, гүзәл Болгар юлы!

Ахыры. Башы журналның 2 нче санында.

Шәһри Болгар манарасы,
Җанбактыдин җам арасы.
Уфа халкы анда барса,
Шушма буйлар һәм барасы!

«Кем?» — дәйеб сорасалар,
Без әйдүрмез: «**Мулла Нәдүр**!
Бу дөнйадин нәкыль кылган,
Рәхмәт кыйлсун Мәүля Кадыйр».

Кара йөзле Нияз гасый,
Йыглаб чыкмас күздин яши,
Фыйск-у-фөҗүр җөмлә эши.
Нә хөрмәтле Болгар юлый!

Мулла Бикмәт угылы Нияз,
Гаклы кыска, фәһеме аз.
Догалары хөрмәте аз,
Нә хөрмәтле Болгар юлы!

Остадыңа дога кыйлса,
Халаикълар «амин» дисә,
Рәхмәте чук, гафу кыйлса,
Җәлил, Җәббар, Гаффар үзи [24].



Бикмәт улы Ниязның шигъри әсәре язылган дәфтәр. XIX гасыр башы

[24] *фикер идеңләр* — фикерләгез; *адын* — исемен; *зикер идеңләр* — кабатлагыз; *кидеңләр* — китегез; *бәндин* — миннән; *малы* — малны; *Мәннан* — Нигъмәт бирүче (Аллаһның күркәм исеме); *кисмеш* — кискән; *сәйер идеңләр* — сәяхәт итегез; *яри кылсын* — ярдәм итсен; *сахибе гар* — мәгарә ияләре, дини риваятьләрдә сөйләнгән изге затлар; *мөршид* — остаз; *вар* — бар; *мәкъбүл* — хуп; *вәли* — изге; *халаикъ* — халык; *деләб* — теләп; *нә хуш* — нинди хуш; *улса* — булса; *ирмеш* — икән; *сафи* — саф, суфый; *кяфи* — күп, җитәрлек; *кәнд үзенгә* — үзен; *җафи улган* — җәфалаган; *Мәүля* — Хуҗа, Яхшылык итүче (Аллаһның сыйфаты); *айган* — әйткән; *мәрсус* — тугры кол; *кави* — куәтле; *карин* — якын; *гали* — бөек, югары; *ирән* — ир-егет; *сил* — ташкын; *тик* — кебек; *шәүкы* — омтылу, кызыгу; *шәраб* — суфыйчылык әдәбиятында Аллаһка мәхәббәтнең дәрәҗәсен билдерә торган шигъри символ; *эчкем* — эчәсем; *йәйеб* — җәеп; *очкум* — очасым; *астанә* — суфыйларның остазы яшәгән, суфыйлар өчен кыйбла дәрәҗәсендәге изге урын; *кочкум* — кочасым; *тәвафчы* — юл гизүче, сәяхәтче; *айрык* — сазлык; *дәйеб* — дип; *әйдүрмез* — әйтербез; *нәкыль кылган* — вафат булган; *Кадыйр* — Кодрәтле (Аллаһның күркәм исеме); *гасый* — гөнаһлы; *йыглаб* — елап; *фыйск-у-фөҗүр* — азгынлык һәм бозыклык; *фәһем* — аң; *остад* — остаз; *чук* — күп; *Җәлил* — Олылык хуҗасы, Данлы (Аллаһның күркәм исеме); *Җәббар* — үз хөкемен барча галәмнәрдә ирештерүче көчле (Аллаһның күркәм исеме); *Гаффар* — Кичерүче, гөнаһларны ярлыкаучы (Аллаһның күркәм исеме); *үзи* — үзе.

Бу шигъри әсәрнең авторы, күп гасырлык татар суфыйчылык әдәбиятында шәрык мөселман традициясенең чагылышы рәвешендә, «кара йөзле Нияз гасый», шулай ук «гакылы кыска, фәһеме аз» дип, үзен яманлап һәм түбәнсетеп, «**мулла Бикмәт угылы Нияз**» исемле кеше икәнлеген төгәл күрсәткән.

Морад мулла исеме телгә алынган борынгы бәет булу фактын М.Гайнетдинов язып килде[25], әсәрнең тексты 16 дүртьюллык күләмендә беренче тапкыр 2006 елда XVIII гасыр татар әдәбиятына багышланган китапта басылып чыкты[26]. Анда бәеткә карата «Текстның кулъязмасы Зәйнәп Максудова архивында сакланган, язмышы билгесез. Аның күчермәсе әдәбиятчы Мәсгуд Гайнетдиновта булган, текст аның тарафыннан хәзерләнеп бирелде», дигән искәрмә урнаштырылган[27].

Әмма «XVIII гасыр татар әдәбияты: поэзия» исемле бу китапта мулла Морадка багышланган бәетнең авторы итеп Мостафа Нәзир угылы күрсәтелгән. Без моны ялгыш дип саныйбыз. Беренчедән, ул китаптагы бәет тексты ахырында «Үзем үлсәм китап калыр йадкәр, ушбуны йазучы Мостафа Нәзир углы дәйү беләсездер» дигән юллар шигъри әсәрнең авторы дип әйтергә нигез түгел. Чөнки, беренчедән, мондый «ошбуны язучы...» рәвешендәге юллар кулъязма дәфтәр яисә китапның иясен белдерә. Андый очракларда «язучы» дигән сүз автор мәгънәсендә булмыйча, шигырь-бәетләрне, җырларны яки башка төрле текстны үз дәфтәренә яки китабына күчерүче дигәнне аңлата. Икенчедән, бәетнең без бастыра торган текстында аның авторы «Мулла Бикмәт угылы Нияз» дип төгәл күрсәтелгән булуы әсәрне иҗат иткән кеше Мостафа Нәзир угылы түгеллеген белдерә. Дөрес, «XVIII гасыр татар әдәбияты: поэзия» китабында ул юллар «Мулла Бигъмәт — фәһме нияз» рәвешендә, мәгънәсе буталчык итеп бирелгән.

Бу шигъри әсәр вариантларыннан бер өлеше (сигез юлы) элегрәк тә басылганы бар иде[28], тик аларда мулла Морад исеме кергән юллар юк.

Шигъри әсәрнең текстына карата кайбер аңлатмалар бирү зарур. Эчтәлегеннән күренгәнчә, ул традицион бәет-мөнәҗәтләргә хас булганча, көйләп укылганлыгы аңлашыла. Аның кайбер дүртьюллыклары гүя үзләре үк көйләнеп-җырлап тора. Рухы һәм эчтәлеге белән бу текст ислам диненә тугрылык сакларга, «кичә-көндез фикер» итәргә, Болгар шәһәрен зиярәт итәргә, ягъни анда барырга өнди. «Ошбу юлның имамы вар» дип, әлеге гамәлнең җитәкчесе-юлбашчысы мулла Морад булуы һәм аның мөридләре күплеге белдерелә. Шәһри Болгар мөселманнар өчен рухи көч бирә торган үзәк буларак гәүдәләнә. Алдагы юлларда «фикер идеңләр көне-төне» диелгән өндәмә, алтынчы дүртьюллыкта «Ике күзең йомык улса, хәтерең һәм сынык булса» дигән сүзләр белән турыдан-туры үзаңны яңарту зарурлыгына юнәлтә. «Мөридләр чук уласыдыр» дип, бу гамәлгә иярүчеләр күбәячәгенә һәм әлеге фикернең көчәюенә өмет белдерелә.

«Ошбу дин кави улсун,
Хакъга карин вәли улсун!
Дәрәҗәсе көндин-көн
Халык ара гали улсун!»

— дигән дүртьюллыкта диннең куәтләнүен, аның дәрәҗәсе күтәрелүен теләү белдерелгән.

«Җанбактыдин җам арасы» дигәндә Ямбактыдан (хәзерге Татарстанның Спас районындагы татар авылы) Болгарга кадәрге араның ерак түгеллеге белдерелгән.

Болгарга хәтта диңгезләр, сазлыклар кичеп тә, Уфа (өязе дип аңларга кирәк) халкы да, Шушма[29] буйларында яшәүчеләр дә килергә кирәклеге әйтелгән.

«Кем?» — дәйеб сорасалар,
Без әйдүрмез: «Мулла Нәдүр!»

— дүртьюллыгында автор үзенең һәм фикердәшләренең мулла Нәдер Уразмәтев волосте кешеләре булуын белдергән. Шушы дүртьюллыкның соңгы ике юлыннан аңлашылганча, ул

вакытта инде Нәдер мулла мәрхүм булган. Тарихта мәгълүм бу шәхес 1758 елда дөнья куйган[30]. Ә мулла Морадның Нәдер волостена нисбәтле булу-булмавы турында тулырак мәгълүматны моңарчы язган идек[31].

Архив чыганакларыннан билгеле булганча, 1769 елда изге Болгар җирендә меңләгән мөселман татарлар җыелган, ә 1771 елда бу хәрәкәтнең җитәкчесе мулла Морад кулга алынган. Шушы даталарны күздә тотканда һәм шигъри әсәрнең өндәү рухында булуын исәпкә алганда, Бикмәт улы Нияз аны 1769-1771 еллар арасында —Морад мулла хәрәкәтенең иң югары күтәрелгән чорында иҗат иткән, дип фаразларга мөмкин.

Әлеге шигъри әсәрнең хәзерге вакытта берничә кулъязма күчермәсе билгеле. Аның язылуына, һичшиксез, Морад мулла хәрәкәтенең тәэсире булган. Гомумән, Морад мулла хәрәкәте Идел-Урал буйларында яшәгән мөселманнарның тарихи үзаңын күтәрүгә зур йогынты ясаганлыгын танымыйча мөмкин түгел.

С.Алишев, М.Гайнетдин, Р.Әмирханов, Д.Исхаков, И.Измайлов һәм башка галимнәр Морад мулланың иҗтимагый фикер үсеше тарихындагы урынын билгеләдe, татар-башкортларның Пугачёв күтәрелешендә актив катнашуына аның йогынтысы булган, дип язды. Тик бу мәсьәләдә тарихчы Динә Мостафина Морад мулланың дәүләтчелекне торгызу идеясе тарафдары булганлыгын шик астына ала, ул гына да түгел, XVIII гасыр кешесенә үз чорына хас булмаган этник үзаң төшенчәсен тагу бөтенләй абсурд, дип яза. Д.Мостафина мулла Морадның ишаннарга хас, акыл һәм мантыйкка таянмый торган, илаһи хис-тойгыларга бәйле кайбер кыланмышларын XVIII гасырдагы Сенат тикшерүчеләре мисалында табиблык диагнозына мохтаҗ дип бәяли[32].

Мондый фикерләр белән килешеп булмый. Чөнки Казан ханлыгы яулап алынганнан соң берничә гасыр дәвамында татар-башкорт күтәрелешләре һәм яулары еш булып торганлыкны, шул ук вакытта элек-электән әллә ничә дәүләт тоткан татар халкының бер фидакяр улы Морад мулла башына андый уй килү ихтималын без кире какмыйбыз. Халык хәтерендә тарихи үткәннәр, шул исәптән Болгар һәм Казан ханлыклары турындагы истәлекләр саклнган. Җимерелгән Болгар белән Алтын Урда дәүләтләрен һәм Казан ханлыгын юксыну һәм сагыну, изгеләштерү татар халкының күңел авазында — тарихи бәетләрендә аермачык чагылыш тапкан. Шәһри Болгарны Ислам дине кабул ителгән төп үзәк буларак, мөселман татарларның изгеләштереп каравы, хәрабәләрен булса да күрергә бару, андагы борынгы бабайларның изге рухына дога кылу кебек йолалар күптәннән килгән тарихка ия. Болгар шәһәренә багышланган күп санлы бәетләр моның ачыктан-ачык дәлиле[33]. Халык күтәрелеше вакытларында үткәннәргә мөрәҗәгать итүне, аерым алганда мулла Морад җитәкчелегендәге хәрәкәт борынгы Болгарны торгызу фикеренә таянганлыгы турында тарихчы Фәрит Шәкүров та язган иде[34].

Д.Мостафинаның Морад мулланы: «Батырша эшен дәвам итүче дип санау дөреслеккә туры килеп бетми, аның омтылышлары җәмгыятьтә киң хуплау тапмаган, тарафдарлары да 11 генә кеше (дөрес, аларның да аудиторияләре булгандыр)», — дигән фикерләрен[35] кабул итә алмыйбыз. Югыйсә, Морад мулла башлангычы белән 11 яки берничә дистә кеше генә түгел, ә йөзләгән, хәтта меңләгән татар-башкортларның изге Болгар җирләрендә туплануын нәрсә белән аңлатырга мөмкин соң?! Морад мулланың үзенә һәм ул башлаган хәрәкәткә мәдхия рәвешендәге шигъри әсәрнең кулъязма күчермәләре табылып торуы да — үз вакытында бу фикернең җәмгыятьтә таралган булуын дәлилли. Андагы:

«Ике күзең йомык улса,
Хәтерең һәм сынык улса»,

— дигән юллар халык үзаңының дәрә-

җәсен күрсәтә торган дәлил булуына ике күзне йомып, күрмәгәнгә салыну, әлбәттә, урынсыз булыр иде.

Шулай ук:

«Уфа халкы анда барса,

Шушма буйлар һәм барасы!»

— дигән сүзләр турыдан-туры өндәү булганлыгы белән дә санлашмыйча мөмкин түгел.

Татар-башкортларның дини һәм милли, иҗтимагый һәм сәяси изелүдән котылу өчен күп гасырлык көрәше чылбырында Батырша күтәрелешеннән соң Пугачёв явына кадәрге арада булган мулла Морад хәрәкәтенең тарихи әһәмияте, һичшиксез, зур.

Мулла Морад хәрәкәтенең калыбы һәм рәвеше нindилеккә карамастан, татар-башкортларның Пугачёв восстаниесендә катнашуына аның тәэсире булу белән берлектә, XVIII гасыр ахыры-XIX гасыр башында Таҗетдин Ялчыгол кебек каләм әһелләренә «Тәварихы Болгария»ише хезмәтләр язарга йогынты ясаган. Т.Ялчыгол әсәрләре соңгырак дәвер галимнәре тарафыннан ничек кенә тәнкыйтьләнсә дә, аларның үз чорына күрә, халыкның үзаңын уятып, тарихи тамырлар белән кызыксынуга этәргәнлеген инкяр итеп булмый. Ялчыголның Болгар тарихына бәйләп язылган әсәрләрендә буталчык һәм уйдырма мәгълүматлар булса да, алар халык арасында киң популярлык казанган. Әлеге әсәрләрнең күп таралган һәм укылган булуын хәзерге вакытка бер йөзгә якын кульязма күчермәләре табылуы[36] раслап тора.

Морад мулланың «мулла Морад» рәвешендә, ягъни «мулла» сүзе аның исеме алдында әйтелүе-язылуы тотрыклы хәлендә үз чорыннан ук калган, дияргә нигез бар. Рус телендә язылган архив документларында «мулла Морад» дип язылган кебек, Бикмәт улы Ниязның шигъри әсәрендә дә ул нәкъ шулай ук телгә алынган. Мөхәммәтгариф Морадый язмасында да юлдашы Мөхәммәтшәриф хәзрәтнең «мулла Морад» дип эндәшкәнлеге теркәлгән.

***

Мәгълүмат тулылыгы өчен мулла Морадның үзе һәм аның ата-бабалары турында моңарчы кайбер китапларда ялгыш аңлатмалар булганлыгын да әйтергә кирәк. Морадның нәсәбе хакында галим Мәсгуд Гайнетдин: «Г.Исхакыйның «Сөннәтче бабай» хикәясендә «сөннәтчеләр шәҗәрәсе»ндә аның «нәсел агачы» турында хәбәр сакланган булуы ихтимал. Ф.Әмирхан бабасының бабасының бабасы Морад та шул бер үк шәхес булырга мөмкин», — дигән бер фараз язган иде[37]. Шуннан соң М.Гайнетдин бу карашын тагын да куәтләп язды[38].

Морад мулла турындагы мәгълүматларны җентекләп өйрәнгәч, М.Гайнетдинов фаразлары расланмады. Бу мәсьәлә турында артык сүз озайтырга ихтыяҗ юк, чөнки М.Гайнетдиннең бу фикерләре дәлилләнмәвен тәфсилләп язган идек[39]. ■

---

[25] Гайнутдинов М. Мурад мулла // Духовная культура и татарская интеллигенция… — Казань, 2000. — С.8; Гайнетдинов М. Морад мулла // Татар зыялылары: тарихи портретлар… — Казан, 2003. — Б.7; Гайнетдинов М. Мәңге тоныкланмас көзгебез… — Казан, 2006.— Б.305.

[26] XVIII гасыр татар әдәбияты: поэзия / [төз. М.Әхмәтҗанов]. — Казан, 2006. — Б.121-124.

[27] Шунда ук. — Б.336.

[28] Кульязмалар тасвирламасы. Өченче бүлек / [төз. А.Фәтхи]. — Казан, 1968. — Б.6; Татар әдәбияты тарихы: алты томда. Т.1. — Казан, 1984. — Б.390.

[29] Шушма исеме белән аталган елгалар Татарстан Республикасының төньяк өлешендә дә, көньяк-көнчыгыш төбәгендә дә бар.

[30] Амирханов Р., Габдуллин И. Надыр Уразметов // Әлмәт — Альметьевск. — Казань, 2003. — С.295.

[31] Гали авылы тарихы… — Казан, 2014.— Б.36.

[32] Гасырлар авазы = Эхо веков. — 2007. — №2. — Б.97-98.

[33] «Гәүһәр Болгарга килдем…»: тарихи бәетләр / [төз. Мәрданов Р.]. — Казан: «Милли китап» нәшр., 2013. — 128 б. — («Татар археографиясе» сериясе; 12 нче китап).

[34] Шакуров Ф. Развитие исторических знаний у татар до февраля 1917 года. — Казань: изд-во ун-та, 2002. — С.15.

[35] Гасырлар авазы = Эхо веков. — 2007. — №2. — Б.101.

[36] Ялчыгол Таҗетдин. Тәварихы Болгария. — Казан: «Хузур» нәшр., 2014. — Б.5.

[37] Гайнетдинов М. Мәңге тоныкланмас көзгебез… — Б.305.

[38] Гайнетдинов М. Мулла Мурат // Гасырлар авазы = Эхо веков. — 2007. — №2. — С.82.

[39] Гали авылы тарихы… — Б.49-53.

ЧАЛЛЫ-ЧИБӘРКҮЛ АРАСЫ, УРАЛ КИЧЕП БАРАСЫ

Людмила Белоусова

ЧИБӘРКҮЛМЕ — ӘЛЛӘ ЧУАРКҮЛМЕ?

Уфа-Чиләбе юлында бер карагандa киртә кебек утырган, ә эченә килеп кергәч, кыргый матурлыгы, борма-борма юллары, өскә авам дип торган текә кыялары, тауны кисеп үткән тар тоннель юллары, җәелеп агучы саф, салкын сулы елгалары белән гаҗәпләндергән дә, сокландырган да Урал тауларын узгач, күлләр иле башлана. Татарстаннан йөзләрчә чакрым ераклыкта булсак та, күлләрнең исемнәре гаҗәпләндерә: **Алакүл, Акчакүл, Еланчык, Ишкүл, Кисегач, Комкүл, Кечекүл, Сөнкүл, Ташкүл, Тирәнкүл, Озынкүл, Чибәркүл...**

Кисегач, Тирәнкүл, Табанкүл, Сөнкүл, Чибәркүл, Еланчык, Кондра күлләре — без килергә чыккан Чибәркүл районы территориясендә. Районның исеме дә иң зур күл саналган Чибәркүл белән бәйле. Биредә бер күрергә зарыккан карендәшләребез — керәшеннәр, үзләренчә әйтсәк — нагайбәкләр, бакаллар яшәп ята. Алар яшәгән **Ключевка (Лягушино), Балатау (Болотово), Варлам (Варламово), Папау (Попово)** авыллары мәйданы 8 мең квадрат километрга җәелгән Кондра күле буенда урнашкан. Үзе шәһәр, үзе район үзәге булган **Чибәркүл (Чебаркуль)** шул ук исемдәге күл буенда утыра. «Күлнең исеме башкортча **«Чыбар күл» («Пёстрое озеро»)** була, дип аңлаттылар безгә. Татарчалаштырып, «Чибәркүл» дип тә йөртәләр.

«ТЫНЫЧЛЫК КҮГӘРЧЕННӘРЕ»

Керәшеннәр бу соклангыч матур якларга XIX гасыр уртасында, патша Указы нигезендә, Башкортстаннан күчереп утыртылганнар. 1840 елда Россия хөкүмәте «Оренбург казак гаскәрләре белән идарә итү» дигән Положение кабул итә. Положениедә казакларның санын арттыру, хуҗалыкларны ныгыту, казак хезмәтен үстерү буенча реформалар карала. Башкортстанның Бакалы, Нагайбәк станицаларында яшәүче керәшен казаклары да Оренбург гаскәре составында Россия дәүләт структурасының бер звеносы булып исәпләнә башлый. Дистәләгән еллар буена үзара сугышып көн иткән башкортлар белән кыргызкайсаклар арасында казак станицаларыннан торган «Оборона линиясе» төзелә. Шул «линия»не ныгыту өчен, керәшен казакларын күчереп утыртып, 1842 елда патша хөкүмәте «әчке политик» мәсьәләне хәл итә...

ҮЗГӘРТЕП КОРЫЛГАН «БОЛЬШЕВИК»

Хәрби хезмәттә торып, авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнгән казак-

лар өчен XX гасырның беренче яртысы үтә дә авыр була: Япон, I һәм II Бөтендөнья, гражданнар сугышлары, революция, репрессияләр, 1901, 1911, 1921, 1931 елларда килгән корылык һәм ачлык еллары зур сынаулар китерә. Шушы афәтләрне исән-сау кичкән, Совет власте елларында шактый ныгып калган, инде бүген перестройка казаларын кичереп ятучы Попово авылына кичке эңгер төшкәндә генә килеп җиттек.

Төз, киң урамнары, каты агач карагайдан салынган йөзәр еллык йортлары Поповоның, үзләре әйтмешли, Папауның шактый нык авыл икәнен күрсәтеп тора. Нарат урманы эчендә утырган бу авыл кайчандыр бик авыр тормышлы булып, соңыннан миллионер колхозга әйләнгән. 25 ел буена «Большевик» колхозын җитәкләп, авылны районның үрнәк хуҗалыгына әйләндергән авылдашлары Иван Афанасьевич Уряшевны әле дә булса сагынып сөйлиләр. Иртән радиодан бар авылның хәлен белешә, кайсы бригаданың кайда эшләячәген әйтә, «Кыстыбый, тәбикмәкләр белән чәй эчтегезме? Балаларыгызны мәктәпкә озаттыгызмы? Тамагыгыз тук, өстегез бөтен. Инде эшкә чыгыгыз!» — дип әйтә торган иде. «Эшкә җырлап бара, җырлап кайта торган идек», — дип искә алдылар аны авыл әбиләре.

Кайчандыр авыл янәшәсендә уран чыгаручы рудник гөрләп эшләп торган. Перестройка давыллары колхозның да, рудникның да астын өскә әйләндергән. Бүген авылда бернинди производство да, авыл хуҗалыгы объектлары да юк. Культура йорты, китапханәсе, урта мәктәбе, балалар бакчасы гөрләп эшләп торган авыл терәксез калган. Янәшәдә урнашкан, югары сыйфатлы мәрмәр чыгаручы Коелга руднигы җитәкчелеге белән сөйләшүләр алып баралар, диделәр безгә район җитәкчеләре. Бәлки, авылда берәр производство ачу мөмкинлеге табылыр…

КЕМ АРБАСЫНА УТЫРСАҢ…

Папауга килеп чыгуыбыз очраклы түгел. Узган елның декабрь аенда Казанда узган керәшен яшьләре Форумына шушы авылдан делегация килгән иде. Укытучылары Надежда Уряшева җитәкчелегендәге яшьләр, форумнан кайткач, авылда «революция ясаганнар». Дистәләгән еллар буена үз кабыкларында бикләнеп яткан папаулылар хәзер Татарстанда үзләре кебек керәшеннәрнең күпләп яшәгәнен, туган телләрендә сөйләшкәнен, үз йолалары белән яшәгәнен, аларга да ярдәм кулы сузарга әзер икәннәрен белә. Аларның да арбадан төшеп каласылары килми… Татарстан кунаклары белән очрашуга Папау гына түгел, Варлам, Балатау, Лягушино керәшеннәре дә җыелды.

«ФРАНЦУЗЛАР» БЕЛӘН «ЗУБКАЛАР»

Авыл белән якыннанрак танышу өчен безне Папауның хөрмәтле кешесе, «аяклы энциклопедиясе» Валентина Ивановна Уряшевага җибәрделәр. Ул элеккеге хуҗалык җитәкчесе, атаклы Иван Уряшевның кызы. Гомер буе авыл мәктәбендә тарих укыткан. Пенсия яшендә булса да, авыл халкы аңа зур өметләр баглый. Безнең катнашта узган авыл җыенында район администрациясе Валентина Ивановнаны балаларга туган тел өйрәтү буенча җаваплы кеше итеп билгеләде.

Мамау ягыннан «Зубкалар», тәтәү ягыннан «французлар» без, дип таныштырды ул үзе белән. Карт бабам малай чакта, тырыша-тырмаша, урысча өйрәнгән. Урыс авылларында йөреп кайткач, авылдашларына: «Мин урысчаны шытырдатып өйрәндем, урыс мине мактады, «Зубка» дип әйтте», — дип сөйләгән. Тәтәү ягыннан бабаларымның бер агай-энесе Франциягә походтан, Париждан үзенә хатын алып кайткан. Ул хатын татарча да, урысча да бер авыз сүз белмәгән.

Шуннан бирле без «французлар» булып йөрибез. Шулай да, ул җиңгәбез француженка түгел, төрек хатыны булгандыр, дигән уебыз бар. Бабаларыбыз Франциядә генә түгел, Германиядә дә сугышканнар, күп походларда булганнар. Лейпциг, Кассель, Фершампенуаз — барысы да алар аяк баскан җирләр.

1904 елдагы Япон сугышында зур батырлыклар күрсәткәннәр. Безнең станицаларда тупланган 11 нче казак полкы Маньчжуриядә ике ел сугышкан. Күрше, Травники авылында Япон сугышында башын салган казакларга памятник бар. Ул 1910 елда ук ачылган, 186 казакның исеме уеп язылган. Араларында таныш фамилияләр дә очрый…

Минем карт бабам сөйли торган иде. Япон сугышыннан атлар белән дүрт ай кайтканнар. Дальний Востокта Пыкрау көнне бер авылга төнгә туктаганнар. Үзебезчә сөйләшкәннәрен ишетеп үз колакларына үзләре ышанмаганнар. Бу керәшен авылы булып чыккан. Пыкрау пироглары белән сыйлаганнар, мунчалар керткәннәр. «Кунак булып, тагын юлга кузгалдык,- дип искә ала торган иде бабай. — Кайларга гына илтеп чыгармый бу нужа бабай адәм баласын…»

«ИВАН ГРОЗНЫЙ»

«Зубкалар» да, «французлар» да авылның асыл нәселләре булдылар, дип сөйләвен дәвам итте Валентина Ивановна. Бабам Зубка Микулае (Юртеев Николай Иванович) 1929 елда төзелгән «Уракчы» колхозының беренче председателе булган. Соңрак, колхоз «Большевик» булып үзгәртелгәч, хуҗалыкны минем атам — француз Иваны җитәкләгән. Тик аны «француз» дип түгел, «Грозный» дип йөрттеләр. Бик тырыш, таләпчән иде. Үзлегеннән урысча өйрәнеп, башта кызыл диплом белән Пермь финанс-экономика техникумын, соңрак Оренбург авыл хуҗалыгы институтын бетерде. Сугыштан капитан званиесендә кайткан. Кайту белән колхоз дилбегәсен тоттырганнар. Дәүләт делегациясе составында чит илләргә йөрде, чит технологияләр өйрәнде, экспериментлар уздырды. Үзен дә зурладылар, орден-медальләр белән бүләкләделәр. Безне иң беренче итеп басуга чыгара, туганнарны иң авыр урыннарга куя торган иде. Эшне үзе башлап эшләде, кешегә үрнәк күрсәтте. Яраткан киеме — солдат галифесе, сатин косоворотка булды. Гадел булды, кеше рәнҗетмәде, шуңа күрә, «Грозный» булса да, яраттылар.

УВЕЛЬКА НАГАЙБӘКЛӘРЕ

Безнең Папау авылының тарихы бик зур, ди Валентина Ивановна. XIX гасыр башында аңа качкын урыслар нигез салган. Беренче килеп урнашкан Попов фамилияле урыс кешесе хөрмәтенә «Попово» дип атаганнар. 1842 елда Башкортстаннан, обозларга төяп, керәшен казакларын китергәннәр.

Килүчеләрне 12 авылга урнаштырганнар. Җиде авылны Гөмбәй елгасы буена (хәзерге Нагайбәк районы), 5 авылны Увелька елгасы буена (хәзерге Чибәркүл районы) урнаштырганнар. Аралар 200 чакрымнан артык. Минем бабамның бабасы 12 яшьлек малай булып килгән. Ул әйтеп калдырганнарны бабай безгә дә сөйли торган иде. Карт бабаларыбыз Гөмбәйгә китүче агай-энеләре белән елашып аерылышканнар. «Безнең якларга бер килеп чыгарсыз, тәрәзә рамымда безнең нәсел тамгасы булыр, безне шуннан танып табарсыз», — дигән минем бабам туганнарына. Безнекеләр, беренчеләрдән булып, йорт җиткергәннәр. Иске йортыбызның тәрәзә рамында чыннан да, сәнәк формасындагы тамга ясалган иде. Туганнары бабамны килеп тапканнар, бик куанганнар. Увелькалар белән Гөмбәйләр элегрәк бик кунакка йөрешкәннәр, хәзер генә аралар ера-

гайды, ди Валентина Ивановна. Иң зур кунакларга гына каралган түр урынны, бездә хәзер дә «Гөмбәй кунагы урыны» дип йөртәләр. Унике авыл, аралар ерак булса да, бер гадәт, бер «мораль кодекс» белән яшәгән. Элегрәк бездә, мактасалар да, хурласалар да, «унике авылга дан», «унике авылга гыйбрәт» дип сөйләшәләр иде…

Килүчеләрне кочак җәеп каршы алганнар, дисәм, ялган булыр. Урысчалары ипи-тозлык та булмаган, җитмәсә, казакларга җир, өй салырга урман бүлеп биргәннәр, ә урыслар, казак хезмәтендә тормагач, җирсез. Безнекеләр ашлык үстергән, мал асраган. Урыслар бакча тотканнар. Аларда шалкан, кишер, суган, кәбестә бик уңган. Иген уңмаган елларда керәшеннәр, урысларга ялланып, бакчада хезмәт иткән. Җәй буе эшләгәне өчен бакча хуҗасы Пыкрау көненә (14 октябрь) азрак кишер, кәбестә, шалкан, суган биргән. Түләү шуннан артмаган.

Көз җиткәч, безнекеләр урысларга тегермәнгә барган. Иң беренче булып килсәләр дә, 4-5 көн чират торганнар. Кеше беткәч кенә, безнекеләрнең чиратлы җиткән. Менә шулай башлаганнар монда тормышны безнең бабайлар…

«КАЙТАМ ӘЛЕ ПАПАУЫМА…»

Яшьләр Казанга формуга барып кайтканнан соң, авылда тормыш үзгәрде, ди Валентина Ивановна. Җитәкчеләре Надежда Уряшева, авыл халкын җыеп, җыен уздырды. Йокыдан уянгандай булдык. Балаларыбыз телне белми, тамырларыбыз корый бара икән бит…

Без моны үзебез дә күреп кайттык. Шушы ярты ел эчендә ике коллектив төзелеп, Чибәркүл нагайбәкләре беренче тапкыр Бажов фестивалендә катнашканнар. Дөньяга беренче чыгуларында ук төрле номинацияләр буенча җиде дипломга лаек булган Папаулар район администрациясен дә, башкаларны да таң калдырган. Балалар коллективына да, зурларга да костюмнар тегеп биргәннәр. Папау авылында хәзер туган телдә сөйләшү модада. Авылда узган гаилә бәйрәмендә «Кыз сорау» йоласын күреп, нагайбәк җырларын тыңлап, балаларның «Нагайбәкчә кадриль» биегәнен карап кайттык.

«Кайтам әле Папауыма
Сызылып таңнар атканда»,

дип җырлады авыл хоры.

Сүзләре, көе Виталий Агаповныкы булса да, башкарулары үзләренчә иде.

Кайтырлар, болай булса… ■

Сулдан уңга: Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалим, Равил Фәйзуллин, Сибгат Хәким, Ренат Харис, Рәдиф Гаташ. Гыйнвар, 1979 ел

СҮЗ ҺӘМ СУРӘТ

Рәдиф Гаташ

Әлеге рәсем турында вакытында Сибгат ага да язып чыккан иде инде. Шигырьгә бездән алда килгән «тыйнак, әдәпле Илдар Юзәйләр, Шәүкәтләр буыны» белән чагыштырып, иҗат түгел, үҗәт холык, яшәү рәвеше, иҗатны күрсәтә белү «стиле» буенча үзгәлегебезне күргән, күрсәткән иде.

Барлык хыяллар уртак булган, җырдагыча, «тал тамырлары кебек үскән» бергә чаклар, матур чаклар сагындырмый димени! Шуңа да, XX гасырны озатканда:

Алтмышынчы еллар! Шигъри табында
Без, «биш йолдыз», тостлар чөйгән чагында,
Ант эчтек бит — һаман тугры калырга
Гасыр ахырында һәм... аргы ягында?! —

дип язган идем мин.

Дөрес, бергә-бергә киңәшеп, Бауман урамындагы фотоательега кереп, Сибгат аганы да чакырып, истәлек өчен шушы рәсемне алдырганда мондый уй-фикерләүләр юк иде әле. Алда — өметләр, шигъри хыял һәм бәхетләр вәгъдә иткән Мәңгелекне генә күрә идек. Мәңгелек — шул ук, без генә олыгайдык. Ә фото — гел яшь кала... ■

КАРА ГЕНЕРАЛ

Рәис Зарипов

Ниһаять, тагын бер катлаулы мәсьәләне ачыкларга да вакыт җиткәндер. Совет хакимияте чорында татар шәхесләрен башка милләт (аеруча башкорт) вәкилләре итеп күрсәтү буенча үткәрелгән чирле һәм явыз вазгыять Даян Мурзинны да урап үтмәде. Мәскәү тарафыннан бу ямьсез эш яһүди милләтеннән булган язучы Генрих Борисович Гофманга йөкләнде. Бөек Ватан сугышында эскадрилья белән командалык иткән өлкән лейтенант (соңыннан — полковник), очучы-штурман, Советлар Союзы Герое, 22 ел гомерен хәрби хезмәткә багышлаган ветеранны андый адымга барырга нәрсә мәҗбүр итүен аңлап та, аңлатып та булмый. Билгеле инде, мондый гамәлне Уфада шатланып һәм энтузиазм белән кабул иттеләр һәм җиң сызганып, Суслов идеологиясе буенча салынган тайгак юлдан салулап киттеләр. Әлеге ялганның масштабларын тулырак күзаллау өчен, «Кара генерал» китабы белән бәйле хикмәтле хәлләрне җентекләбрәк бәян итүдән башка чара юк.

Генрих Гофманның **«Кара генерал»** китабы 1970 елда дөнья күрә. Анда Даян Мурзинның һәм аның көрәштәшләренең Словакиядәге, Богемиядәге һәм Моравиядәге көрәше сурәтләнә. Бер үк вакытта, югары чиннардагы алман ягы вәкилләре гамәлләре дә бик җентекле һәм шактый мавыктыргыч итеп бәян ителә. Автор аеруча дошман тылында хәрәкәт итәчәк партизаннар отрядының булачак командиры надпоручик Ян Ушьяк (Мурзиннан аермалы буларак, ул аны Ушияк дип атый) турында бик югары фикердә, аны гел үрнәк итеп куя. Гофман язуына караганда, Мурзинны надпоручик Ушьяк һәм аның дусты **Милек** белән, Киевтан көнбатышка таба урнашкан **Святошино** дип аталучы дача бистәсендәге диверсантлар әзерләүче махсус мәктәп башлыгы подполковник **Богомолов** таныштыра.

Ашханәдә Ян Ушьяк белән Ян Милек үзләренең словак милләтендәге коммунистлар булуларын, 1941 елда алман армиясенә эләгүләрен һәм Одесса янына китерелүләрен бәян итәләр. Үткер Мурзин, сөйләштерә торгач, аларның үз ватаннарын басып алган Гитлерга хезмәт итәргә теләмичә, дивизияләре беренче сугышка керү белән үк Кызыл Армия ягына чыгулары һәм 1 нче Украина фронты составында гитлерчыларга каршы сугышулары турында да белеп өлгерә. Ярар, Гитлерның Словакияне басып алмаганын, 1939 елда гына оешкан шул дәүләтнең президенты **Йозеф Тисоның** СССРга каршы ике словак дивизиясен

Ахыры. Башы журналның 1 нче санында.

Даян Мурзин. 90 нчы еллар ахыры. Уфа

Даян Мурзин беркайчан да татарлыгын яшермәгән, үз милләтеннән йөз чөермәгән.

җибәрүен язучы белмәскә дә мөмкин. Тик менә аның, Кызыл Армиягә әсир төшкән Ушьякны Уфа каласын, аның халкын, аерым алганда башкортларны, аларның гореф-гадәтләрен биш бармагыдай белүче шәхес итеп сурәтләве көлке дә, кызганыч та:

«— О, судруг Мурзин! <...> Син каян, кайда тудың?

— Мин Уфадан, — диде Мурзин көрсенеп. — Андый кала турында ишеткәнегез юкмы?

— О! — Ушияк тагы да җанлана төште. — Ул бит безнең икенче ватаныбыз. Ул Бозаулыктан ерак түгел ич. Без анда (Бозаулыкта — Р.З.) үзебезнең яңа армиябезне оештырдык. Анда Свобода, Клемент Готвальд яшәде.

ВОЕННЫЙ БИЛЕТ
ВК № 220622
Мурзин
(фамилия)
Даян Баянович
(имя и отчество)
Личный № Б-969243

ВК № 220622
1. Число, месяц, год и место рождения 20 декабря 1921 г. д. Старые-Балыклы Бакалинского района Башкирской АССР
2. Национальность Татарин
3. Военный билет выдан Ленинским райвоенкоматом г. Уфы Башкирской АССР
февраля 1968 г.

<…> Мин Уфаны бик яхшы беләм. Анда мәрхәмәтле, яхшы халык яши».

Автор язганнан чыгып кына, «яңа армия»нең кайсы калада оештырылуын төшенүе читен. Укучы Уфада дип тә, Ырынбур өлкәсенә керүче һәм Башкортстан башкаласыннан 340 чакрым ераклыкта урнашкан, Казакъстан чигендәге Бозаулык каласында, дип тә уйларга мөмкин. Инде «яңа армия»гә ачыклык кертик. 1941 елның 27 сентябрендә совет-чехословак килешүенә кул куела һәм шуңа ярашлы рәвештә, 1942 елның 5 гыйнварында Бозаулык каласында 1 нче аерым Чехословак пехота батальоны оеша башлый. Оештыру мәсьәләләрен Лондонга сыенган сөргендәге хөкүмәт хәл итә, ә оператив яктан батальон совет командованиесенә буйсына. 974 кешедән торучы батальон 1943 елның 30 гыйнварында хәрби ант бирә һәм фронтка озатыла. Батальон командиры вазифасына **Ярослав Кратохвил**, ә аның урынбасары итеп Людвиг Свобода билгеләнә. 1943 елда **Новохопёрск** каласында батальон базасында 3,5 мең хәрбине берләштерүче 1 нче аерым Чехословак пехота бригадасы оеша. РККА Генштабы башлыгы, Советлар Союзы Маршалы **Александр Васильевский** директивасына (10.04.1944) ярашлы рәвештә, 1944 елның августында **Черновцы** каласы янында әлеге бригада базасында 1 нче Чехословак армия корпусы оеша. **Бенеш** хөкүмәте, 19 меңнән артык хәрби тупланган корпус командиры итеп генерал-лейтенант Ярослав Кратохвилны куя. Әмма сентябрь аенда совет командованиесе басымы белән ул үз вазифасыннан бушатыла. Корпус белән аның урынбасары бригада генералы Людвиг Свобода командалык итә башлый. 1945 елда дивизия генералы званиесенә үрләтелгән Свобода Чехословакиянең милли саклану министры итеп билгеләнә, ә командалык бригада генералы **Карел Клапекка** күчә.

Күргәнебезчә, Бозаулыкта бернинди дә «яңа армия» оештырылмый. Сүз фәкать хәрбиләр саны меңгә дә тулмаган батальон турында гына барырга тиеш. Шулай ук подполковник Богомоловның Ян Ушьяк белән Ян Милекның «Свобода корпусы»нда хезмәт итүләре турында искәртүе дөреслеккә туры килми. Корпус белән бригада генералы Людвиг Свобода командалык итәргә алынган вакытта, Словакиядә беренче чыныгу үткән

Мурзин һәм Ушьяк отряды Моравияга үтеп керү омтылышлары ясый.

Гофман тасвирлаган Ян Ушьякның шактый гына «башкорт» мәкальләрен белүе дә урынлы гаҗәпләнү тудыра:

«— Мин әле менә синең башкорт мәкален искә төшердем. Шуны әйтүем.

— Нинди башкорт мәкале тагы?

— Сездә, Башкириядә ничек әйтүләрен исеңә төшер әле, Юрка. «Кунак — ишәкнең хуҗасы». Димәк, син хуҗа әйткән бөтен нәрсәне дә үтәргә тиеш. <...> Ушьяк көлеп җибәрде.

Мурзин да башкорт мәкален исенә төшереп, елмаеп куйды...

— Әгәр тау Мөхәммәт янына килмәсә, Мөхәмәт үзе тау янына бара.

— Ян, син бу мәкалне дә беләсеңмени? — дип гаҗәпләнүен белдерде Мурзин.

— Мин күп беләм. Болар халыкның зирәклеген күрсәтә. <...> Сездә: «Тавыкның да йөрәге бар», — диләр. Алманнарда исә бу: «Амаисен хабен зух галле». Мәгънәсе шул ук».

Кызыгы шунда: үзе яратмыйча, «бошлар» дип атаучы алман халык мәкальләрен дә белә икән бит әле дөньякүләм танылган, күренекле «лингвист» Ян Ушьяк. Ә ул әйтем башкортча бик мәзәк, бөтенләй башка төрле яңгырый, имеш. Ягъни, элеге «башкорт мәкале»н русчадан («И у курицы есть сердце») кире тәрҗемә иткәндә, мәгънәсенең тамырдан үзгәрүе ачыклана:

«Сездә, мәсәлән, тавык төшенә тары керә», — диләр.

Ягез инде, «Тавыкның да йөрәге бар» белән «Тавык төшенә тары керә» арасында нинди уртаклык булсын! Әмма автор белән тәрҗемәче раславынча, болар — бер үк мәкаль.

Хатыны Надежда белән. 70 нче еллар

Әнә шулай татарның күренекле шәхесләрен, мирасын башкаларга өләшү һәм аның үзен бер пешмәгән, мескен милләт итеп күрсәтү өчен махсус эшләнгәндер мондый пычрак гамәлләр. Гел шулай башыңны төеп, мыскыллап торсалар, милли горурлыкның юкка чыгуына, маңкортлашуның көчәя баруына һич тә аптырыйсы юк...

Гофман язуына караганда, «башкорт баласы» Мурзин «үз халкы»ның борынгы гореф-гадәтләрен дә бик яхшы белгән икән:

«Яралары төзәлә башлады, аяк сызлавы да басыла төште. Мурзин борынгы башкорт йоласын кулланып, ярасын чи ит (сало) белән каплаган иде. Шул да ярдәм итте сыман».

Совет вакытында гамәлдә булган

мондый сәер сәясәтне аңлавы читен. «Кара генерал»ның башкортчага тәрҗемә ителгән титул битендә үк «башкорт егете Даян Баян улы Мурзин» дип укучы күңеленә корт салып кую кемгә кирәк иде? Мондый мәгънәсезлектән кем ота? Ничек шундый ялган таратырга мөмкин?! Даян Мурзин беркайчан да татарлыгын яшермәгән, үз милләтеннән йөз чөермәгән ләбаса! Хәтта, 1941 елның җәендә Рига өчен барган сугышларда яраланып, үлем көтеп ятканда да, беренче чиратта, үз милләтен искә төшерә һәм моны тарих өчен китабына да теркәп калдыра:

«Мин чиста, җыештырылган урында ятам. Әгәр берәр нәрсә була калса, искә алыгыз: мин Даян Мурзин, унтугыз яшьтәмен, милләтем — татар, кече политрук, дошманга каршы намус белән сугыштым һәм соңгы сәгатем сукканда, штык атакасы вакытында үземә кадауларына юл куюым кызганыч».

Тагын нәрсә кирәк соң хакыйкать өчен? Ни җитми? Бәлки болар СССР «нык үскән социализм»га аяк баскан дәвердә, татар милләтенә каршы даими оештырылып килгән мәкерле сәясәтнең чираттагы дулкыны башлануын аңлата торгандыр. Әнә шулай татарның күренекле шәхесләрен, мирасын башкаларга өләшү һәм аның үзен бер пешмәгән, мескен милләт итеп күрсәтү өчен махсус эшләнгәндер мондый пычрак гамәлләр. Гел шулай башыңны төеп, мыскыллап торсалар, милли горурлыкның юкка чыгуына, маңкортлашуның көчәя баруына һич тә аптырыйсы юк…

Менә шундый хәлләр. Мондый вазгыять шартларында Мурзин шәхесе тирәсендәге серле вакыйгаларның күплеге һич тә гаҗәпләндерми һәм тамчы да аптыратмый. Чөнки бу — совет чорында уздырылган хикмәтле идеологиянең бер чагылышы. Әгәр дә җәмгыятьтә үзгәртеп корулар тормышка ашырылмаган булса, гомер юлында күпне күргән, күпне кичергән легендар шәхеснең **«Дошман тылындагы фронт»** дигән китабын яза һәм бастырып чыгара алуын күз алдына китерүе дә читен. Мәгәр 2005 елда нәшер ителгән әлеге китабында, ул әле Власов белән бәйле «серле» вакыйганы бәян итүдән тыелып калган. Ә бәлки рөхсәт булмагандыр?! Аның белән генә чикләнмичә, ветеранның истәлекләренә соң дәрәҗәдә урынсыз һәм шикле бер җөмлә килеп керүе, дөресрәге, шул җөмләдәге ике сүз гаҗәпкә калдыра һәм күңелдәге шикне көчәйтә. Чынлап та, Вермахтның 16 нчы танк дивизиясе командиры генерал-лейтенант **Дитрих фон Мюллерны** кулга алу турында язганда: «Бу безнең партизаннар бригадасы тарафыннан әсир төшерелгән беренче һәм соңгы генерал иде», — дигән җөмләгә «соңгы генерал» сүзләрен өстәүгә хаҗәт юк ич.

Әлбәттә, «алман генералы» дип өздереп әйтелгән булса, аптырамас та идең. Чөнки хәрби антына хыянәт итеп, дошманга хезмәт итү юлын сайласа да, Власовны алман генераллары исемлегенә кертеп карау мөмкин түгел. Ә монда «соңгы генерал», имеш. Әлеге сүзләрнең Мурзин тарафыннан язылуы ышандырмый. Монда, әлеге дә баягы, Власовны эләктерү вакыйгасын яшереп саклау өчен җаваплы цензура хезмәткәренең кулы уйнау ихтималы зур. Бәлки әле нәкъ шуннан соң, кайбер матбугат чараларында һәм Интернетта Даян аганың, Власовны үзләре эләктерүләре турында дәлилләгән фикерләрен раслаучы «тавышлар» яңгырый башлагандыр.

Даян Мурзинны Украина партизаннар хәрәкәте штабы башлыгы (1942-1945) генерал-лейтенант Тимофей Амвросиевич Строкач белән Чехословакия партизаннар хәрәкәте командующие (1944-1945) генерал-майор Алексей Никитич Асмоловның үз итүләре, аңа карата даими ышаныч күрсәтүләре аерым игътибарга лаек. Мурзин яраланып, урманда яткан чакта коман-

далык вакытлыча бригада комиссары **Иван Степанов** кулына күчә. Язучы Генрих Гофман аның ролен күпертеп күрсәтергә тырышса да, чынлыкта алай булмый. Дөрес, Степановның да званиесе — капитан, ул партизаннарга самолётын алманнар бәреп төшергәч килеп кушыла. Әмма Мурзин шикелле өч мәртәбә диверсантлар әзерли торган мәктәпләрдә күнегүләр үтмәгән һәм партизанар отрядлары белән командалык итмәгән, ягъни махсус әзерлеге дә, командирлык тәҗрибәсе дә юк. Мурзин «табылганчыга» кадәр Украина партизаннар хәрәкәте штабы белән элемтәнең җайга салынмавы — аның шул кимчелекләре нәтиҗәсе. Болар һич тә Степанов файдасына түгел. Шуңа да Мурзин, беренче эш итеп, штаб белән элемтә урнаштыруга ук, Ушьякның язмышы тулысынча ачыкланып бетмәүгә карамастан, генерал Строкач нәкъ менә аны бригада командиры итеп билгеләүләрен ирештерә. Строкач һәм Асмолов тарафыннан Даян Мурзинга карата уңай мөнәсәбәт сугыштан соңгы елларда да дәвам итә. 1962 елның 6 августында генерал-майор Алексей Асмоловның «Ян Жижка» исемендәге Чехословак партизаннар бригадасының «элекке» командиры Даян Баян улы Мурзинга карата кайсыдыр махсус хезмәтләр өчен язган гаять дәрәҗәдә җылы эчтәлектәге «Хәрби характеристика»сы — шуның бер генә мисалы.

1 нче Украина партизаннары дивизиясе командиры, ике тапкыр Советлар Союзы Герое генерал-майор **Сидор Ковпакның** сугыштан соң Даян Мурзинга Украинада төпләнеп калырга тәкъдим иткәнлеген дә искәртмичә калып булмый. Ул хәтта **Леонид Ильич Брежнев** белән дә таныш була. Беренче мәртәбә алар Чехословакиядә 1945 елның маенда очрашалар. Даян аганың искә алуына караганда, ул чакта булачак генсек, апрель аенда 3 нче Белоруссия фронты составыннан Ставка карамагына чыгарылган 5 нче армия командующие, ике тапкыр Советлар Союзы Герое (19.04.1945 һәм 8.09.1945) генерал-полковник **Николай Крылов** (соңыннан — Советлар Союзы Маршалы, СССРның стратегик максаттагы ракета гаскәрләре командующие) белән була. 4 нче Украина фронты составындагы 18 нче армиянең сәяси бүлеге башлыгы (1945 елның июнь аеннан — 4 нче Украина фронтының сәяси идарәсе башлыгы) **генерал-майор Леонид Брежневның: «Менә син нинди икәнсең, «кара генерал» Мурзин»,** — дигәне хәтерендә озакка төенләнеп кала ветеранның.

Икенче мәртәбә 1969 елда ЧССРның Мәскәүдәге илчелегендә, президент Людвиг Свобода визиты уңаеннан уздырылган тантана вакытында очраша ике ветеран. Чехословакия герое Мурзин да әлеге мөһим чарага чакырулы була. Очрашу ярым рәсми шартларда үтә һәм анда дустанә атмосфера өстенлек итә. Ә инде банкет башлангач, рәсмилекнең эзе бөтенләй калмый. Җаен чыгарып, Чехословакия илчесе Даян Мурзинны Брежневка тәкъдим итә. Әлбәттә, Леонид Ильич чирек гасыр элек, нибары бер мәртәбә күреп калган сакаллы комбригны танымый. Әмма Мурзин ачыклык керткәч, бик тиз исенә төшерә һәм гаҗәпләнеп:

— Синмени әле ул «кара генерал»? — дип сорый.

Уңай җавап ишеткәч:

— Ә кара сакалың кайда? — дип шаяртып та ала.

Бераздан җитдиләнеп, СССР хөкүмәте җитәкчесе **Алексей Косыгинга** мөрәҗәгать итә:

— Лёша, әйдә әле, минем фронтовик дустым өчен чәкештерик. Ә нишләп ул һаман **Советлар Союзы Герое** түгел? Моны кичекмәстән төзәтергә кирәк! — ди.

Төрле юбилей чаралары уңаеннан, Даян Мурзинның ил җитәкчелеге делегациясе составында Чехословакиядә (соңрак Чехиядә һәм Словакиядә) еш булуын да ассызыкларга кирәктер.

Соңгы мәртәбә ул Словакияне азат итүгә 60 ел тулу уңаеннан уздырылган тантаналарда катнашу өчен Россия президенты **Владимир Путин** җитәкчелегендәге делегация составында **Братиславага** бара. Ул чакта, ягъни 2005 елның февралендә Словакиянең башкаласында Россия һәм АКШ президентлары Владимир Путин белән **Джордж Бушның** очрашуы үтә. Әлеге саммит илне фашистлардан азат итүне билгеләү (гәрчә Словакия алман гаскәрләреннән тулысынча 1945 елның май башына гына арына, ә ил башкаласы Братислава — 4 апрельдә) чараларына туры килгәнлектән, делегация составына Чехословакиядә сугышкан өч ветеранны, шул исәптән Даян Мурзинны да кертәләр. Бәйрәм чаралары вакытында ветераннар Путин белән бер машинада йөриләр һәм бергәләп Мәңгелек ут мемориалына чәчәкләр салалар.

Даян Мурзин 2004 елның сентябрендә Ян Жижка исемендәге 1 нче Чехословак партизаннар бригадасы төзелүенә һәм аның Словакиядән Моравиягә үтеп керүенә 60 ел тулу уңаеннан Чехиядә узган тантаналы чараларда да катнаша. Нәкъ шул елны бригада ветераннары Советы рәисе **Честмир Смолка** һәм дошман тылында көрәш алып барган Чехия белән Моравиянең элекке партизаннары Даян Мурзинга **Россия Герое** исемен бирүләрен үтенеп президент Владимир Путинга мөрәҗәгать итәләр. Берничә дистә партизан һәм яшерен көрәш алып барган патриотлар кул куйган хаттан өземтә:

«Гитлерчы-фашист баскыннары тарафыннан басып алынган елларда безнең ил халкы зур сынаулар алдында калды. Шул авыр вакытларда <…> Советлар Союзы <…> чехословак халкына ярдәмгә Чехословакиягә үзенең батыр ул һәм кызларын <…> җибәрде.

Әлеге кыю совет командирлары арасында десант (төркеме — Р.З.) җитәкчесе сыйфатында килгән яшь кенә офицер, Совет (Кызыл — Р.З.) армиясе капитаны Даян Баян улы Мурзин да бар иде. 23 яшендә генә булуына карамастан, аның дошман тылында партизаннар көрәше алып бару буенча зур тәҗрибә туплап өлгергәнен белә идек. Моңа кадәр ул <…> Украинада һәм Молдавиядә өч ел дәвамында партизан отрядлары белән командалык иткән.

Хөрмәтле Владимир Владимирович! Безнең барыбызга да, Даян Мурзин командалыгында, Словак милли восстаниесе үзәгеннән <…> Прагага чаклы ифрат авыр партизан көрәше юлы үтәргә туры килде. Без, турыдан-туры партизаннар сугышында катнашучылар, аны иң булдыклы оештыручыларның берсе һәм гаять дәрәҗәдә кыю, тәвәккәл, гайрәтле командир буларак беләбез. Ул кыска гына вакыт эчендә партизаннар отряды оештыра алды. Соңрак, өзлексез дәвам иткән сугышлар барышында отряд эре партизаннар бригадасына әверелде һәм Мурзин аның белән сугыш тәмамланганчы командалык итте. Ян Жижка исемендәге 1 нче Чехословак партизаннар бригадасы фашистлар өчен хәвеф-хәтәр тудырса, безнең халык күңелендә өмет һәм ышаныч уятты… <…>

Майор Мурзинның фәкать исемен генә ишетү дә фашистлар арасында курку һәм каушау тудырганына күпләр шаһит. Чехиядә һәм Моравиядә безнең бригаданың иң зурлардан саналуын да әйтмичә калып булмый. Бригада тарафыннан бик күп авыллар һәм калалар фашистлардан азат ителде һәм аларда Милли-революцион комитетлар төзелде. Безнең бригада партизаннары тарафыннан меңнәрчә фашист солдаты һәм офицеры юк ителде, хәрбиләр һәм техника төялгән 68 эшелон яр астына җибәрелде… <…>

Чехословакия җирендә алып барылган авыр, тигезсез сугышларда Даян

Күрәсең, аның батырлыклары чех һәм словак ягы өчен генә мөһим булгандыр. Алар – саллы һәм гадел бәһа бирә белә торган халыклар.

Мурзин ике тапкыр яраланды һәм контузия алды. <…> Безнең халык Мурзинны үзенең милли герое дип игълан итте, урамнар, мәйданнар аның исемен йөртә, ул — Чехословакиядәге күп кенә кала һәм авылларның мактаулы гражданы. <…> Д.Б.Мурзин ЧССР хөкүмәтенең 10 югары бүләгенә лаек булды… <…>

Бүген, Владимир Владимирович, үзебезнең зур бәйрәмебез — Словак милли восстаниесенең 60 еллыгы алдыннан Сезгә мөрәҗәгать итәбез һәм Даян Баян улы Мурзинга Россия Герое исемен бирүгезне үтенеп сорыйбыз».

Әмма ветераннарның үтенеченә колак салучылар табылмый — хат җавапсыз кала. Менә шундый сәер һәм серле битарафлык. Күрәсең, аның батырлыклары чех һәм словак ягы өчен генә мөһим булгандыр. Алар — саллы һәм гадел бәһа бирә белә торган халыклар. Әлбәттә инде, андый уңай мөнәсәбәтнең Чехословакия тыныч юл белән мөстәкыйль Чехия һәм Словакия дәүләтләренә бүленгәч тә дәвам итүе — аерата сөенечле хәл. 2000 елдан Даян Баян улы Мурзинның Чехия Республикасы армиясенең отставкадагы полковнигы дигән хәрби чинын йөртүе шуңа дәлил булып тора. Хәрби чин дигәннән, тагын бер серле вазгыять. Чехия ветераннары хатында Мурзинның чины майор дип күрсәтелә. Шундый ук раслау белән 1945 елның 25 маенда партизаннар бригадасы командиры майор Даян Мурзинга бирелгән командировка боерыгында да танышырга мөмкин. Аннан күренгәнчә, 25 майдан 10 июньгә кадәр майор Мурзин «Опель» маркалы җиңел автомобильдә Киевка, Украина КП(б) ҮК карамагына командировкага җибәрелә. Максаты — Украина җитәкчеләре алдында махсус доклад ясау. Гаҗәпкә калдырганы шул: 1948 елда Мурзин капитан чинында фотога төшә. Бу исә аның Казандагы юридик мәктәптә укыган чагына (1946 елның сентябре-1948 елның августы) туры килә. Мурзинның үз китабында ике тапкыр милләтенең татар булуын ассызыклавы һәм иллюстрацияләр битенә милләте күрсәтелгән хәрби

Рәис Зарипов Даян ага Мурзин белән әңгәмә кора. 2008 елның 1 декабре

билетының күчермәсен урнаштыруы совет идеологиясенең нинди мәкерле юллар белән гамәлгә куелуын фаш итү өчен махсус эшләнгәнлеге бернинди шик-шөбһәгә дә урын калдырмый. Шулай ук капитан погоннары тагылган формасындагы фотосын һәм «майор Мурзин» дип ташка басылган командировка боерыгы күчермәсен бер биттә янәшә бирүе дә тикмәгә түгел. Монда Даян аганың безгә әйтергә теләгән фикере яшерелгәне бик яхшы төсмерләнә.

Ни кызганыч, бар серләрен дә ачып өлегермәде данлыклы разведчик-диверсант. Татар халкының каһарман улы, Чехословакиянең милли герое Даян Баян улы Мурзин 2012 елның 9 февралендә 91 нче яшендә вафат булды. Бу җәһәттән Татарстан җитәкчелеге һәм Казанда нәшер ителүче матбугат чаралары кайгы уртаклашып мәшәкатьләнмәделәр, ягъни «вакланып» тормадылар. Билгеле инде, милләтнең каһарман улы исемен мәңгеләштерү буенча да республика башкаласында бармакка бармак та сукмаячаклары ачык. Бу безнең мескенлекне, куркаклыкны, үшәнлекне һәм тәмам манкортлаша башлавыбызны күрсәтә. Болар — милләтнең киләчәген шик астына алучы гаять дәрәҗәдәге куркыныч симптомнар. Башка халыкларның җитәкчеләре, җаваплы түрәләре андый түбәнлеккә төшми, үзләренең күренекле милләттәшләрен күрмәмешкә салышмый һәм әнә шулай мескенләнеп үз-үзләрен түбәнсетми. Мәгәр шунысы хак: дистә еллар дәвам итүче мондый кыргый вазгыятьтә татар халкының гаебе юк. Урының җәннәттә булсын, рәнҗеп ятма, Мәскәү тарафыннан кагылган һәм милләт «аталары» тарафыннан үгисетелгән тагы бер данлыклы татар баласы! Ә без, үз чиратыбызда, киләчәктә андый мөнәсәбәтнең үзгәрәсенә һәм тулаем милләт язмышы күгендә якты көннәр туасына ышанычөметтә калыйк, рухи ныклыгыбызны югалтмыйк, кыйблабызга тугрылык саклыйк! Бердәм булыйк!

Редакциядән: *Башкортстанның Татар иҗтимагый үзәге 2015 елны Даян Мурзин елы, дип игълан итте.* ■



ҖИҢҮ АЛЫП КИЛГӘН ТАТАР ГЕНЕРАЛЫ

Александр Филиппов

Армия генералы, Совет Армиясенең Генераль штабы Оператив идарәсе начальнигы, Генераль штаб начальнигы урынбасары, Генераль штаб начальнигы, Варшава Договоры илләренең Берләшкән Кораллы Көчләр штабы начальнигы, Кырым (Ялта) һәм Берлин (Потсдам) конференцияләрендә катнашучы, «Җиңү» ордены белән бүләкләнгән бердәнбер генерал һәм бердәнбер татар ул – Алексей Антонов.

1888 елда Иннокентий Алексеевич Антоновны Иванай исемле керәшен авылыннан (ул хәзер Балык Бистәсе муниципаль районына керә) действительный хезмәткә чакыралар. Башлангыч белемле генә булса да Иннокентий ушлы кеше була. Аны соңыннан солдатта калырга кыстыйлар һәм кыска сроклы офицерлар курсына укырга җибәрәләр.

1896 елның 15 сентябрендә Гродно шәһәрендә поручик Антоновның улы туа. Аңа бабасының исемен бирәләр. Кечкенә вакытта малай әтисенә ияреп төрле хәрби өйрәнүләргә йөри. Алексейга 12 яшь тулганда, капитан Антонов, хәрби манёвр вакытында, боз ватылып, пушка һәм атлары белән елгага чума, үпкәләре шешеп, ун көн эчендә үлеп тә китә. Аның хатыны Тереза Ксаверьевна — милләте буенча татар каны катышкан поляк — ике бала белән тол кала. Алексей ул вакытта Гродно шәһәрендә гимназиядә укый торган була. Беренче Бөтендөнья сугышы башлангач, Тереза Антонова язган үтенеч буенча, дивизия командиры аларга Петербургта дүрт бүлмәле фатир алып бирә. Аның туганнары биредә яши торган була. Ләкин Алексейга унсигез тулганда, 1915 елның язында, әниләре дә үлеп китә. Алексей шул ук елны гимназияне тәмамлап, Петроград (бу вакытта шәһәр исеме алышына) университетының физика-математика факультетына укырга керә. Тик аны тәмамлый алмый, нужа куып йөртә, чөнки әнисе үлгәннән соң әтисе өчен пенсия бирүне туктаталар. Путилов заводына браковщик булып эшкә урнаша.

Сугыш кызган 1916 елны егерменче яше белән барган егетне солдатка алып, Павловск хәрби училищесына кыска курсларга офицерлыкка укырга юллыйлар. 1917 елның башында Антоновны фронка җибәреп, Егерь лейбгвардия полкына взвод командиры итеп билгелиләр. Ел ярымнан артык поручик Антонов фронтта немецларга каршы сугыша.

Кечкенәдән үк күп телләрне белеп үсә Алексей. Әтисе аңа туган телне өйрәтә, моңлы итеп керәшен җыруларын җырлый. Сугыш землянкаларында ул, татар солдатлары белән бергә, «Кара урман», «Герман көе» кебек җырларны җырлый. Әнисеннән, поляклашкан татар морзасы кызыннан, поляк, француз, немец телләрен өйрәнә. Сеңлесе Людмила Иннокентьевна язуына караганда, өйдә алар рус, поляк һәм, әлбәттә инде, сирәк булса да, татар телләрендә аралашып үсәләр.

1918 елда поручик Антоновны армиядән озаталар. Ул, Петроградка кайтып, Азык-төлек комитетында эшли.

Россиядә Гражданнар сугышы башлангач, 1919 елның 11 апрелендә мобилизация белән Кызыл Армия сафларына алына. Аны штаб хезмәтенә билгелиләр, ул кызыл командирга әйләнә. Антонов Көньяк фронтта Деникинга каршы барган көрәшләрдә Мәскәү Эшчеләр дивизиясенең штаб начальнигы ярдәмчесе була. Ләкин аның яртысы кырылып бетә, аны 15 нче Инза укчы дивизиясе составына кертәләр. Антонов ике тапкыр яралана.

1920 ел. Антонов бу вакытта инде 45 нче бригаданың штаб начальнигы була. Врангель армиясе кызылларны алдан да, арттан да, яннан да тукмаклый. Михаил Фрунзе Кырымны яулап алу өчен оештырылган Көньяк фронт командующие итеп билгеләнә. Кырым ярымутравын яулап алганда Сиваш кичүенең әһәмияте зур була. (Мондагы вакыйгалар безгә Гомәр Бәшировның «Сиваш» повесте аша да билгеле.) Бу кичүне оештыручыларның берсе — Антонов. Ул кичү планын Фрунзега икәүдән-икәү калгач җиткерә. Бу аларның беренче орашуы була. Михаил Васильевич үзенең Бишкәктә татарлар белән аралашып үсүен әйтә. «Ә мин — керәшен татары», — ди Алексей. Татарча сөйләшеп, «мин — молдован, син — татар», — дип аеры-

лышалар, Фрунзе тәкъдиме белән, Сивашны кичүдә актив катнашкан өчен, Алексей Антонов Хәрби Революцион Советның Дәрәҗәле коралы (Почётное оружие) һәм Мактау грамотасы белән бүләкләнә. Моны аңа М.В.Фрунзе үзе тапшыра.

Гражданнар сугышы тәмамлангач, ул 15 нче Сиваш укчы дивизиясендә 1928 елга кадәр хезмәт итә. Шул ук елны коммунистлар партиясе сафына кабул ителә һәм М.В.Фрунзе исемендәге хәрби академиягә укырга китә. Академияне уңышлы тәмамлагач, аны Украинадагы Коростень шәһәрендә урнашкан 46 нчы дивизиягә штаб начальнигы итеп билгелиләр.

1932 елда шул ук Академиянең оператив факультетына укырга керә. Монда ул хәрби теоретиклардан, шул исәптән, профессор Дмитрий Михайлович Карбышевтан тирән белем ала. Укуны тәмамлаганда факультет комиссары Г.С.Иссерсон: «А.И.Антонов бик яхшы оператив-штаб хезмәткәре, югары штабларда эшләргә әзер», — дигән бәя куя.

Укудан соң — ул яңадан армия хезмәтендә. Ел ярым 46 нчы укчы дивизиянең, аннан соң 1934-1935 елларда Могилёв-Ямполь ныгытылган районында штаб начальнигы була. Аннары аны Харьков хәрби округы штабына 1 нче (оператив) бүлек начальнигы итеп күчерәләр.

1936 елда округ командованиесе А.И.Антоновны Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең яңа гына ачылган Генераль штаб академиясенә укырга җибәрә. Академиягә ул вакыттагы хәрби эш теоретиклары җыела. Аларны Алексей Иннокентьевич М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академиядән үк белә. Аның беренче тыңлаучылары И.Х.Баграмян, А.М.Василевский, Н.Ф.Ватутин, Л.А.Говоров, М.В.Захаров һәм башка командирлар булалар.

Алексей Антонов. 1926 ел

Бу академиянең укытучысы А.В.ГОЛУБЕВ сөйли:

— Барлык тыңлаучылар да бик яхшы укыдылар. Мин укыткан югары берләшмәләр тактикасы курсыннан Антонов аерылып торды. Аның француз телен яхшы белүе чит ил белгечләренең алдынгы карашларын ачарга мөмкинлек тудырды. Мин аның «Армейская наступательная операция с преодолением водного рубежа» дигән рефератын яхшы хәтерлим. Укытучылардан алырга мөмкин булган белемне тиз үзләштерде, вакытны әрәмгә уздырмады.

1937 ел. А.И.Антонов беренче курсны уңышлы тәмамлый. Аңа икенче курста укырга туры килми — Оборона Наркоматына чакырып алып, Советлар Союзы Маршалы С.М.Будённый командалык иткән Мәскәү хәрби округына штаб начальнигы итеп куялар.

1938 елда Алексей Иннокентьевичны М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академиядә гомуми тактика кафедрасында өлкән укытучы итеп күчерәләр. 1940 елда доцент һәм генерал-майор

дәрәҗәсе бирәләр. 1941 елның гыйнварыннан ул — гомуми тактика кафедрасы начальнигы урынбасары.

1941 елның 11 мартында генерал-майор А.И.Антоновны Киев Махсус хәрби округына билгелиләр. Бөек Ватан сугышын шушында каршылый ул. Сугышның беренче көннәреннән үк ул Көньяк фронт идарәсен формалаштыруга керешә. 1941 елның августында шушы фронтның штаб начальнигы була. 1942 елның июль аенда Төньяк Кавказ, аннары Кавказ фронтларының штаб начальнигы итеп күчерәләр. Югары даирә аның фронтлардагы гадәттән тыш оператив оештыру сәләтен күреп, Генераль штабка чакырып кайтара. Гомумән, Антоновны гел иң авыр участокка куялар.

Алексей Иннокентьевичның аннан соңгы барлык эшчәнлеге Советлар Союзы Кораллы Көчләренең Генераль штабы белән тыгыз бәйләнгән. Советлар Союзы Маршалы Б.М.Шапошников, сәламәтлеге какшау сәбәпле, Генераль штаб начальнигы вазифасыннан китеп, Хәрби академия начальнигы була. Аның урынына элек Генштабның Оператив идарәсе белән җитәкчелек иткән А.М.Василевский билгеләнә. Оператив идарәдән аның китүе Генштаб өчен бик авырга туры килә. Аның начальниклары булып ярты ел эчендә генераллар А.И.Бодин, икешәр тапкыр А.Н.Боголюбов, В.Д.Иванов, алар арасында вакытлыча П.Г.Тихомиров, П.П.Вечный һәм Ш.Н.Гениатуллин эшләп алалар.

Хәл тагын да катлаулана, чөнки Югары Башкомандующий Ставкасы, А.М.Василевский Генштаб начальнигы итеп куелганнан соң да, күп вакытын Сталин заданиесе буенча фронтларда үткәрергә мәҗбүр була. Александр Михайлович үзенә лаек булган урынбасар эзли башлый. А.М.Василевский Оператив идарә башлыгы һәм Генштаб начальнигы урынбасары итеп генерал-лейтенант А.И.Антоновны сайлый һәм Ставкага тәкъдим итә.

Армия генералы С.М.ШТЕМЕНКО сөйли:

— Мин ул вакытта көньяк юнәлешкә җитәкчелек иткәнлектән, Алексей Иннокентьевичны миңа каршыларга туры килде. Идарәгә гадәттән тыш зур сәләтле һәм штаб хезмәтенең зур белгече килгәнлеге сизелде. Антонов үзен бик акыллы тотты. Ул барлык кешеләр белән аерым-аерым танышып чыкты, фронттагы оператив хәлләрне җентекләп өйрәнде. Моңа бер атна вакыт кирәк булды. Антонов, Генштабка килеп эшли һәм Сталин кабинетына көн саен иртән доклад белән йөри башлагач, эшне үзенә яраклаштырып үзгәртте һәм Генераль штаб тәүлек буе эшли башлады.

Алексей Иннокентьевич Ставка белән очрашуга бөтен яктан да әзерләнә. Аның Сталин белән беренче очрашуы бик рәсми һәм салкын була. Аны 1943 елның гыйнвар башында Брянск, аннары Воронеж һәм Үзәк фронтка Ставка вәкиле итеп командировкага җибәрәләр. Монда ул Воронеж һәм Касторное районнарында һөҗүмнәр оештыру өчен Сталинградтан кайткан Генераль штаб начальнигы А.М.Василевский белән очраша. Бирегә 16 гыйнварда генерал-лейтенант А.И.Антонов, 18 нче аерым укчы корпусы белән дошманны әйләндереп алып, һөҗүм ясарга тиеш була. Бу сугышларда 40 нчы армия һәм 18 нче аерым укчы корпус белән Ставка вәкиле А.И.Антонов координация ясый. Берләшмә һәм корпус частьлары һәм армия, дошманга аркылы төшеп, аның чигенү юлын кисәләр. Гитлерчылар бер авылдан икенчесенә сугылалар, әмма аларны һәркайда пыран-заран китереп ташлыйлар. Дошман калдыклары капитуляция ясый. 27 гыйнварда фашист төркемнәре тар-мар ителә. Монда аларның 15 дивизиясе тулысынча, ә 6сы зур югалтулар кичерә. 24 гыйнварда башланган Воронеж-Касторное операциясе уңышлы уза һәм ул 1943 елның 17 февралендә тәгәлләнә.

Алексей Иннокентьевич Воронеж фронтында март азагына кадәр була. Аның эшчәнлеге Генераль штаб начальнигы А.М.Василевский һәм Югары Башкомандующий И.В.Сталин тарафыннан югары бәяләнә. Тиздән ул Мәскәүгә кайта һәм Ставкада фронтлардагы хәлләр турында доклад ясый, Сталин аны бик дикъкать белән тыңлый.

Сталин Ставкадан тәүлекнең теләсә кайсы вакытында шалтыратып, һәрвакыт үзенә кирәкле мәгълүмат алуга ирешә. Билгеле, моның өчен генерал Антоновка үзенә дә тәүлегенә 17-18 сәгать буе Генштабта булырга, барлык фронт штаб начальниклары белән элемтәдә торырга туры килә.

Югары Башкомандующий Сталинга Генераль штаб тәүлегенә өч мәртәбә доклад ясый. Беренче доклад — телефоннан иртәнге 10-11 сәгатьтә. Бу докладны Антонов оператив идарә начальнигы Штеменкога тапшыра. Кичке 16-17 сәгатьләрдә докладны Ставкага барып Антонов үзе ясый. Күп вакытта Антоновка кичен 21-22 сәгатьләрдә икенче мәртәбә дә барырга туры килә.

Авиация Маршалы Ф.Я.Фалалеев, армия генералы А.И.Антонов, Советлар Союзы Маршалы Г.К.Жуков

Ул Сталинга аңлаешлы итеп, кыска гына сөйләп, күп мәгълүмәт бирә. Антонов кулында кәгазь юк, ул барысын да

Кызыл Армия Генераль штабы начальнигы урынбасары А.И.Антонов (уңда) һәм Генштабның Оператив идарәсе начальнигы С.М.Штеменко



Армия генералы А.И.Антоновның 15 көн эчендә үз бүлмәсендә бикләнеп утырганнан соң туган хәйләгә корылган «Багратион» операциясе. Бу операцияне тормышка ашыру 1944 елның 23 июненнән алып 29 августына кадәр берөзлексез 68 көн буена дәвам итә. Монда 2,33 миллион сугышчы һәм командир катнаша. Шуларның 178,5 меңе үлә, 587 меңе яралана

яттан белә, аның мәгълүматлары — үзе ясаган карталарда. Ул докладын безнең гаскәрләрнең хәрәкәтенә бәя бирүдән башлый. Фронтлар, армияләр, танк һәм механикалаштырылган корпусларның командующийлары һәм командирлары исемнәре белән әйтелә. Дивизия һәм полклар — номерлары белән. Ул бервакытта да кәгазьдән укымый, барысын да яттан белә.

Армия генералы Сергей Матвеевич ШТЕМЕНКО: *«Генерал А.И.Антонов төгәл, уйларын ачык һәм кыска итеп сөйли белә, иң кирәген эләктереп алып, сөйләгәндә шуны алгы планга чыгара һәм иң кирәгенә тавышы белән басым ясап сөйли. Шунлыктан Ставкада Антонов ясаган докладлар табигый чыга, өстәмә сораулар бирелми. Генерал А.И.Антонов, Ставкага докладка дип әзерләгән документларны өч папкага салдыра. Кызыл тышлыгысенә иң мөһимнәре — беренче чиратта җиткерелә торган докладлар салына. Икенче папка зәңгәр тыштә булып, анда икенче чираттагы документлар — төрле үтенечләр, хәбәрләр, зарланулар салына. Яшел тыштәге папкада хәрби дәрәҗәләр бирү, орденнар белән бүләкләү, чит илләрдән килгән һәм тәрҗемә ителгән хәбәрләр, командирларны билгеләү турындагы документлар. Кызыл папкадагы документларның эчтәлеге Ставкага тулысы белән җиткерелә, калган папкаларга кайбер көннәрдә чират та җитми, андый чакларда «Бүген кызыл папкадагы документларны гына карыйбыз, дия торган була Сталин»*, — дип яза.

Үз эшен яхшы белгән, докладларны курыкмыйча турыдан-туры һәм дөрес, бернинди дә шомартуларсыз ясаган А.И.Антонов Сталин алдында зур дәрәҗә казана. Антонов, Генштабта эшли башлаганның беренче көненнән үк, җиңелүләрнең берсен дә яшермичә, Сталинга җиткерә белә. Кирәк чагын-

да үз фикерен Сталинга ачыктан-ачык әйтә алган генерал да әле ул.

1944 елның җәйге хәрби кампаниясе операцияләрен үткәрү турында генерал А.И.Антонов апрель аенда доклад ясый. Бу Балтыйк буеннан Карпат тауларына кадәр барлык фронтлар катнашында икенче Бөтендөнья сугышы тарихына керерлек иң эре вакыйгалар булырга тиеш. Ул Польша, Чехословакия һәм башка Көнчыгыш Европа илләрен Гитлер тырнагыннан азат итүне күз алдында тотып эшләнә.

Алексей Иннокентьевич бу авыр эшне — 1944 елның җәйге кампаниясенең хәлиткеч һөҗүм планын берүзе аерым бүлмәгә бикләнеп эшли. Бу турыда ул Сталинга да әйтеп, аны 15 көн эчендә башкарып чыгарга сүз бирә. Белоруссиядәге стратегик код белән «Багратион» исеме бирелгән операцияне планлаштыру, шулай итеп, Антоновка йөкләнә.

Беренче шарт итеп, немец командованиесен иң ныклы һәм җаваплы һөҗүмнәр Балтыйк буенда һәм Көньяк фронтларда булырга тиеш, дип ышандырырга кирәк. Шуңардан чыгып, Өченче Украина фронтына боерык җибәрелә.

Өченче Балтыйк буе фронтына да шундый ук директива китә. Мондый маскировка ясау Черёха елгасыннан көнчыгышка табарак башкарылырга тиеш була.

Дошманнар бу ялганга шунда ук кабалар. Бигрәк тә көньяк юнәлештәге немец командованиесе зур борчуга төшә. Көчле һава разведкасы ярдәмендә алар Кишинёвтан төньяктарак безнең гаскәрләрнең ниятләрен ачыкларга тырышалар. Бер урында гына басып торганлыктан, болар шушында һөҗүм итәргә әзерләнәләр икән, дигән фикергә киләләр һәм үзләренең көчен шул урыннарга туплый башлыйлар. Чынлыкта исә танк һөҗүме дошман көтмәгән бөтенләй икенче урында әзерләнә…

1944 елның 14 маена Белоруссия операциясенең планын һәм карталарны эшләү тәмамлана. Операцияне башкарып чыгу өчен бик күп көч куелса да, җыйнак кына текст һәм картадан башка берни дә булмый. Бу Антонов стиле — кыска һәм төгәл. Зур җаваплылык алып, бер үзе эшләгән текстка да, картага да Антонов кул куя. «Багратион» әзер!

Ставкада хәрби начальникларның зур киңәшмәсендә җентекләп анализланганнан һәм төзәтүләр керткәннән соң, «Багратион» планы Югары Башкомандующий И.В.Сталин тарафыннан раслана, ә Алексей Иннокентьевичка аның тормышка ашырылуын катгый күзәтү астына алырга кушыла. Операция 1944 елның 22 июнендә башлана. Совет гаскәрләре алты тәүлек эчендә дошманның флангтагы Витебск һәм Бобруйск астындагы группаларын тар-мар итәләр. Танк һәм механикалаштырылган берләшмә дошман тылына 110-150 километрга эчкә кереп, гитлерчыларның ике ел буена ныгытылган фронтларын җимерә.

Генерал С.М.ШТЕМЕНКО: *«Антоновның Белоруссиядәге кебек зур яуларны оештыруы беренче очрак кына түгел, андыйларны күпләп китерергә мөмкин булыр иде»,* — дип язды.

Алексей Иннокентьевич Антоновның хезмәте соңыннан Ватан тарафыннан «Җиңү» ордены белән дә билгеләнеп үтелә. Бу үзе дә батырлыкка тиң. Чөнки мондый бүләкне алучыларның саны бөтен СССРга бары тик 11 генә (исемлек орден бирелү тәртибе буенча бирелә): Г.К.Жуков, А.М.Василевский, И.В.Сталин — икешәр тапкыр, К.К.Рокоссовский, И.С.Конев, Р.Я.Малиновский, Ф.И.Толбухин, А.А.Говоров, С.К.Тимошенко, А.И.Антонов, К.А.Мерецков. Ә чит ил кешеләреннән Румыния короле Михай I, маршаллар Б.Монтгомери, М.Роля-Жимерский, И.Б.Тито, Д.Эйзенхауэр бүләкләнә.

Ахыры бар ■

ЯЗЫЛМАГАН КЫЙССА

Камил Кәримов

Бу рәсемдә – миңа иң изге булган ике газиз зат

ӘДҺӘМ

«Атна саен гает,
Гает саен мәет», — дигән такмак чыгарган ул гаҗизлектән... Беренче хатыны ураза гаетендә үлә, икенче хатыны — Корбан гаетендә... Күкрәктән дә аерылмаган килеш үги калган малайга тагын берәү өстәлә...

Әдһәм — Шәледә мал врачы. Ятимнәрнең тамагы тук, өсте бөтен!

35 яшендә ул Фин сугышына алына. Ике улы исә үз әниләре ягыннан туган тиешлеләр кулына күчә.

Ватан сугышының беренче көненнән үк мобилизацияләнә.

1945 елның көзендә Шәлегә «Ура!» кычкырып кайтып кергәндә минем әти булмаган әле ул.

МӘДИНӘ

Казанга килеп, «Микоян» кондитер фабрикасына эшкә урнаша. Аны, Солтан авылы егете Сәләхетдингә димләп, кияүгә бирәләр.

Ирен хәрби эшелон белән фронтка озаткач, ул, алты айлык Шәмсетдинен биләүгә төреп, яңадан Шәлегә, әнисе янына кайтып керә.

Снайпер Сәләхетдин Миңнегалиев 1941 елда ук хәбәрсез югала... Һәлак булган урыны 2000 елда гына табыла.

ӘТИ

Сугыштан соң да — «ат духтыры». Утлар-сулар кичкән, һәркайда сүзе үтә торган «грамотный» кеше булып таныла ул. Кырык яшен тутырган «Сугышчан Дан ордены» кавалеры, рядовой Әдһәм Кәримов яңа гаилә кору турында хы-

яллана (рядовой, дип аерым әйтәм, чөнки безнең «Корыч» нәселендә чин вә түрәлеккә омтылучы кеше булмаган). Исән-сау килеш җиңү яулап кайткан фронтовикларны Шәленең йөзләгән сазамыгы-толы көткәндер дә, ләкин Әдһәм алты яшьлек малае белән утырып калган Мәдинәне сайлый. Фоторәсемдә аларның авыл советында язылышып кайткан көннәре, ягъни 1946 елның 1 мае. Шул көнне үк ул күрше Колай авылыннан иске келәт бурасы төяп кайта. Бураны җыеп, ике тәрәзә уеп, түбәсенә салам ябып, өй итеп керәләр.

...Ятимнәр арасына Тәнзилә апам өстәлә.

Әти исә яңа өй салу турында хыяллана башлый.

Үзебезнең бәләкәй тананы колхозның симереп ялкауга чыккан, олы гәүдәле үгезенә алыштыра. Шуны суеп саткач, кечкенә бозау алып, калган акчага яңа бура күтәрергә ниятли ул.

Чиллә кояшы күтәрелгәнче дип, таңнан торып, Казанга китәләр. Кичтән суелган итне, җилләнеп барсын өчен, марля белән генә каплыйлар. Шәледән чыгып, Мишә күперен үтеп киткәч кенә... Казан юлына күтәрелгәндә... Тәрәзәдәй чалт аяз көнне, карурманның әллә кайсы төшеннән генә, черек салам өемедәй бер болыт килеп чыга да арбадагы итне манчып китә... Казанга барып җиткәндә инде пешеккән, муртайган, төсен салган итне базарга кертмиләр. Сабын кайнату комбинатына тапшырырга туры килә... Әтинең өйгә ни хәлдә кайтып кергәнен сурәтләп торуның кирәге юктыр...

Аның рухы сына, яшәү дәрте сүнә, сугыштан калган яралары көчәя. Мин туганда ул инде урынга егылган була. Һәм, 1951 елның февралендә, миңа ярты яшь дигәндә, бакыйлыкка күчә.

ӘНИ

Җиңү яулап кына бетми шул ул сугыш... Газаплары, әрнүләре, каргышлары, хәрабәләре озын-озак елларга сузыла...

Без — сугыш афәтенең дүрт ятиме — ике тәрәзәле өйдә калдык. Әни — көне-төне колхоз эшендә. Әтинең пенсиясе артыннан да йөреп карады ул. Райсобес документларны кире кайтарды: «Әтиегез өйдә үлгән. Сугыш инвалиды дигән таныклыкны алмаган булган. Димәк, орден-медальләренең дә роле юк», — кебегрәк җавап иде ул.

Әсирлеккә төшеп, концлагерьдан исән-имин котылып кайткан өч кеше бар иде авылда. Без аларның малайлары белән уйнамаска тырыша идек... Ул абзыйларга, пленда зыян күргәннәре өчен дип, Германия 800әр дойч-марка акча түләде... Әни бик рәнҗегән иде моны ишеткәч...

Әтинең ордены белән кайсы абыем уйнагандыр, белмим, ә мин, күкрәгемә «За боевые заслуги» медален тагып, кибет тавында чана шуганымны хәтерлим.

36 яшьтән тол калып, әни кияүгә чыгу турында бүтән сүз кузгатмады. Үги әтигә булса да: «Әти!» — дип эндәшәсе килгән чакларым күп булды...

Абыйларымның үскән бере бәхет эзләп читкә китеп барды, 1963 елда, яңа бура күтәрергә дип өмә җыйганда, әни янында Тәнзилә апам белән икәү генә калган идек инде: сөенә-сөенә иске өйне сүттек, идән астына баз казыдык.

Әни колхоздан 2 мең сум ссуда алган иде («Москвич» машинасы 4 мең торган чаклар), ул бурычны 1971 елда өйне сатып түләп бетердек...

МИН

«Ком сәгате» романымда, мүкне йолыккалап, урамга муенын сузып каңгылдаган ана каз бар. Әти белән әни фотога төшкән шушы өй иде ул: ике тәрәзә арасына җәймә генә элгәннәр.

Шөкер, өй салдым, агач утырттым, балаларым бар... И, Ходаем, сугыш кына була күрмәсен, дип көнгә җитмеш тапкыр кабатласам да аз... ■

АЛБАЙ ТӨБӘГЕНЕҢ БИШ БАТЫРЫ

Шаһинур Мостафин,
эзтабар-язучы

һәр төбәкнең, һәр авылның кабатланмас үз тарихы, үз моңы бар. Әнә шул гыйбрәтле вә данлы тарихны тудыручылар – теге яки бу авылның фидакяр җанлы, якты күңелле, көчле рухлы, тынгысыз кешеләре. Аларның нурлы исемнәрен Галиҗәнап Вакыт һич оныттырмый, кешеләрнең исләренә әледән-әле төшереп тора.

Шулай дигәч тә, хәтеремдә 2010 елның май ае яңарды. Бөек Ватан сугышында җиңүебезнең 65 еллыгын бәйрәм иткәндә Мамадыш районының Албай авылында берьюлы биш каһарманга, шулай ук яу кырында һәлак булган һәм исән кайткан якташларына багышланган мемориаль үзәк ачылды. Әлеге тантанага муниципаль район хакимияте башлыгы **Анатолий Петрович Иванов** җитәкчелегендәге мәртәбәле делегация килде. Керәшен татарлары яши торган ошбу авыл халкы үзенең тәвәккәллеге, бердәмлеге – максатчанлыгы белән бик күпләрне сокландыра. Чыгыш ясаучылар да һәр батырга аерым-аерым тукталып, аларның Ил-Ватан каршында күрсәткән фидакярлекләрен яктыртып үттеләр.

Албайлыларның иң беренче горурлыгы – Гражданнар сугышы чорының легендар каһарманы **Степан Домолазов** (1985-1937).

Укый-яза белгән зирәк егетне 1906 елда патша армиясенә алалар. Тиздән аңа фельдфебель чины бирелә. 1910 елда Степан прапорщиклар мәктәбен тәмамлый. Бер елдан соң аны фехтование буенча инструкторлар хәзерли торган Варшава округ мәктәбенә укырга җибәрәләр. 1915 елда, хәрби хезмәттә көе, С.Домолазов Казандагы 1 нче ирләр гимназиясен тәмамлый.

Беренче Бөтендөнья сугышы елларында кыю һәм батыр штабс-капитан Степан Васильевич Георгий тәресе белән бүләкләнә. Гражданнар сугышы чорында ул – Казан губернасының Мамадыш өязендә хәрби комиссар, атаклы Азин дивизиясенең 39 нчы полкы командиры. Аның полкы Көнчыгыш фронтта адмирал Колчак гаскәрләренә каршы батырларча сугыша. 1920 елда Көнбатыш фронтта ак поляклар белән көрәшкәндә дә үзен бары тик уңай яктан гына таныта. Гражданнар сугышын Степан Васильевич дивизия командиры буларак тәмамлый.

1923-1925 елларда исә С.В.Домолазов – Татарстан АССР хәрби комиссары. 1925 елда ул, М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академияне тәмамлагач – 1937 елга кадәр – Кызыл Армиянең Идел буе хәрби округында җаваплы командирлык вазифаларын башкара. Күрсәткән батырлыклары өчен ул өч мәртәбә Сугышчан Кызыл Байрак ордены, исемле корал һәм алтын сәгать белән бүләкләнә.

С.В.Домолазов


М.К.Москвин

Ни кызганыч, 1937 елда ул репрессия корбаны була. Еллар үткәч, Степан Васильевич аклана, намуслы исеме халык күңелендә яңадан якты йолдыз булып кабына!..

Албайлылар Советлар Союзы Герое **Михаил Москвин** (1910-1969) белән дә нык горурланалар.

Авылда башлангыч мәктәпне тәмамлагач, Михаил авыл хуҗалыгында, Белоруссиядәге һәм Төньяк Кавказдагы төзелешләрдә, аннары туган ягында район Советы башкарма комитеты секретаре булып эшли. 1932-1935 елларда М.К.Москвин Кызыл Армия сафларында хезмәт итә һәм яңадан 1941 елның октябрендә хәрби хезмәткә алына. 1933 елда кече лейтенантлар хәзерләү курсларын тәмамлый.

Михаил Кириллович 1942 елның октябреннән – Бөек Ватан сугышы фронтында.

Үзәк фронтның 60 нчы армиясе карамагындагы 7 нче гвардияче механикалаштырылган корпусның 26 нчы гвардияче механикалаштырылган бригадасы батальоны командиры – гвардия өлкән лейтенант Москвин 1943 елның сентябрендә Киевтан төньяктарак тарафта, үз сугышчылары белән беренчеләрдән булып Днепрны кичә, сугышчыларын һөҗүмгә күтәрә һәм плацдарм яулый. Әлеге мөһим плацдармны үз кулларында нык тотып, батальон дошманның 5 контрһөҗүмен кире кайтара, бригаданың һәм корпусның төп көчләренә елганы кичәргә ярдәм итә. Шушы батырлыгы өчен М.К.Москвинга 1943 елның 17 октябрендә Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

1945 елда ул Ленинградта Югары бронетанк гаскәрләре офицерлары мәктәбен тәмамлый. 1946 елда майор Москвин запаска күчерелә. Ул Мамадыш районының «Камский» леспромхозында эшли. Кыю офицер Ленин, II дәрәҗәле Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр белән бүләкләнә...

Советлар Союзы Герое исемен горур йөрткән өченче батыр – **Иван Максимов** (1924-1987) шулай ук албайлыларның тирән хөрмәт иткән, яраткан авылдашларыннан санала.

Сигезенче классны тәмамлагач, Иван колхозда хисапчы булып эшли башлый. 1942 елның августында аны Кызыл Армия сафларына алалар. 1943 елда егет Смоленск хәрби пехота училищесын тәмамлый. 1943 елдан ул – хәрәкәттәге армиядә, сугышчан операцияләрдә катнаша башлый. Рота командиры – өлкән лейтенант Максимов Данциг шәһәре (Польша) читендә, 1945 елның 30 мартында, ныгытылган саклану сызыгын штурмлаганда сугышчыларын беренче булып һөҗүмгә күтәрә. Рота шәһәрне азат итүдә дә актив катнаша. Аннары дошман танкларының 6 контрһөҗүмен кире кагып, кул астында булган чаралар белән,

И.Т.Максимов

Г.С.Смирнов

Висланы кичә, полкның төп көчләре килеп җиткәнгә кадәр кулга төшерелгән плацдармны нык тотып тора. Тәвәккәл офицер И.Т.Максимовка Советлар Союзы Герое исеме 1945 елның 29 июнендә бирелә.

Албайлылар арасында «Россия Герое» исемен йөртүче хәрби очучы да бар әле. 1914 елда туган **Георгий Смирнов** фашист карчыгаларына каршы көрәштә искитмәле батырлык үрнәкләре күрсәтә. Дошманның ул биш самолётын бәреп төшерә: 22 хәрби очыш барышында гитлерчыларның өсләренә 17 тонна бомба ташлап, аларның танк колонналарын, автомашиналарын юк итә.

50 нче авиация дивизиясенә караган 81 нче авиация полкының звено командиры, лейтенант Георгий Смирнов 1941 елның 8 сентябрендә үк Советлар Союзы Герое дигән олуг исемгә тәкъдим ителсә дә, хәрби бүләкне үз вакытында ала алмый. 1941 елның 31 октябрендә, авыр яралану сәбәпле, Георгий Семёнович госпитальдә вакытсыз вафат була. Бүләкләү кәгазьләре дә каядыр адашып йөри…

Сугыш башланганга 67 ел узгач, Алтын Йолдыз медале, бәхеткә, үзенең иясен эзләп таба. Бу өлкәдә Г.С.Смирнов хезмәт иткән полк ветераннары советы, Геройның улы Геннадий Георгиевич һәм кызы Галина Георгиевна зур эшчәнлек күрсәтәләр. Нәтиҗәдә, Россия Федерациясе Президенты В.В.Путинның 2008 елның 8 мартында игълан ителгән Указы нигезендә лейтенант Г.С.Смирновка «Россия Федерациясе Герое» дигән олуг исем бирелә.

Безнең «Хәтер яктысы» экспедициясе әгъзалары да албайлы батырларның фидакярлеген мәңгеләштерү буенча зур эшләр башкарды. Мамадыш районы үзәгендәге «Хәтер» паркында Советлар Союзы Геройлары М.К.Москвинга, И.Т.Максимовка, Россия Герое Г.С.Смирновка мәһабәт бюстлар куелды (скульпторлары – этиле-уллы **Альфрет, Альберт, Гадел Әбдрәшитовлар**). Күренекле журналист-публицист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре **Александр Филиппов** алар турындагы энциклопедик мәгълүматларны «Герой керәшеннәр» дигән китабына да (Казан, «Сүз» нәшрияты, 2009 ел) кертте. Албайлы каһарманнарның икесе (М.К.Москвин, И.Т.Максимов) 2000 елда Татарстан китап нәшриятында без әзерләп чыгарган «Батырлар китабы» – «Книга Героев»та да түрдән урын алды.

Албай авылында ачылган мемориаль комплекста тагын сугыш һәм хезмәт батыры, Социалистик Хезмәт Герое **Иван Захарович Ивановның** да исем-фамилиясе мәрмәр плитәләргә

И.З.Иванов

алтын хәрефләр белән уеп язылган. Тумышы белән ул Албай авыл җирлегенә керүче Зур Арташ авылыннан. 1927 елда дөньяга килгән әлеге каһарман япон самурайларына каршы фидакярләрчә көрәшеп, «Японияне җиңгән өчен» медале һәм II дәрәҗәле Ватан сугышы орденына лаек була. Сугыштан соңгы гомерен ул тулысынча урман хуҗалыгына багышлый. Мәскәү урман хуҗалыгы техникумын, аннары Йошкар-Оладагы урман хуҗалыгы институтын тәмамлый. Гади мастердан – баш инженерга, аннары «Кама» леспромхозы директоры дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә Иван Захарович. Ул эшләгән елларда леспромхоз коллективы, ил күләмендә иң югары нәтиҗәләргә ирешеп, Хезмәт Кызыл байрагы орденына лаек була. Директор исә «Почёт билгесе», Ленин орденнары белән бүләкләнә. Татарстанның һәм Россиянең атказанган урманчысы И.З.Ивановка 1985 елда «Социалистик Хезмәт Герое» дигән мактаулы исем бирелә...

Әйе, Галәм үзенең ай-йолдызлары, халкыбыз исә үзенең батыр уллары һәм кызлары белән матур бит!.. Мамадыш районы җитәкчеләре шуны яхшы аңлап, киләчәккә карап эш итәләр.

Мамадыш муниципаль районы хакимияте башлыгы Анатолий Петрович Иванов

Редакциядән: *«Татмедиа» АҖ, «Безнең мирас» журналы редакциясе, Татарстан Фәннәр Академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты һәм Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе, «Әдәбият елы» уңаеннан, 2015 елның 20 мартында Мамадыш шәһәрендә «Керәшеннәрнең этник мәдәнияте, тарихы һәм хәзерге заман» дип аталган төбәкара фәнни-гамәли конференция оештыра.* ■

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ҖАВАБЫ

Җавапта Үгделмеш әйтте: – Хөкемдар,
Күрергә теләсәң чынлап, чара бар.

Боерыгыз гына – барам үзем мин,
Чакыртып яныма, әйтәм сүземне,

Төмән төрле сөйләп җанлы телемдин,
Эшкә җигеп акыл белән белемне.

Бетек язсын илбик үз кулы белән,
Ышансын ул егет чын күңеленә.

Бу эшләрне миннән дип үк белмәсен,
Тик фәрманны алгач, китә бирмәсен.

Ничек кенә сөйләп бирсәм дә телдән,
Илбикнең язуы – фәрманы бүтән.

Ни ди бер асыл зат (хәтергә багла):
Бий ярлыгы гаммә күңлен тиз аулар.

Ул белемле кеше әйткән, ди, үзе:
«Төенле күңелне чишәр бий сүзе.

Җылы сүз әйтелсә бийнең теленнән,
Озак чыгармас кол моны күңелдән.

Каю бийнең теле булса бик сөчек,
Аны халык сөяр, олы-кечесе».

ИЛБИКНЕҢ ҖАВАБЫ

– Чарасы шул булса, хуш, – диде илбик, –
Аңарга ау корам – языйм хат-бөтек[1].

Син дә язар булсаң, әйдә, хәзерлән.
Мин исә хат язам тик беръүземнән.

ИЛБИКНЕҢ ХАТЫ ҺӘМ ҮГЕТЕ

Дәвәт[2], кәгазь сорап язды бий хатны,
Бетек илә тәсдикъ итеп ниятне.

Ходай хакы белән башлап бөтеде:
«Түрәткән, үстергән, кичергән...» – диде.

Әйтте ки: – «Мин яздым Алла исемен,
Бу исем һәртөрле ауру-чиргә им.

Ходаема мактау – тәбригем сансыз.
Без түгел, ул чиксез, азаксыз, соңсыз.

*Дәвамы. 2013 елның 10 нчы саныннан басылып килә.
[1] Бөтек – язу, хат.
[2] Дәвәт – язу приборы (кара һәм каләм), хәзерге татар сөйләшләрендә дә еш очрый.

Йөрешергә кирәк кардәшләр белән, Аралашу мотлак илдәшләр белән.

Теләде – түрәтте һәр җан иясен,
Ашата, эчертә, таба җөясен.

Уган – Ходай бөек бүләк бирүче:
Яралган берәүгә бирә үз көчен.

Зәңгәр күк ялтты, ярыткыч ай, көн,
Кара төн, якты көн һәм ел тәүлеген.

Яралтты галәмне – ул әйләнәдер,
Ходай хөкеменчә тизгенләнәдер.

«Баегуга чик» дип яралтты каза.
Казага муеның бөк һәм бул риза.

Ни теләсә, кылды һәм тагын кылыр,
Ни әйтсә, шул булды һәм тагын булыр.

Сәлам соңра сорап хәлеңне, шуннан,
Хат язам исәнлек теләп, и, туган!

Җаның-тәнең саумы, исәнлектәме?
Ничек күтәрәсең гомер йөкләрен?

Ишеттем сиңа хас изге кылык, дип,
Бу заманда сиңа тиң вә иш юк, дип.

Илаһ кылган инде сиңа игелек:
Акыл биргән, ирдәм, зирәклек, белек.

Шул сыйфатларыңны ишеткәч, үзем
Хат язган булдым, и, намуслы йөзлем.

Җибәрәм кардәшең Үгделмешне мин,
Укып сүзләремне җиткерсен, димен.

Кавем-кардәш белән араны өзеп,
Авыл-шәһәрләрдән чөереп йөзең,

Ялгыз аулак тауга киткәнсең үзең.
Гыйбадәтең анда нишләп бик озын?

Кардәшләрең сиңа нәрсә эшләде?
Ничә йөз чөердең, ачык әйт әле.

Әгәр сиңа кемдер золым тигерсә,
Син миңа кайтып кил, уйлашыйк бергә.

Көч белән булса да гаделлек кылыйк,
Һәм син монда яшә шатланып-көлеп.

Кардәшнең кардәшкә тисен файдасы.
Барчабызга тату яшәргә язсын.

Йөрешергә кирәк кардәшләр белән,
Аралашу мотлак илдәшләр белән.

Кайда ярашу һәм килешүләр бар,
Шунда эш ырамлы, итсәң игътибар.

Ничек матур итеп бер шагыйрь әйткән:
«Ике шәй ярашса, шунда бәрәкәт.

Зәңгәр су ярышса кара җир белән,
Үләннәр яшәрә, чәчәкләр көлә;

Ничек матур итеп бер шагыйрь әйткән: «Ике шәй ярашса, шунда бәрәкәт...»

Танышлар ярашып бергә килсә бер,
Яңа буын туып, гөрләп үсәдер».

Әгәр бик теләсәң тагать кылырга,
Шәһәрдә мәчетләр бар дин юлында.

Авыл-калаларда күпләр дин тота,
Кыйммәтлерәктер дә мондагы дога.

Гыйлмең файда бирсен динең өчен дә,
Файда аздыр ялгыз гыйбадәтеңдә.

Инсаннар токымы ике төрледер:
Берсе өйрәтәдер, берсе өйрәнер.
Өйрәнмәсә дә һәм өйрәтмәсә дә,
Кеше түгел, хайван сыман нәрсәдер.

Син инде шуларның каюсы, әйтче?
Икенең бере бул, булма өченче.

Белем алган булсаң тырышлык белән,
Гыйлемне эшкә куй, тормышта куллан.

Белемең җитмәсә, өйрән янә дә,
Кулың тисен тагать-гыйбадәткә дә.

Ни ди, ишет, белкә-белем биргүче
(Белем белән бергә дин күверүче):

Зәңгәр су ярышса кара җир белән,
Үләннәр яшәрә, чәчәкләр көлә

«Гыйлем өйрән һәм бер Аллага табын,
Гыйлемең кисәтер – кайда бар капкын;
Белемле догасы наданныкыннан
Савабында өстен була мең тапкыр».

Белдексез догага чагыштырып бак:
Галимнең йокысы да саваплырак.

Авыл-калада күп гыйбадәт мәгәр,
Мондагы савап зур – ике-өч кәррә.

Синең гыйбадәтең гел намаз кылу
Һәм ураза тоту, шулаймы улым?

Тагын анда нинди гыйбадәт-тагать?
Телең белән миңа сөйләп бир, аңлат.

Үзең инде «заһидмын» дип аталдың
Һәм шулай үзеңә авыр йөк алдың.

Өстәвенә шуңа горурлансаң син,
Тагатең югалта бөтен мәгънәсен.

Гыйбадәтне кеше күзеннән сакла
Һәм, күпме кылсаң да, аз дип хисапла.

Гыйбадәте булса яхшы кешенең,
Халыктан яшерер ябып ишеген.

Ни диләр бит – шундый мәгънәле сүз бар
(И, иге зат, шуңа кылгыл игътибар):

«Ирән батырлыгын һәрчак күрсәтми,
Тагать итсә йөз ел, аз дип исәпли.

Яшертен дога кыл – кеше күрмәсен».
Бу сүзем ихластыр, тиген димә син.

Гыйбадәт кыл яшьрен. Игелек исә
Яхшырак, халыкка ачык ителсә.

Халыкка файда кыл, арасын төзәлт,
Кардәш-ыруыңа якынлык күрсәт.

Бигрәк тә ятимнәр, тол карчыкларга
Күзсез, чулакларга һәм аксакларга.

Җәмәгать берлә кыл фарыз намазын,
Һәм җомга намазын – фәкыйрьләр хаҗын.

Хәләл мал-туар тап, өләш ярлыга.
Адашканның кулын тот, чыгар юлга.

Гыйбадәткә тиңдер саналмыш эшләр.
Шуны эшләгән зат тынычта яшәр.

Ә син бу эшләрдән тәмам ваз кичеп,
Намаз, руза дисең, холыклы егет.

Намаз, руза ул тик үзеңә кызык.
Файдасызга яшәү – миһербансызлык!

Ни шәп әйткән илдә сайланмыш бер мән,
Халык мәнфәгате өчен көярмән:

«Рәхимле ир илгә бер афәт килсә,
Яхшыга-яманга бер ярдәм итә.

Адәм баласы ул ярдәмчел булсын,
Һәм шундый булмаса тумасын, үлсен».

Инсаннар токымы ике төрледер:
Берсе өйрәтәдер, берсе өйрәнер.
Өйрәнмәсә дә һәм өйрәтмәсә дә,
Кеше түгел, хайван сыман нәрсәдер.

Юньле зат кешегә ярдәмчел була,
Илгә нигез-терәк менә шундыйлар.

Гыйбадәткә генә салышкан затлар
Алла рәхмәтенә лаек булмаслар.

Ходайга сөенеч китерим дисәң,
Барча мөселманга сөенеч эстә.

Илаһ мохтаҗ түгел табынуыңа,
Иге исем казган. Менә шул, туган.

Тагатьсез, әлбәттә, кеше дә түгел,
Инсан икәнсең, син гыйбадәтне бел.

Тагать-гыйбадәтне калдырма һич тә,
Тагать юлын кара һәм китмә читкә.

Ләкин гыйлеме киң бераү әйткәнчә,
И, егет, гыйбадәт кылсаң да гәрчә,

Савапларым күп дин кылма горурлык:
Белмисең ич – синең догаң кабулмы?

Бәндәнең бурычы – гыйбадәт кылу,
Тәңре ихтыярыдыр кабул булу.

И, Уйгырмыш, сине тиргәп язганым
Үзем өчен, дип үк уйлама тагын.

Килешсәң, сүземнең файдасы сиңа,
Берни дә тимидер, югыйсә, миңа.

Халыкка хезмәткә сине өндимен,
Көчеңне бүтәнчә кулланма, димен.

Әйткән сүзләремә игътибар кыл да,
Чын тапсаң, кайтырга чык шундук юлга.

Минем белән бергә эшләвең кирәк;
Халыкны күтәрү – бу эш изгерәк.

Үзеңә эш, миңа изге ат алсаң,
Ике дөнья бәхтен бирер бер Аллам.

Миңа изгелек бир, үзең изге бул.
Иге ир кешегә төзер иге юл.

Минем изгелеккә сәбәпче бул син,
Савап бирер Алла, и, батыр дустым.

Ни ди, ишет, әнә бер таҗик белкә
(Таҗик галимнәре данлы һәр илдә):

«Каю бий иленә файда китерә,
Ил аңар шатланып көч-куәт бирә.

Сорама үзеңә – көч сора бийгә,
Бийгә сораганың – ул бөтен илгә!

Кара кемсә иге булса – үзенә,
Ә бий иге булса – халык көн күрә».

Кеше дип әйтәләр, кем соң ул кеше?
Кеше илгә файда китереп яши.

Бар адәм баласы мактый изгене,
Кая изге, аны мактыйк без бүген.

Белдексез догага чагыштырып бак:
Галимнең йокысы да саваплырак.

Шул ул изге – илгә игелек кылса,
Изгелеге илгә багышлы булса,

Рәхимле булыр ул – илгә изге зат,
Хәерле эш кылса, изгеләргә баш.

Моны сөйләп хатка юллар йөгерттем.
Сүземне төзәттем, каләмне сөрттем.

Әгәр калган булса тагы бер сүзем,
Кардәшең җиткерер – әйтер, аййөзем!

Төреп, бәйләп, тамга куйдырып, хатны
Үгделмеш кулына биреп озатты.

Һәм әйтте: – Бар, тагын нинди сүз белсәң,
Яраштырып әйтеп кара, и, бөкәм.

Каты тор, ничек тә алып кил бире,
Коры килмә ансыз, и, баһадирым.

Белкәләр ни диләр (беләсең үзең):
«Оста илче җибәр — озайтма сүзне»[3].

Сүз талкып торулар миңа ник инде:
И, тугрым, бар хикмәт сиңа билгеле.

Ниләр әйтәсеңне үзең беләсең,
Тап ысулын шунда, эшлә кирәген.

«Әйе», — диде торып чыкты Үгделмеш
(Ул ипле коллыкка яшьтән күнелмеш).

Атын менде, өйгә таба борылды.
Өйдә изүләрен чиште, кырынды.

Кояш башын иде һәм җиргә иңде,
Корымланды якты дөньяның йөзе.

Толымын төшерде күк, йөзен япты,
Толым илә астны-өстне каплатты.

Юынды Үгделмеш ястү намазга.
Түшәк алып ятты, оеп беразга.

[3] Күрәсең, борынгы мәкаль, «оста илче үзе дә ничек сөйләргә кирәкне белә» мәгънәсендә.

Гыйбадәткә генә салышкан затлар
Алла рәхмәтенә лаек булмаслар.

Биленләп уянды, күтәрде башын.
Күрде – кара зәңги бетерә эшен[4].

Торды, юынды һәм намазга басты,
Дога кылды, бераз тәсбихен тартты.

Алтынлы калканын кояш күтәрде;
Якты дөнья кинәт көлеп җибәрде.

...Иярләп бүз атын, тотып тезгенен,
Егет кардәшенә китте тиз генә.

Барып җиткәч тауга көн буе чабып,
Аттан төште, теге хөҗрәне табып.

Һәм әкерен генә ишек шакыды.
Узгырмыш уянды, ишек ачылды.

Кардәшен күргәч үк чыкты үзе дә.
Кочаклап алды һәм үпте йөзеннән.

Кулыннан алды һәм өенә кертте.
Урын бирде, кыстап, шунда утыртты.

Ниһаять, сөенде кардәш килүгә.
Кулларын күтәреп, кылдылар дога.

Ни куаныч-шатлык, кеше аерылып,
Исән-сау кавышса, кунакка килеп.

Ни изге эш – кардәш килсә еракттан,
Күрү өчен килсә, ихлас йөрәктән.

Ни күрекле нәрсә, күрче, әгәр дә
Фикердә булсалар кардәшләр бердәм.

Ни ди бераү: – «Әгәр булсаң шәфкатьле,
Күреш, яңартылып торсын кардәшлек.

Аерылган дуслар күрешсә берчак,
Сагыш була кыска, ә шатлык – озак.

Ни күрекле булыр ки без – туганнар
Аерылгач, исән һәм сау кавышсак».

Узгырмыш сорады кардәш-ыруын,
Үгделмеш әйтте бар да сау булуын.

– Хуш, – диде Уйгырмыш – безнең хозурга
Ничек килеп җиттең, хөрмәтләп-зурлап.

Ишеттем мин сине илбик белән, дип,
Халыкка хезмәттә алар бергә, дип.

Нигә килдең икән, эшең калдырып,
Ил йөген иңеннән бераз алдырып.

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ УЗГЫРМЫШКА ҖАВАБЫ

Җавапта Үгделмеш әйтте: – Мин үзем
Күрим әле, дидем, кардәшем йөзен.

Шуннан инде, кубып, күрергә килдем,
Сагыш төеннәрем чишелсен, дидем.

Илаһ мохтаҗ түгел табынуыңа,
Иге исем казган. Менә шул, туган.

Көсәндем мин күптән сине күрергә,
Бүген менә форсат таптым килергә.

Шактый вакыт үтте сине күргәнгә,
Вакыт табылмады үткән көннәрдә.

Инде форсат чыкты, менә килдем, күр,
Сиңа сөйләп торам, Аллага шөкер.

Шулай инде, бәндә тик исән булсын,
Максатына җитә, рәхимле дустым.

Ни ди бер эстәгән – көстәгән кеше –
Вакытның чамасын үлчәгән кеше:

Эзләгәнең, исән булсаң, табылыр,
Сагынышкан ярлар беркөн кавышыр.

Догалар кылгучы, исәнлек теләә:
Һәрнәрсә табыла исәнлек белән.

Мин дә теләгемә, шөкер, ирештем:
Исән булгач, синең белән күрештем.

[4] Ягъни, төн үткән, яктыра башлаган. Кара зәңги — кара (негр) кол — төн символы.

Бу – кереш. Моннан соң озын сүзем бар,
Аны сөйләп бирим, итсәң игътибар.

Якын күрүеңә бирсен бер Ходам,
Мең-мең төмән байлык белән изге дан.

Үзе теләгәнчә корса гомерен,
Кеше ансат яши, и, зур белемлем!

Ишет дөнья күргән кешенең сүзен,
Мәгънәсенә төшен, и, күңеле киң!

«Кайсы якка бакса теләк-мәелең,
Шул якка турыдан йөрү хәерле.
Җаның теләп барсаң, ерак җир — якын,
Барып җиткәч, әсир булыр күңелең».

Һәм, өстәп, Үгделмеш әйтте шул сүзен:
Сине уйлап, сине телдән төшермим.

Торлагыңны, кардәш-ыруны ташлап
Ерак чүлгә киттең. Һәм юк юлдаш та.

Ни изге эш – кардәш килсә ерактан,
Күрү өчен килсә, ихлас йөрәктән.

Үзеңә кыенлык йөкләп, ялгызың,
Ач-ялангач... Тиңсез батырсың үзең.

Туганнарың сине уйлый һәрбере,
Күңелләрен юат. Күрешеп йөре.

Ялгыз яши алмый Адәм баласы –
Кайчагында авырып-чирләп каласың.

Шуны уйлап өйдә ята белмәдең.
Синең хакта сагыш хисен җиңмәдем.

Сиңамы тик тәмуг яралткан Тәңре,
Яки бар газаплар сиңа дигәнме?

Ни бу, нигә болай азап чигәсең?
Ачык кына сөйлә – килә беләсем.

Дәвамы бар ■



КИРПЕЧ ЯСАУЧЫ
ШАПУР ҺӘМ ХУҖА МОЗАФФАР ХИКӘЯТЕ

Хикәяттә китерделәр:
– Кәзирун[1] шәһәрендә күркәм йөзле, һәйкәл кебек зифа сынлы, нечкә табигатьле Шапур атлы бер егет бар иде. Аның атасыннан мирас булып калган һөнәре кирпеч ясау иде. Һәркөн өйләгә тикле эшләр иде, акчасын алыр иде.

Вә бу егетнең гадәте шул иде: эшеннән чыккач, Кәзирун шәһәренең уенкөлке мәҗлес яратучыларына кушылып, алар белән бергә утырыр иде, рәбабны[2] күркәм чалыр иде, төрле көйләр уйнар иде. Һәркем аны сөяр иде, ансыз ул шәһәрдә мәҗлес булмас иде. Шул сыйфатлары белән, шул рәвешчә гомерен хушлыкта, рәхәттә кичерер иде.

Беркөн мәҗлесендә бер егет Багдад шәһәрен сыйфатлап, аның бик ямьле, күңелле шәһәр булуын мактап сөйләде. Аның сөйләве Шапурны кызыктырды,

[1] Кәзирун — Иранның көньяк-көнбатышындагы шәһәр.
[2] Рәбаб — кыллы музыка уен коралы.

ул Багдадны барып күрергә теләде. Хаҗ вакыты килеп җиткәч, билен баглады, Багдадка йөз тотты. Багдадка барып җитте, ишеткәненә караганда мең артык булды. Бер өйдә бер хөҗрә тапты. Хәленә ярашлы рәвештә киенде, ясанды, һәркөн иртәдән кичкә кадәр базарда, кибетләрдә, солтан мәйданында йөрер иде, күзенә нур, күңеленә яктылык табар иде. Төн җитәрәк ике кешелек табын өчен азык-төлек һәм шәраб әзерләп куяр иде. Бер күңел юаткыч кыз табып, аны хөҗрәсенә китереп, йөзен ул айга тотар иде, рәбабын кулына алып, һәр пыяланы эчкәнче бер сүз әйтеп, бер газәлне[3] көйләп бирер иде. Исерә башлагач, ул кыз белән бер ястыкка баш куяр иде…

Беркадәр вакыт шул рәвешчә көн итте. Менә берзаман хаҗга киткән ватандашлары әйләнеп кайттылар. Бу Шапурны үгетләделәр: «ватанга кайт», — диделәр. Моның бераз динарлары бар иде, шуны тотып бетермичә кайтып китүне кирәк тапмады, «киләчәк кәрван белән китәрмен әле», дип уйлады.

Шулай күңел ачып йөри торгач, акчалары җилгә очты, ачлыктан көч-хәл белән, абына-сөртенә йөри башлады, китәргә кәрван да булмады. Багдадта хәерче булып калды. Эш эзләп карады, таба алмады. Шул хәлгә җитте ки – бер мәчет почмагында урын табып, шунда тора башлады. Ул мәчет җәмәгате моңа көн дә ике ипи сәдака итеп бирәләр иде, шуңа канәгать булып утырды.

Раббының тәкъдире һәм күкләрнең хөкеме шулай булды:

Ул шәһәрдә бер олы сәүдәгәр бар иде, исемен Хуҗа Мозаффар диярләр иде, ул шушы мәчеттә намаз кылыр иде.

Беркөн күзе Шапурга төште, аны катына чакырды, әйтте:

— Әй, егет! Кайдан син, бу шәһәргә ничек килеп төштең?

Шапурның уена шул төште: «әгәр үземне мөлкәтле бер бай булган итеп күрсәтсәм, читтә гариблектә[4] йөргән кешегә моның гаебе булмас» дип, сүзгә кереште:

– Олы нәселдән чыккан егетмен, Кәзирун шәһәреннәнмен, күп мөлкәт вә нигъмәт иясе буларак, атаклы һәм билгеле атам бардыр, аты Габдулла сәүдәгәрдер. Мине Хиҗазга[5] бару теләге биләп алды, мең төрле ялыныч һәм тырышлык белән атам-анамның ризалыгын алдым, берникадәр хезмәтчеләр белән Хиҗазга юнәлдем. Багдад тирәсенә җиткәндә юлбасарлар пәйда булдылар, нүкәрләремне[6] үтерделәр, малымны талап алдылар, мине яралап киттеләр. Соңрак бу җиргә тикле килдем, бер кәрвансарай почмагында авырып яттым. Кәрван Хиҗаздан кайтып килгәндә әзерләнеп җитә алмадым, алар белән китә алмадым, авыр хәлдә, ярдәмчесез шушы мәчет почмагын ихтыяр иттем. Тәңренең рәхмәте белән мөселманнар мине карап, кайгыртып, сәдакалар белән исән-сау тоттылар, – диде.

Хөҗа Мозаффар моның бу хикәятен тыңлады, егетне ошатты:

– Нишлисең, моның кебек хәлләр күп була, — диде. Аннан Шапурга әйтте:

– Кайгырма, Тәңре хушлыклар бирсен. Әйдә, тор, минем өемә кайтабыз, – диде. Алды, өенә китте.

Шапур күрде: бик күркәм җир, биек һәм матур сарай, төрле-төрле төстәге келәмнәр түшәлгән, голәмнәр, кәнизәкләр солтан сараендагыча аягүрә басып, хезмәткә әзер торалар.

Хуҗа Мозаффар Шапурны янына алды, утырдылар, гадәтенчә ширбәт китерделәр. Үзенә салып алды, аннан Шапурга сузды, эчтеләр. Бераздан ризык

[3] Газәл — җиде яки күбрәк ике юллыктан торган лирик мактау шигыре.
[4] Гариблек — читтә йөрү.
[5] Хиҗаз — Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләре урнашкан урын.
[6] Нүкәр — кораллы хезмәтчеләр, сакчылар.

килде, һәр төстән үзенә бертөрле хәлвәләр алдына куйдылар. Хуҗаның уллары да утырдылар, бергәләп ашады-эчтеләр. Аннан соң табынга дога кылдылар.

Шапурны икенче көнне дә чакырдылар, аш өстәле җәйдереп, кунак иттеләр. Өченче көн дә шулай булды, ашау-эчүдән соң бер укымышлы әзер тора иде, ул Шапурның кулыннан тотып бер аулак бүлмәгә алып барды, әйтте:

– Бу Хуҗаның синнән бер теләге бардыр, кабул итсәң иде, – диде. – Теләге шулдыр: моның чибәрлек иясе булган кызы бардыр. Иренең авызыннан явыз сүз чыккан, талак[7] әйткән. Хәзер инде хатыны аңа хәрам булды[8], шуңа күрә хатынына икенче иргә чыгып алырга кирәк, аннан соң хәләл була. Инде менә никадәр кеше арасыннан атасы сине сайлап алды. Шуны эшләү кирәк булыр: ул кызны бүген сиңа никах итәбез, төнлә аның белән булырсың, иртәгесен аңа талак бирерсең. Бүләк итеп сиңа ун динар бирерләр, шуның белән көн күрерсең, кәрван белән Кәзирунга китәрсең, диде.

Шапур бу хәлне ишетте, үзен төш күрде дип санады, бармагын баш өстенә куйды:

– Яхшы булыр, хезмәт итәм, рәхмәтле булырмын, – диде. Мулла әйтте:

– Мин казыйның урынбасарымын, шәригать хөкемнәрен яхшы белермен, сиңа ант бирәм, таң аткач, озак та тормый хатынга талак бирерсең, – диде. Шапур:

– Хөкем синекедер, – диде. Мулла Шапурны каты ант иттереп, ул хатынны Шапурга никахландырды.

Кич белән кыз катына керде. Күрде: бер олы ятак куелган, түшәкләр салынган, йолдыз кебек нурлы бер кыз ятак өстендә утыра, кояш кебек көләч йөзле. Шапур бу халәтне күреп, акылы китте, һушсыз булып торды, ник дигәндә – ни аның кебек ай йөзлене күргәне юк, ни аның кебекнең тезенә тезен кушканы юк…

Кыскасы, бер-берсе белән сөйләштеләр, бер-берсен белештеләр, холыклары бер-берсенә хуш килде. Ә бу хатынның әлеге талак кылган ире атасының абзасы улы икән, бик холыксыз һәм тотрыксыз икән. Кыз Шапурның үткенлеген, егетлеген күргәч, мең җан белән гашыйк булды. Шапурга әйтте:

– Нишләсәң дә эшлә, тик мине кулыңнан җибәрмә. Таң аткач, казый кешесе килеп «хатынны бушат», диер, ни әйтерсең? – диде. Шапур әйтте:

– И ханым! Мин монда гарибмен[9], якын кешеләрем юк, ни эшләргә дә белмимен. Синең атаң, кардәшләрең һәм якыннарың олы затлардыр, алар белән ничек сөйләшим, ничек эш итим?! Мин сине югалту кайгысыннан үләрмен. Әгәр атам хәлемне белсә, алтын-көмеш, җәүһәрләр, тукымалар йөкләтеп кәрван җибәрер иде, мин аларны бу эшкә сарыф итәр идем, дошманны җибәрмәскә, киртәләргә мәшгуль булыр идем. Әмма бу мизгелдә миңа атам тарафыннан һич ярдәм юк.

Кыз әйтте:

– Һичшиксез һәрнәрсәдән котылу — ул Тәңре Кәрим вә Рәхимнәндер, тик Аннан гына мәрхәмәт ирешсә инде, – диде.

Шапур:

– Фәрман синекедер, кулымнан ни килсә, шуны эшләргә тырышырмын, – диде.

Бу заман болар бу сүздә икән, тыштан бер кәнизәк килде, кычкырды:

– Таң атты, торыгыз, инде бер-берегез белән сөйләшмәгез, кавышуыгызның төне ахырына җитте, аерылышу вакытыдыр, – диде.

Шапур салкын сулыш алып, күзеннән йөзенә кан агызып, кайгы-хәсрәтле булып тышка чыкты. Кыз түшәге өстендә кычкырып елап, йөзләрен тырнап утырды.

Шапур тышка чыккач та бер голәм каршы килде. Шапурны мунчага илтте,

[7] Талак — хатынны аерырга теләгәндә ир кеше тарафыннан өч мәртәбә әйтелә торган сүз.
[8] Хәрам булды — талактан соң ул хатын белән бәйләнешкә керү ярамый.
[9] Гариб — читтән килгән кеше.

башын-тәнен юды. Мунчадан чыккач та бер букчадан чиста, ару киемнәрен чыгарып өстенә кидерде.

Шапур Хуҗа Мозаффар катына килеп, хөрмәт күрсәтеп, утырды. Ширбәт килде – эчелде, ризык килде – ашалды. Аулак калгач, мулла Шапурны алды, бер бүлмәгә алып барды, ун мыскал[10] алтын һәм бер багдади чалма Шапурның уңында куйды. Әйтте:

– Олы нәсел углысың, белерсең: бу эшне яшертен кылырлар, бу шәһәрдә бу эшкә күп кешеләр бар иде, әмма Хуҗа сине ихтыяр итте, сайлап алды. Олы нәселдәнсең һәм гарибсең, инде хатынга талак бир, – диде.

Шапур тавыш күтәрде:

– Мин саный идем: гаделлек, хаклык һәм чын мөселманлык галәмгә хәлифәт башкаласы Багдадтан җәелә, дип. Минем бу уем ялгыш икән, мине бер кызга шәригать тәртибе буенча никахландырдылар, инде бу заман алдап «хатынга талак бир!» дип әйтәләр, мәгәр мондый эшләрне җир йөзенең хәлифәсе, мөэминнәрнең әмире белән, дип уйлыйлармы? Алай булса, ни өчен бу эшләрне болай итәләр?

Муллага мөрәҗәгать итеп әйтте:

– Син олы кешесең, башка моның кебек сүз сөйләмә, югыйсә хәлифә капкасына барып, башыма туфрак чәчәрмен, ул вакыт белерсең – үзеңә ни килер. Мәгәр сез мине гаҗиз һәм ярдәмчесез күрдегез, шуның өчен бу эшне миңа ягасыз. Менә аз көннән атамның коллары килеп җитешсә, кемнең углы икәнен белерсез, – дип бу хакта шактый сүзгә ялган үреп сөйләде.

Мулла Хуҗа Мозаффар катына барды, ишеткәнен җиткерде һәм әйтте:

– Бу кеше мескен һәм борчулы хәлдә, бу сүзләрне комсызлыктан сөйли, ул алтыннарны егерме итик, шаять риза булыр, – диде.

Хуҗа боерды, ун динар китерделәр, теге ун динар өстенә куйдылар, егерме динар булды.

Мулла янә ул акчаларны Шапурга илтте:

– Менә сумма аз дисәң, артыгы белән булды, – диде.

Шапур динарларны күрде, тагы каты тавыш куптарды, өне Гаюк[11] йолдызына җитте. Мулла әйтте:

– Ярар, бүген сабыр итик, иртәгесен эшне бетерербез, – диде.

Шапур торды, өенә китте, маҗараны хатынына сөйләп бирде. Хатын әйтте:

– Эшеңне Тәңре уң итәр, иртәгә тикле ирем булырсың, иртәгесен хәл ничек булыр – күрербез, – диде.

Менә кич җитте, яңадан ишекләрне бикләделәр, таңга чаклы кәеф-сафа сөрүдә булдылар, бер-берсенә мәхәббәтләре сәгать саен артыр иде, гыйшык дәрте күзләрен каплар иде…

Таң вакыты җитте, кыз әйтте:

– Сине иртән иртүк казыйга илтерләр, зинһар, аның янында нык тор, бүген тагын талак әйтүдән котылсаң, бәлки иртәгә берәр җае чыгар.

Таң атты, Шапурны гадәттәгечә мунчага илттеләр. Мунчадан чыкты, мулла яңадан килде:

– Менә тагын бер букча кием, утыз динар китердем, дәүләтеңне кабул ит, башка буш хыялга бирелмә. Әгәр «юк» дисәң, бу да кулыңнан чыгар, рисвай[12] булырсың, таяк ашарсың, – диде.

Бу хакта никадәр сөйләсә дә, Шапур колагына элмәде, муллага юк-бар, ахмаклыклар сөйләде:

– Моның кадәр хурлаулар, сезнең катыгызда тиешле тоеладыр, мәгәр мең динар

[10] Мыскал — авырлык үлчәме, 4,6 грамм.
[11] Гаюк — иң якты йолдызларның берсе.

бирсәгез дә минем егетлегем, олылыгым янында туфрак кебек түбәндер, әгәр кемдер хатынына талак бирәсе килсә — бирсен, әмма мин бирмим! – диде.

Мулла, гаҗиз калып, Хуҗа Мозаффар катына барды:

– Бу кешедә баш юктыр, бу эшнең тыныч кына бетәсе булмады, моны казый катына илтеп йөз суын түгү кирәк, – диде.

Шулай карар иттеләр, Хуҗа уллары белән бергә кычкырыш һәм кайнарлык белән Шапурны хөкемгә казый янына илттеләр, хәлне аңлатып бирделәр:

– Бу эшеңне уйлап эшлә, ахырда үзеңә зыяны тимәсен. Әгәр ул динарлар гына җитмәсә, илле итсеннәр, тулы хәзерлек белән ватаныңа юлласыннар, хезмәтчеләр бирсеннәр, ә син бу эшне ахырына җиткер, нәфесеңне куй. Әгәр сүземне тыңламасаң, мин шәригать юлы белән бу эшне ахырына җиткерермен, чөнки син боларның тиңе түгелсең, ризык табудан гаҗиз билгесез бер кешесең, дәрвишсең, бу шәһәрдә сине белгән кеше юк, мескен хәерчесең, хатынның атасы һәм туганнары мәшһүр вә маллы хуҗалардыр, синең болар белән ни катышың булсын! – диде.

– Хөрмәтле вә гыйззәтле казый әфәнде! Яшең озын булсын, хәлифәт күләгәсендә һәм аның бусагасы төбендә моның кебек золым тиеш түгел, гәрчә мин гарибмен, читтән килгән бер кешемен, әмма сез уйлаганча түбән кеше түгелмен, мин үз шәһәремдә мал-нигъмәт һәм югары дәрәҗә иясемен, болардан ким түгелмен. Әгәр дә шундый яман вакыйгага юлыкканмын икән, мондый эшләр күп адәмнәрнең башыннан үтәр, моның гаебе юктыр. Бүген-иртәгә атамнан хәбәр килә, мал вә әсбап китерәләр, шулар миңа җитәр, – диде.

Моның бу сүзеннән соң казый артык нәрсә әйтә алмады, мәҗлес таралды, һәркем үз җиренә китте.

Шапур хатыны янына кайтты, баштан үткән хәлләрне сөйләде. Шөкер иттеләр, таңга кадәр кәеф-сафа сөрүдә булдылар.

Таң аткач кыз елады:

– Шуннан куркам: сине субашка[13] илтерләр, җәзаларлар, газапларга түзмәссең, талакны кулдан чыгарырсың, әмма сабыр итә белсәң, түзә алсаң, яхшы булыр иде, – диде.

Шапур өйдән тышка чыкты, күрде; шәһәр халкы капка төбенә җыелган. Шапурны тоттылар, әмир катына илттеләр. Шапур карады: шәһәр башлыгын күрде, нык һәм усал кешедер, ничәмә-ничә ир вә хатын-кыз, азат вә кол диванында[14] торырлар. Курыкты, әмма Тәңрегә тәвәккәл итте[15], үзен-үзе тотты. Бераз торгач, бу бәк әйтте:

– Бу ни эш: син ни кыласың? Шуны белмисеңме: Хуҗа Мозаффар кебек олы кеше сиңа кызын куячак түгел, биргәннәрен кабул итеп, хатынны үз юлына җибәрсәң, син үз юлыңа китсәң, ни булыр? Бу син эшләгән эш ни тилелек? Юкса, шуны телисеңме: боерам, таяк белән суктырып таныклыгыңны алырлар, – диде. Шапур әйтте:

– Әгәр Багдад шәһәрендә, хәлифәтнең чыганагында гадәт шундый булса, икрар таяк белән суктырудан алына икән, алыгыз, ни эшлим, гадел хөкем бары тик Аллаһтандыр, – диде. Шулвакыт әмир әйтте:

– Шулкадәр үгетләдем, тыңламады, инде җәза мәйданына күтәрсеннәр! – диде.

Шунда ук җәза урынына күтәрделәр, йөзгә якын таяк ордылар. «Аһ!» дигән аваз чыгармады, талакны әйтмәде…

Ахыры киләсе санда

Текстны басмага
Нәҗип Нәккаш-Исмәгыйль әзерләде. ■

---

[12] Рисвай булу – хурлыкка калу.
[13] Субаш – полиция башлыгы.
[14] Диван – сарайда утырышлар, җыелышлар залы.
[15] Тәвәккәл итте – тапшырды.

АЧЫ ТӘҖРИБӘ АВАЗЫ

....

Габдулла Тукай

● Кеше арасында гашыйкка өстенлек мәңге юк.

● И Хода, бир акыл, тоткыннар йортына эләкмим — ...гыйшкым сәбәпле диванамын, диванамын.

● Керпе үзенең кабыгына кереп яшеренгән төсле, мин дә сөю хакында бернәрсә язсам, ялган имзалар астына сыгынам.

***

● Өч кешедән дөньяда качып котылып булмый: берсе — кендек әбиседер ки, ул сине теләсәң дә, теләмәсәң дә дөньяга тартып чыгарыр. Икенчесе — яучы карчыктыр. Ул сине, аласы кызыңны күрсәң дә, күрмәсәң дә, алырга теләсәң дә, теләмәсәң дә — өйләндерер. Өченчесе — мәзиндер. Ул сине теләсәң дә, теләмәсәң дә — җуар да күмәр.

● Гаилә хакында минем фикерем коры гына: әгәр кече яшьтән фәләнне... сүә-истигъмаль итеп[54], рәфыйкаңнең[55] синдәге хакын бөтенләй үк тәләф итмәгән[56] булсаң, син — аны, ул сине якыннан белеп яратышсаң, шуның өстенә шәрмәндәи гыял[57] булмасын өчен, иң азында ел тәүлегенә биш йөз тәңкә килерең булса, һәркемгә өйләнү тиеш. Югыйсә, эчеңә сәнәк белән төрткәндә, бер тамчы кан чыкмаслык булса, ике күңелдә чын мәгънәсе белән булган мәхәббәт уты янмаса, гаилә өчен әллә нинди түбән кешеләргә мөрәҗәгать йә тәлинкә тотарга булса — Алла сакласын!

● Тигез — тиңлеккә юл куймау бездә гадәт. Ярың тиң-пар булмаса, әлбәттә, һәлакәт, пар булу шарт... Өйләнештә иң кирәге — тигезлек.

● Хәзерге өйләнүчеләр... Күңелләр саф чыгында шәп, матур кыз сайлыйлар анлар... Әгәр дә басса дөнья һәм муеннарда бурыч тулса, убырлы карчыгыңны да алырлар, акчасы булса.

● Бар микән дөньяда миннән бәхетсезләр?! Хатыным, йортым юк — ятам номерда.

● Күңелсез сүз сөйли бәгъзе гакыллылар хатын-кызга: фәкать бер ел күңелле, дип, календарь һәм хатын безгә.

● Уйнаш кыйлуы бик уңгай да, бала табуы бик читен, диләр.

● Әгәр булсын дисәң бер өй эче шаушу вә җәнҗалсыз: ире булса сукыр, ул җитми — булсын һәм хатын телсез.

Әгәр ир тирече булса — хатыны өчен үз тиресен дә базарга чыгарыр.

***

● Кирәк анчак яшәр микъдар ашарга, кирәкми тик ашарга дип яшәргә.

● Тән үстерсәң — җиһанда, бер дә шиксез, фил булу мөмкин.

● Тәмле булганга гаҗәпләнмә бу байлар ашлары, күп вакыт борычы, тозы — мескин гидайлар[58] яшьләре.

● И бәрәңге! Син, бәрәңге! Кил, бәрәңге — җан ашым; син генә тәмләтәсең бар ярлылар, байлар ашын.

Сүзлекчә:

[54] Сүә-истигъмаль итү — бу урында «җенси азгынлык» мәгънәсендә;

[55] Рәфыйка — хатын;

[56] Тәләф итү — юкка чыгару;

[57] Шәрмәндәи гыял — гаиләне оятка калдыру;

[58] Гидайлар — ярлы-ябагай;

Дәвамы бар

Текстны басмага ***Зиннур Мансуров*** *әзерләде.* ■

Яңа шигырь туа. «Кызыл таң» газетасы редакциясе. 1952 ел

АТНАБАЙ КАНАТЫ АСТЫНДА

Марат Кәбиров

3. АТНАБАЙ ПРЕМИЯСЕ

Алдан бәян ителгән очрашу вакытында шигырьләремне калдырган идем. Бераздан алар «Кызыл таң» газетасында зур шәлкем булып, Әнгам Атнабаевның кереш сүзе белән басылып та чыкты.

Мин әле бу хакта белмим. Училищеда «ярым хәрби» тәртип хөкем сөрә. Иртән безне «линейка»га тезәләр. Һәрбер төркемнең старостасы директор урынбасары каршына басып, үткән атна нәтиҗәләре турында рапорт бирергә тиеш. Мин дә шуңа әзерләнеп басып торам. Ләкин… бу юлы андый нәрсә булмады. Хәниф Абдуллович тезелешкән студентлар уртасына чыкты да бер генә сүз әйтте:

— Кәбиров!

Директор кырыс холыклы кеше. Тавышы бөердән чыга. Чебен очканны ишетерлек тынлык урнашты. Бер адым алга атладым.

— Тә-әк… — Хафизов шул рәвешле барыбызны да айкап чыга да, тавышын бераз йомшартып, миңа дәшә. — Чык әле алгарак…

Ахыры. Башы 2 нче санда.

Мин кыюсыз гына уртага күчәм. Төркемемдә кем тәртип бозды икән? Нәрсә булды икән? Директор һаман суза...

— Син нәрсә, — дип, бераздан миңа төбәлә Хафизов. — Әллә үзең дә белмисеңме?

Баш чайкыйм.

— Тагын кемнәр белми? — Хәниф Абдуллович карашы белән һәркемне сөзеп чыккандай итә. — Сез дә белмисезме?

Рәтләр буенча «Ә нәрсә булган?», «Кем нәрсә эшләгән?» дигәнрәк пышылдашулар йөгереп уза. Директор кулындагы «Кызыл таң»ны ача:

— Менә нәрсә булган! Газетага язганнар!

Хафизовның тавышы көр, кырыс. Шатланамы ул, ачуланамы — һич аңларлык түгел. Киеренке халәттәбез.

— Әнгам Атнабаев үзе язган! — ди дә директор, кычкырып укый башлый.

Моңа кадәр билгесезлектән ни кыларга белми торсам, хәзер сөенечкә түзеп булмый! Ирексездән ерыла барган авызны ничек тә җыярга тырышам. Башкаларның да кәефе күтәрелә. Иреннәргә елмаю куна. Моңарчы саклыгын җуймаган карашлар ягымлы яктылык белән мине сыйпап үтә.

— Менә бит ничек, — ди Хафизов, укуыннан бүленеп. — Ишетәсеңме, Кәбиров! Әнгам менә нәрсә яза синең турыда, ә!

Хәзер инде аның тавышында соклану, горурлану сизелә. Ул укып бетерә дә:

— Бу вакыйганы болай гына калдырырга ярамый, — дип нәтиҗә чыгара.

— Директор белән бер «ярты» бушатасыз инде болай булгач, — дип пышылдый кайсыдыр шаяны. — Юарга кирәк, ди бит...

— Стипендия аласыңмы? — дип миңа төбәлә Хафизов. — Шуңа өстәп, премия дә алырсың!

Алкышлар, алкышлар!.. Ирексездән, мәктәптә грамота алырга тилмереп йөргән чагымны хәтерләдем.

Казанда Татарстан һәм Башкортстан язучылары очрашкач. Уңнан сулга, арткы рәттә: Ә.Еники, Р.Гаташ, Р.Ишморат, Ә.Атнабай, З.Нури, Ш.Галиев, М.Кәримов, Р.Төхфәтуллин, Ә.Баян. Алгы рәттә: Г.Ахунов, Р.Сафин, К.Кинҗәбулатова, Ә.Исхак, Ф.Исәнгулов. 1967 ел

Ирендәге елмаю дертләп куйды. Бер генә мизгелгә...

Төштән соң ук премия акчасын китереп бирделәр. Мин аны күңелемнән генә «Атнабай премиясе» дип атадым. Бу — әдәбият өлкәсендә алган иң беренче бүләгем иде.

Сүз монда Әнгам абыйның үзе турында гына түгел. Сүз аның үзеннән башка да хәрәкәт итә торган көч — Шагыйрь рухы, Атнабай рухы турында бара... Әдәбиятка мине Атнабай рухы тартып китерде. Атнабай рухы якты күңелле кешеләр белән очраштырды. Дуслаштырды, аралаштырды. Шәхес буларак ныгыган чакта таяныч булды. Нәкъ менә үз шигырендәге кебек:

Абый кирәк —
Кайчагында
Барлыгын тою җитә,
«Мин абыйлы» дигән уй да
Кешене кыю итә.

Кайчагында, әгәр тормыш юлымда Атнабай очрамаса, ни булыр иде икән, дип уйлап куям... Һәм ул хәлне күз алдына китерә алмыйм...

4. ОСТАЗ

Мин Уфага килгәч, Әнгам абый белән ярыйсы ук аралашып яшәдек без. Күңелем төшкән чакларда да, күкрәгемә сыймас шатлыгым булса да, аңа бардым. Озаграк күренми торсам, үзе телефоннан шылтырата иде:

— Кая югалдың син? Кил!

Хәләл җефете Сәвия апа да һәрвакыт ачык йөз белән каршы ала, килеп керүгә, табын әзерләргә тотына: «Син бит студент кеше, хәстәрләп торучың юктыр, тартынып торма», — ди. Хәл-әхвәл сораша... Әни кебек.

Мин ул ханымга һәрвакыт сокланып карыйм. Шагыйрьгә беркайчан да җиңел түгел! Гомере сөргендә үтмәсә дә, башларын балта кисмәсә дә, җан өзгеч чорлары күп аның.... Шундый чакларда таяныч була алу, шагыйрь язмышын уртаклаша алу сәләте бөтен хатын-кызга да бирелмәгән, шагыйрь хатыны булып кала алу өчен дә аерым бер талант кирәк, ахрысы. Әгәр, бер могҗиза белән, «атказанган шагыйрь хатыны» дигән мактаулы исем барлыкка килсә, аңа, һичшиксез, Сәвия апа да лаек табылыр иде...

Сәвия апа йорттан кеше өзелмәүгә күнегеп беткән инде. Чөнки Атнабай канаты астында бихисап иҗат әһелләре үсеп чыкты, күбесе хәзерге татар, башкорт әдәбиятының әйдәп баручыларына әверелде. Яшь чакларында менә шушы гади дә, гали дә Атнабай йортына бик еш килгән алар: куанычлары барда да, кәефләре юкта да, карыннары ачта да...

Мин шуларның иң кечкенәсе идем. Әнгам абый белән Сәвия апа да, бусагадан атлавыма: «О, безнең кече улыбыз килгән!» — дип каршыларга гадәтләнде. Миңа, әтисез үскән малайга, Әнгам абыйның: «Улым», — дип әйтүен ишетү рәхәт иде, билгеле. Һәм мин аны, чыннан да, әтием итеп, рухи әтием итеп яраттым.

Атнабайның шәкерте булу шактый авыр. Ул шигърияткә, әдәбиятка, иҗатчының үз-үзен тотышына да таләпчән, кискен, җитешсезлекләреңне әйткәндә хәтта бераз аяусызрак та. Уратып-чуратып, салпы ягыңа салам кыстырып тормый, турыга яра да сала: чыдасаң — чыда, чыдамасаң — утырып ела, йә ишекне бәреп чыгып кит. Ләкин... түзәсең. Чөнки ул — бөек остаз, ул гадел хөкем йөртә, әдәби иҗатның авырлыгын да, тормышның мәрхәмәтсезлеген дә яхшы белә, сине шул кырыс чынбарлык белән якалашырга әзерли.

Мондый чакларда Сәвия апа безнең янга килеп бер әйләнә... ике... Өченчесендә түзми, әйтеп куя:

— Җитәр инде! Бала гына бит әле ул...

Атнабай «безне аңламый бу, әйеме» дигәндәй, карашын миңа төбәп ала да, елмаюын тыебрак, каршы төшә:

— Нишләп бала булсын ди! Шагыйрь ул!

— Унсигезе дә тулмаган бит әле...

— Шулаймыни...

Аның тәнкыйте дә, мактавы да һәрвакыт төпле, нигезле. Һәр сүзенең изге ният белән әйтелгәнен беләсең, шуңа кимсенмисең дә, һаваланмыйсың да. Әтиләрчә усал, әтиләрчә назлы иде Атнабай.

Газета-журналларда басылган язмаларыңны укып бара. Шундук телефоннан шылтырата. Саран гына мактап ала. Яки җитешсезлегеңне күрсәтә. Халыкның яраткан шагыйре авызыннан нәрсә ишетү дә (уңай сүз булсын, тискәре сүз булсын) куаныч. Атнабай чаклы Атнабай укыгач, ул кадәр хөрти язмыйимдыр, ахры, дип юанып та куясың...

Әйткәнемчә, бүгенге көндә Башкортстанда күренекле саналган шагыйрьләрнең күбесе Атнабай йортында үскән, шул йорттан туп-туры зур әдәбият дөньясына чыгып (кереп!) киткән. Безне каләмгә дә Атнабай иҗаты тарткандыр, дип уйлыйм, чөнки барыбызның да яшьлек шигырьләрендә атнабайлык ярылып ята бит: сукырларча иярүләр дә бар, аның алымнарын үзебезчә дәвам итәргә тырышу да, темалар, шигъри бизәкләр уртаклыгы да... Кайберләребез тормышка Атнабайча карарга да өйрәнде бугай. Аның мыек астыннан елмаюын, ихласлыгын, горурлыгын, намуслылыгын үзенә күчерде.

Атнабай йорты — Шагыйрь Рухы тәрбияләү мәктәбе иде. Һәм ул мәктәп, әдәбият гыйлеменә өйрәтү белән бергә, каләм әһеленә хас булырга тиеш кешелек сыйфатларын да сеңдерергә алынды, принципларын сатмый, ялагайлана, куштанлана белми торган шәхес тәрбияләүне максат итеп куйды.

Әдәбиятны — халыктан, халыкны — әдәбияттан читләштерергә маташкан дәвердә бу игелекле йорт Башкортстандагы татар әдәбиятының мәркәзе вазифасын үтәде. Әнгам Атнабаев,

«Төшеп калган эттән түгелсеңдер, күз карашың болай акыллы...» 1979 ел

язучыларның үз-үзенә бикләнә баруын күреп, аларга аралашып яшәү, бер-берсенә терәк булу өчен этәргеч бирергә тырышты... Без һәрвакыт аның барлыгын, ихтирамлы игътибарын тоеп яшәдек. Андый остазың булу — бәхет, язмыш бүләге. Ул бәхеткә, ул бүләккә бик күпләр ирешә алды: Роберт Миңнуллин, Госман Садә, Ринат Хәйри, Рәдиф Гаташ, Рәдиф Тимершин, Салават Рәхмәтулла...

Ләкин Атнабай шагыйрьләрнең генә остазы булып калмады. Ул моңа кадәр әдәбият белән бөтенләй кызыксынмаган кешеләрне дә шигырь яратырга мәҗбүр итте. Яшь талантларны — язарга, ә халыкны — шигырь укырга өйрәтте ул. Һәм шуның белән халыкның да бер остазына әверелде.

ӘНГАМ АТНАБАЕВ
шигырьләре

КЕШЕГӘ НӘРСӘ ҖИТМИ?

Бу кешегә һәрчак нидер җитми:
Кара икмәк булса, ак җитми,
Шуышып йөргән чакта — аяк җитми,
Җәяү йөргән чакта — ат җитми,
Аты булса, машинасы җитми,
Очар өчен ракетасы җитми,
Планетасы җитми…
Күк җитми…
Бу кешегә ифрат күп җитми.

Шул кешегә ләкин кайчагында,
Башларына кайгы төшепме,
Бинахакка кайгы күтәрепме,
Гамьсезлектән җаны өшепме,
Ап-акны да кап-карага буяп,
Матурны да ямьсез күргәндә,
Якты дөнья белән бәхилләшеп,
Һәлакәтен эзләп йөргәндә, —
Шул юлыннан тартып алыр өчен,
Бу кешегә ифрат аз җитә:
Бер җылы сүз — Күңел эретерлек наз җитә.

УФА — КАЗАН

Уфа дисең дә мактыйсың,
Уфадан туйдым инде,
Гомеремдә күрмәсәм дә,
Үкенмәс булдым инде.

Казан калалары матур,
Сагындым Казанымны,
Укып йөргән елларымны,
Мәхәббәт газабымны.

Яшьлек үткән юлларымнан
Казанга кабат китәм.
Бер күрергә зар булырсыз —
Уфага кайтмам бүтән.
Казанга китәм, китәм!
Елларына әллә ничә
Кабатлана шул хатам.
Казанны сагынып барам да
Уфамны сагынып кайтам.

КАРА ИКМӘК

Әнкәй миңа кара икмәк, чәйнәп,
Имезлеккә салып биргән дә,
Үзе киткән урак урырга…
Елаганмын,
ләкин чыдаганмын —
Икмәк белән була торырга.

Кара икмәк бәләкәйдән таныш,
Беләм аның кыйммәт икәнен,
Бер телеме өчен
кешеләрнең
Таңга кадәр чират көткәнен.

Кара икмәк зур мәсьәлә булган:
Йөз граммлап аны бүлгәннәр,
Кош теледәй шул граммнар өчен
Сугышканнар,
хәтта үлгәннәр…

Шул чакларны онытабыз бугай,
Әйтерсең лә, күктән төшкәнбез.
Беребез дә күктән төшмәгәнбез,
Кара икмәк ашап үскәнбез.

Ул вакытлар мәңге кире кайтмас,
Без ашыйбыз хәзер калачын,
Тик калачның тәмен белер өчен
Онытмаек аның карасын.

Онытмаек
җәйге челләләрдә
Җиң сызганып кемнәр игкәнен,
Онытмаек бәрәкәтле җирнең —
Кара җирнең кара икмәген!

ЫШАНАСЫ КИЛМИ

Кичә берәү бу дөньядан китте,
Каршы торалмады үлемгә.
Кеше гомере мәңге түгелгә
Кыен булып куйды күңелгә.

Кыен булды…
Ләкин бүген иртән
Кояш чыкты, көлеп, кызарып.
Вак-вак басып,
көянтәсен асып,
Суга китте күрше кызлары.

Җилләр исте…
Җилләр түбән очтан
Алып килде төтен исләрен.
«Кемнәр бүген кунак чакыра икән,
Иртә яккан шулай мичләрен?

Кемнәр икән бүген шатланыр —
Хатлар алыр икән ерактан?
Кайсы кызның бәхете җиңәр икән —
Кемнәр кайтыр икән солдаттан?..»

Уйларымны челпәрәмә ватып,
Килеп керде күршем атылып, —
Үзе көлә, үзе аптырый —
Игез малай тапкан хатыны!

Җир өстендә яңа көн башланды,
Җиңел булып китте күңелгә.
Җиңелмәслек нәрсә түгел лә —
Ышанасы килми үлемгә,
Кеше гомере мәңге түгелгә.

***

Р-га

Син китәргә тиеш бөтенләйгә —
Вагон тоткасына үрелдең.
Күз җитеп тә әле өлгермәгән,
Язны сагынып та өлгердем.

Бар табигать үксеп елый сыман:
Елый таллар…
Елый болытлар…
Болытлардан кургаш тамчы тама,
Кургаштан да авыр минутлар.

Ара якын:
тик бер генә адым,
Атлыйсы да
Атыласы синең кочакка,
Һәм янасы
бөтен гомер буе
Кочаклашып шушы учакта.

Ара якын,
ләкин кешеләрнең
Язмышлары ята арада.
Язлар белән күз арасы ерак —
Бигрәк ерак безнең аралар.

Еласыннар таллар…
Болытлар…
Һәм елгалар чыксын ярыннан! —
Тимер юлда рельслар да шулай —
Мәңге бергә,
мәңге аерылган.

ТУФРАК

Түш кесәгә салып йөртәсе бар
Үзебезнең туган туфракны;
Тирләр тамып яргаланып кипкән,
Кайгылардан кара янып беткән,
Туйдыручы туган туфракны.

Шул туфрактан чыккан малайлар без,
Кендегебез шуңа ябышкан.
Аермабыз, булса, чак кынадыр
Шул туфракта үскән арыштан.

Арыш үскән җирнең хуҗасы без,
Килмәгәнбез аңа кунакка.
Тереләр дә атлый шул туфрактан,
Үлеләр дә — шул ук туфракта.

Безне язмыш кайчак илтеп бәрә
Күз күреме җитмәс якларга.
Каф таулары аша бәндәләрне
Шушы туфрак тартып кайтара.

Тирләр тамып яргаланып кипкән,
Кайгылардан кара янып беткән
Туйдыручы гомум туракны —
Үзебезнең туган туфракны

Түш кесәгә салып йөртәсе бар.
Белеп бетермибез кадерен.
…Кай туфракта булса туган йортым,
Шул туфракта булсын каберем. ■

БЕР СҮЗДӘН ТОРА ДӨНЬЯ...

Рүзәл Мөхәммәтша

Иң әүвәле Сүз булган... Изге китапларның берсе шулай дип башлана. Шагыйрь-шогара халкы, ихтимал, бу гыйбарәне күңелендә шигарь итеп йөртәдер, чөнки Сүз аның өчен эш коралы да, яшәү максаты да, ризык-тәгаме дә (хәер, бүгенге вазгыятьтә бусын төшереп калдырсаң да зыян юк). Дөньясы-каһәреннән арынып иҗат утына чумган һәм кирәкле бер кәлимә валчыгын табарга изаланып, башыңда бөтерелгән мең-мең лексик берәмлекне капшаган халәтне ничек аңлатып бирмәк кирәк? Инде шул мизгелдә, рәхәт газабыңның рәхмәте булып, гарештән көтелгән җәүһәрең дә иңсәме!..



Зөлфәт

Шуңа күрә шагыйрь һәрвакыт эзләнүдә, язганын төзәтүдә, дөресләүдә, бер төшенчәне икенчесенә алыштыруда, үзгәртүдә. Кайвакыт бу, билгеле, артыгын кыланып ташлауга да китерергә мөмкин — әйтик, **Хәсән Туфан** шигырьләренең вариантларында адашып үләрлек.

Әмма, ни кызганыч, иҗат эшен авыр, җитди, җаваплы хезмәт санамыйча, «тезмәне» күктән (яисә башка җирдән) төшкән рәвешле генә акламага күчерүчеләр, аннан соң яңадан карап-төзәтеп түгел, хәтта укып чыгарга, җөмлә төзеклеген, хәреф ха-

тасын, сүз мәгънәсен барларга кирәк санамаучыларның саны күпкә күбрәк шул бүген…

Без хәзер бергәләп күз төшерәсе шигырьләр киңкатлам укучыга яхшы таныш. Беренчесе — Зөлфәтнең Мөдәррис Әгъләмгә багышланган «Карлар тик тора»сы, икенчесе — **Мөдәррис Әгъләмнең**, багышлаусыз булса да, **Зөлфәткә** аталган шигыре — «Татарстаным».

Тукта, мизгел! Шигырь укыйбыз…

КАРЛАР ТИК ТОРА

Мөдәррис Әгъләмгә

Бүген моңсу…
Иске зур каланың
Үзеннән дә иске йортында
Авыр уйлар килеп *тукталалар*,
Яңа уйлар
йөрәк портына.

Их син, сәях дустым, нәни гигант!
Без — ракета күк, тик бер аерма:
Ракетаның тыш катлавы яна,
Безнең исә — йөрәк,
тойгыларның
Атмосфера катлауларында.

Илне дөртләтерлек янгын ята
Җил иркендә калган күмердә.
Илдә көчек булсаң да бик ярый,
Тик ил өчен кирәк өрергә!

Чатнап күктә* яна яшен ташы,
Төшмәгән ул ләкин күкләрдән, —
Шул ут безне җиргә атып бәргән.
Шул ут безне күккә күтәргән.

Сырттан сыйпамыйлар —
куркынычтыр! —
Тик кирәкми авыр суларга:
Илдә бүре булсаң да бик ярый,
Тик ил өчен кирәк уларга!

…Ага вакыт җиргә ак кар булып,
Ага еллар, уза гомерләр.
Беренче кар булсаң да бик ярый —
Ил җанында кирәк эрергә.

Ява карлар, ашыккандай җирнең
Караларын акка күмәргә.
Шагыйрьлек тә ярый —
моның өчен
Җырлы иткән җылы көннәргә
Үзең белән кирәк түләргә.

Ага вакыт җиргә ак кар булып,
Бәгырьләрдә гүли бу вакыт,
Күзләренә кара,
Көчең җитсә,
Шул вакытны юлда туктатып.

Их син, сәях дустым, нәни гигант!
Карлар төшми, карлар тик тора! —
Тибрәнгәләп күккә күтәрелә
Безнең шушы иске йорт кына.

Моңсу бүген… Иске планетаның
Үзеннән дә иске шул Вакыт —
Көче җитте! —
Сорау ала бездән,
Күзгә карап, юлда туктатып…

Сез, әлбәттә, авыш хәрефләр белән аерымланган урыннарга игътибар иткәнсездер. 1973 елда язылган шигырьнең шушы варианты **«Ике урман арасы»** җыентыгыннан алынды (ТКН, 1995). Әмма элгәре китапларда (мәсәлән, **«Утлы бозлар»**да, ТКН, 1978) бу строфалар үзгә төрле яңгырый:

Бүген моңсу…
Иске зур каланың
Үзеннән дә иске йортында
Авыр уйлар килеп *якорь сала*,
Яңа уйлар
йөрәк портына.

Яңа уйлар йөрәк портына килеп *«тукталып»* кына калмый, ә *«якорь сала»*! Күз алдына китердегезме? Образ ничә мәртәбә көчәйде (дөресрәге, төзәткәнче көчле булган) ләбаса! Ләкин автор, туксанынчы еллардагы пуризм омтылышына бирелеп, күрәсең, чит телдән кергән «якорь» сүзе белән бергә, әлеге гүзәл образдан

*Мондый вариант та бар: «Күкрәкләрдә…»

да баш тарткан, нәтиҗәдә, алты юллык шактый ярлыланып калган.

Сигезенче строфаның әлгәре вариантына игътибар итик:

Ага вакыт җиргә ак кар булып,
Нервыларда гүли бу вакыт,
Күзләренә кара,
Көчең җитсә,
Шул вакытны юлда туктатып.

Тагын шул ук хәлгә юлыгабыз. Чит сүз биредә янә алыштырылган, анысы хуп, әмма нәтиҗәдә «вакытның» конкрет «нервыларда» (ягъни, кеше организмындагы сиземләү җепселләрендә, бәйләмендә) «гүләве» абстракт «бәгырьләргә» күчкән. Күңелнең киеренке кылларында уйнаган (гүләгән!) Заман җиле сурәте юкка чыккан. Образ тоныкланган. Строфа янә ярлыланган.

Әйткәнемчә, бу үзгәрешләрнең нигезендә тел сафлыгын кайгырту ята булса кирәк. Шагыйрь алынмаларны үз сүзебезгә алыштыру бәрабәренә матур шигъри табышлардан баш тарткан. Билгеле, аның бу гамәле тиктомалдан тумаган, киресенчә, озаклап уйлап, үлчәүнең кай ягы басканын җентекләп күзәтеп ясалган төпле нәтиҗә ул. Строфалап тикшергәндә күпмедер югалту ачысы чамаланса да, шигырьне тулаем бер картина итеп караганда бу хилафлык сизелми. Асылташ барыбер асылташ булып кала.

Икенче шигырь, гомумән, сүз кадере, сүз кыйммәте һәм сүз куәте мәсьәләсендә искитмәле үрнәк саналырлык. (Каләмдәше-иҗатташының чираттагы (илле яшьлекме икән?) юбилеенда Мөдәррис Әгъләм аны «Зөлфәт дустым...» дип башлый һәм «Киләчәккә, Зөлфәт, ышанам!» дип тәмамлый (видеоязмасы бар). Шуннан чыгып, әсәрне Зөлфәткә бәйле, дип гөманлаган идем дә. Хаталансам, бигайбә!)

Чү, тукта, мизгел! Шигырь укыйбыз...

ТАТАРСТАНЫМ

Шагыйрь дустым сәяхәттән кайткач
Әйткән иде, Татарстаным,
Картадагы синең сурәтеңнең
Чабып барган атка охшавын.

Ничек кенә әле чабасың син,
Томырылып,
 Татарстаным,
Ялларыңнан чытырдатып тотып
Синең белән мин дә очамын.

Синең белән ул — без мәртәбәле,
Синең белән ул — без канатлы.
Бабаларым, атларыннан егылып,
Ничә тапкыр борын канатты...

Затлы аргамаклар кайсы чорда,
Кайда гына илтеп сукмады?!
Ил бәясе башлар ярылдылар,
Шөкер әле күзләр чыкмады.

Ярый әле шундый заманнарда
Югалмаган күрү сәләте.
Егылганда авырткан җир була,
Авырткан җир була, гадәти.

Авырткан җирем син — Татарстан,
Без чабабыз менә әлегә...
Әмма беләм, кайда бәрелсәң дә,
Авырткан җир алдан бәреләә.

Авырткан җирем син — Татарстан,
Син йөрәктер миңа, бәгырьдер...
Кайда гына килеп бәрелсәм дә,
Иң беренче сиңа бәрелер.

Башка халыклар күк безне дә бит
Азатлыкка сусау уяткан.
Без чабабыз,
Еллар очкын булып
Очып кала безнең тояктан.

Без чабабыз
 еллар,
 чорлар аша,
Яңгыратып бөтен тарафны;
Иле белән кеше мәртәбәле,
Иле белән кеше канатлы.

Бер канатың була туган телең,
Бер канатың була туган җир;
Кошка гына түгел, кешегә дә
Канат кирәк була торгандыр.

Син чыннан да, илем,
әкияттәге
Чабып барган атка охшаган.
Шушы ике канат бар чагыңда,
Киләчәккә, илем, ышанам.



Мөдәррис Әгъләм

Шигырь **«Иман тәрәз шакый»** (ТКН, 1996) китабыннан алынды. Инде сорау: ул кайчан язылган һәм биредә кайсы чор кәефе чамалана? «Әлбәттә, милли күтәрелеш еллары!» — дип җавап бирерсез. Һәрхәлдә, үзем әүвәл шулай уйлаган идем. Туры килә ич инде: күтәренке күңел, өмет ялкыны, тантана, «синең белән ул — без мәртәбәле, синең белән ул — без канатлы», «бабаларым, атларыннан егылып, ничә тапкыр борын канатты», «бер канатың була туган телең, бер канатың була туган җир», һәм башкалар. Әмма шигырь... игътибар... 1972 елда ук язылган! Шагыйрь торгынлык чорында туксанынчы еллар рухындагы әсәр иҗат иткән! Ничек?! Гаҗәпме? Гаҗәп. Бер кечкенә детальне исәпкә алмасаң...

Элгәре вариантларда (мәсәлән, **«Исәнме, йөрәк!»** җыентыгы, ТКН, 1978) сигезенче строфа менә болай яңгырый:

Башка халыклар күк безне дә бит
Революция (!) уяткан.
Без чабабыз,
Еллар очкын булып
Очып кала безнең тояктан.

Шушы бер сүз бөтен гомуми картинаны җимереп төшерә, вакыйгаларны җитмеш ел артка, XX гасыр башына чигереп ташлый!

Бер сүз аркасында шигырьдәге һәр юл, һәр җөмлә, һәр строфа үзгә мәгънә ала, әсәрнең эчтәлеге төбетамырыннан үзгәрә!

Авторның рухи искерә төшкән шигырен шулкадәр иҗади якын килеп, оста рәвешле яңартып җибәрә алуына сокланырга гына кала...

Әдипләребезнең байтагы иҗат юлын коммунистлар чорында башлап, «демократия» көннәрендә дәвам итәргә мәхкүм булды. Билгеле, әдәбиятта ат уйнаткан яшь чакларында аларның һәрберсе үзе яшәгән заманны, аның уңышларын, идеалларын, хыялларын, өметләрен кәгазьгә төшергән. Бер «гүзәл» мизгелдә илеление белән бергә барысы да челпәрәмә килеп төшкәч, телисеңме-теләмисеңме, иҗатыңа да яңача карарга, элгәре язганнарыңа төзәтмә кертергә туры килгән, күрәсең.

Ләкин эш анда түгел. Эш кемнең бу эшкә тотынуында һәм кемнең бу эшне ничек башкарып чыгуында гына... ■

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

Сәхифәне филология фәннәре докторы, профессор ЗӨФӘР РӘМИЕВ алып бара.



АКЫШ ГАЛИ (Галиулла Агиш; 1918-2011), 1939 елдан соң башлыча Төркиядә яшәгән журналист, 1997 елга кадәр Бөтендөнья татар лигасының президенты. Г.Акышның Тукай иҗатын чит илләрдә, аеруча кардәш төрек халкына танытуда беренче адымы 1938 елда ясала. Каһирәдә Тукай көнен бәйрәм итү турында зур булмаган мәгълүмати мәкалә язып, аны «Яшь истыйляхчы» имзасы белән «Яңа милли юл» журналында (№6) бастыра ул. Бу бәйрәм чарасында (мәрасимдә) үзе дә катнашып, Тукайның тәрҗемәи хәле турында чыгыш ясый (мәҗлес «Сөембикә маршы»н уйнап тәмамлана). С.Арсланбәк, Н.Бинарк белән берлектә 1965 елда Анкарада «Тукай бәйрәме» брошюрасын чыгаруда, Төркиядә Тукайның үлеме уңаеннан уздырылган искә алу кичәләрен оештыруда актив катнаша. Г.Акышның «Идел-Урал төрек-татарларының бөек шагыйре Габдулла Тукай үлеменә 70 ел», «Идел-Урал төрек-татарларының бөек шагыйре Габдулла Тукайга 100 яшь» мәкаләләре, «Төрек йорды», «Әмәл», «Ени форум», «Вакыт» кебек төрек газета-журналларында дөнья күрә. Ул әдипне татар-төрек дөньясының милләт, халык өчен янып иҗат иткән уртак шагыйре, урысларның Пушкины, инглизләрнең Шекспиры, төрекләрнең Нәмикъ Кәмалы дәрәҗәсендәге «бөек шагыйрь һәм философ» дип атый. Тукай иҗатының аеруча мөһим өч үзенчәлегенә игътибар итә: 1) халыкчылыгы — «тулы бәхетне халыкка хезмәт итүдә күрүе»; 2) миллиятчелеге — «XX йөз башында милли мәдәният Ренессансын тудыруы»; 3) иманлы мөселманлыгы, динилеге — «Коръән белән пакьләнүе». «Миллиятчелектә шовинизмнан ерак торды, мөселманлыкта фанатизм юлына басмады, халыкчылыкта радикализм юлына төшмәде», — дип, Тукайның фәлсәфи һәм әдәби фикер сөрешендә объектив юлны билгели. Галим совет идеологиясе шартларында

Әсәр:
Акыш Али. Зур төрек әдибе Тукай (интервью) / Вакыт. Истанбул. 1943. 8 март; аныкылар. Бөек татар-төрек шагыйре Габдулла Тукайның халыкчылык һәм милләтчелек яклары / Азәрбайҗан. Анкара. 1965. №10-12. — Б.15-16; Идел-Урал төрекләренең зур шагыйре Габдулла Тукай 100 яшендә / Әмәл.

әдипне атеист итеп күрсәтүчеләргә бик ачына, аларга җавап итеп: «Тукайның күп шигырьләре Изге Коръәннән, Бар һәм Бер Аллаһтан илһам алып әдәбият мәйданына килгән», — дип яза. Г.Акышның 2001 елда Алманиядән ТР Милли архивына кайтарылган шәхси архивында шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗатына кагылышлы мәкаләләр дә бар. 1986 елда Нью-Йорк татар җәмгыяте тарафыннан татар әдәбияты һәм мәдәниятенә багышланып чыгарылган «Өмид юлымыз» исемле бюллетеньнең бер санында, тууына 100 ел тулу уңаеннан, бөек каләм иясенең портреты, тормыш юлы (инглиз һәм төрек телләрендә), Минһаҗның «Даһи Тукайны искә алу» шигыре, АКШның Детройт шәһәрендә узган Тукай кичәсе турында тәфсилле, күләмле язма да урын ала. Г.Акыш «әдәби һәм фикри төшенчәсе белән халкының рухына якын булган татар шагыйре кыямәт көненә кадәр халкы белән бергә яшәячәк» дип, иҗатының үлемсез булуын искәртә.

Алия Мөбарәкшина ■

Анкара. 1986. №153. — Б.17-18; Идел төрек-татарларының бөек шагыйре Габдулла Тукай 75 ел элек вафат булды / Төрек йорды. Анкара. — 1988. №18. — Б.38.

Әдәб.:
Гали Акыш Тукай турында… // Ватаным Татарстан. — 2006. — 28 апрель; Гилязов И. Новые поступления. Али Акыш и его личный архив // Эхо веков. — 2002. №3-4; Дәүләт Н. Казан төрекләре һәм Габдулла Тукай // Казан. 1971. — Март; Миңнегулов Х. Чит илләрдәге татар әдәбияты һәм матбугаты // Дөньяда сүземез бар… К., 1999. — Б.194-209; Миңнегулов Х. Еракта да якын Тукай // Гасырлар арасында уйланулар. К., 2010. — Б.80-88.

1986 елда Нью-Йоркта татар җәмгыяте чыгарган «Өмет юлымыз» бюллетене. Г.Тукай, Р.Фәхреддин, Г.Кариев, К.Насыйри, Ф.Әмирханга багышланган. ТР Милли архивындагы Гали Акыш фондыннан алынды.

КҮҢЕЛ ТАШКЫНЫ

Аида Алмазова

(Татар профессиональ музыкасы тарихына кыскача күзәтү)

XX гасыр татар милли профессиональ музыкасы үсешендә өч чорны аерып чыгарырга мөмкин. Беренче чор (20-30 еллар башында) профессиональ музыкага нигез салучы С.Габәши һәм С.Сәйдәшев исемнәре белән бәйле. Алар милли музыка драмалары, көнкүреш көйләрен һәм татар совет җырларын тудырулары белән танылган. Икенче чор (40-50 еллар) татар музыкасы опера, балет һәм симфоник оркестр өчен язылган әсәрләр белән игътибарга лаек.

Солтан Габәши

Нәҗип Җиһанов

Бу чорның күренекле композиторлары — Н.Җиһанов, М.Мозаффаров, А.Ключарёв, Җ.Фәйзи. Өченче чорда (60-90 еллар) симфония һәм камера-инструменталь музыка жанры үсеш ала. Чор Н.Җиһановтан кала Р.Яхин, А.Монасыйпов, Ф.Әхмәтов, Р.Билалов, Р.Еникеев, Ш.Шәрифуллин һәм башка күп кенә композиторлар иҗаты белән бәйле.

20-30 еллар башында танылган халык музыканты һәм композитор С.Габәшинең эшчәнлеге киң колач ала. Ул татарлар өчен музыка грамотасы курсын яза һәм татар хорын җитәкли. 1925 елда ике композитор — В.И.Виноградов һәм Г.Әлмөхәммәтов белән берлектә «Сания», ә 1930 елда «Эшче» операсын яза.

«Сәйяр» труппасы нигезендә оешкан Татар дәүләт драма театрының 20-30 елларда чәчәк аткан чоры. С.Сәйдәшевнең иҗаты да әлеге театр белән бәйле. 1922 елда ул эшчәнлеген музыка бүлеге мөдире һәм театр оркестрының дирижеры буларак башлый. С.Сәйдәшевнең беренче музыкаль драмалары — «Башмагым» (1922), «Сүнгән йолдызлар» (1922), «Казан сөлгесе» (1923), «Галиябану» (1926) халык җырларын эшкәртеп, аларны спектакльләрдә файдаланудан тора. Бары 1926 елда К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл», аннан соң Т.Гыйззәтнең «Наёмщик» (1928) һәм К.Тинчуринның

Салих Сәйдәшев

Рөстәм Яхин

Александр Ключарёв

Мәсгудә Шәмсетдинова

Алмаз Монасыйпов

«Кандыр буенда» (1932) драмаларыннан милли музыканың яңа формасы — арияләр, дуэтлар, увертюра, балет сюитасын спектакльдә яңача, урынлы куллану кереп китә. Кайбер пьесаларда алар шулкадәрле күп, хәтта пьесаларны сөйләм белән аралашып барган опера, дияргә дә мөмкин.

30-50 елларның икенче яртысында татар музыкасы яңа баскычка күтәрелә. 1934 елда Мәскәү консерваториясе каршында татар опера студиясе ачыла. С.Садыйкова, Г.Кайбицкая,

М.Рахманкулова, А.Измайлова кебек танылган җырчылар белән беррәттән вокаль осталыгы дәрәҗәсе алардан ким булмаган яшьләр — М.Булатова, У.Әлмиев, Ф.Насретдинов, Х.Зәбировалар Мәскәүдә стажировка үтәләр. 1935 елда студия каршында әдәби секция оеша. Романслар һәм рус, чит ил классик операларының текстларын татар теленә тәрҗемә итү, шулай ук үзенчәлекле опера либреттолары булдыру бурычы куела. М.Максуд «Кара йөзләр», Ә.Камал «Туй», М.Җәлил «Алтынчәч», Ә.Фәйзи «Качкын» операсына һәм «Шүрәле» балетына либреттолар язалар. Опера һәм балет иҗат итәргә студия тыңлаучылары С.Сәйдәшев, З.Хәбибуллин, Ф.Яруллин, Җ.Фәйзи һәм консерваториянең үзендә укучы М.Мозаффаров белән Н.Җиһанов тартыла. Музыка белемен өйрәнүгә шушы кадәр игътибар үзенең уңышлы нәтиҗәләрен дә бирә. 1937 елда алданрак җыр һәм бию ансамбле барлыкка килә (соңрак филармониягә кушыла), 1938 елда милли опера театры ачылу мөмкинлеге туа. Шул ук 1938 елда татар филармониясе, 1939 елда Татарстан композиторлар берлеге оеша.

30-50 еллар ахырында татар музыкасында бер үк вакытта классик һәм романтик юнәлеш барлыкка килә. Беренчесе — көрәш һәм хезмәт героикасын данлау белән бәйләп, дөньяны күтәренке рухта тасвирлау. Икенчесе хәзерге заманның тынгысыз чынбарлыгыннан канәгатьсезлекне һәм шәхес кичерешләрен яктыртуга юнәлдерелгән. Беренче юнәлеш вәкилләре булып Н.Җиһанов, А.С.Ключарёв, М.Мозаффаров, Җ.Фәйзи санала. Икенче юнәлеш Ф.Яруллин һәм Р.Яхин иҗатында чагылыш таба.

Татар опера һәм балет театры 1938 елда Н.Җиһановның «Качкын» операсы белән ачыла. Шуның артыннан «Ирек» (1939), «Алтынчәч» (1941), «Түләк һәм Сусылу» (1944), «Илдар» (1944) һәм «Намус» (1951) опералары языла. Шагыйрь дустына багышланган соңгы операсы — «Муса Җәлил» (1954). Н.Җиһанов музыкаль-драматик әсәрләрнең тематикасын бик киңәйтә. Революцион тема белән беррәттән XIII гасыр Болгар дәүләте белән бәйле тарихи вакыйгаларны кертә. Халыкның эпик риваятьләреннән үсеш алган легенда-әкият тематикасы аның әсәрләрендә гәүдәләнеш таба.

Н.Җиһанов тормышының икенче өлеше (1968-1988) симфонияләр иҗат итү белән бәйле. Ул барлыгы 16 симфония язган. Аларда тарих та, заман да киң яктыртылган.

30 елларда Н.Җиһанов белән бер үк вакытта, Мәскәү консерваториясен яки аның каршындагы татар опера студиясен тәмамлаучы яшь композиторларның яңа буыны барлыкка килә. Алар — А.Ключарёв һәм М.Мозаффаров, Җ.Фәйзи һәм З.Хәбибуллин. Татар музыкасы тарихына аларның һәркайсы үз өлешен кертте.

Пианист, аккомпаниатор, фольклорчы һәм композитор Александр Сергеевич Ключарёвның (1906-1972) 30-60 еллар музыка культурасы үсешендә роле бик зур. Бик озак еллар ул Татарстан җыр һәм бию ансамбле белән тыгыз иҗади бәйләнештә булып, халык иҗаты кабинетының мөдире булды, симфоник-оркестр һәм камера-инструменталь музыка өлкәсендә беренче әсәрләрен иҗат итте.

А.С.Ключарёв иң беренче чиратта татар фольклорына әйтеп бетергесез өлеш кертте. Бу өлкәдәге эшчәнлегенең нәтиҗәсе буларак, беренче мәртәбә җентекле эшкәртелеп, 1941 һәм 1955 елларда татар халык җырларының күләмле җыентыгын чыгарды.

Татар милли материалына нигезләнгән симфоник әсәрләрдән, беренче чиратта «Галиябану» (бигрәк тә концертларда өзекләре еш яңгыраган «Авыл көе» һәм «Алтын-Көмеш») симфоник сюитасын, «Су буйлап», «Идел буе халыклары темасына сюита» һәм «Идел симфониясе»н (1955ел) санап китәргә була.

А.Ключарёв белән янәшә үз вакы-

ты өчен танылган тагы бер композитор Җ.Фәйзи иҗат итә. 60 нчы елларда СССР ФА Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтындагы фольклор бүлегендә хезмәткәр булып эшләгәндә Җ.Фәйзи «Халык җәүһәрләре» дип аталган халык җырларыннан төзелгән җыентыкның авторы булды. А.С.Ключарёвтан аермалы буларак, Җ.Фәйзи фольклорның соңгырак катламнарына: тиз, катнаш такмакларга, әйлән-бәйләнгә игътибар итә. Композитор үз иҗатында шул ук катламнарны эшкәртүләрдә, җырларда, музыкаль комедияләрдә куллана.

Җ.Фәйзинең җыр-романсларында мәхәббәт шатлыклы яки моңсу, дулкынландыргыч хисләр белән табигый итеп бирелә. Композиторга көчле эмоцияләр күрсәтү хас түгел, аның әсәрләре гади һәм садә, элегия яки серенада, романс яки лирик җыр рәвешендә яңгырый. Аеруча Һ.Такташ шигыренә язылган «Урман кызы» җыры һәм М.Әмирнең «Тормыш җыры» спектаклендәге шул ук исемдәге җыр белән ул профессиональ музыкага килеп керде. Җ.Фәйзи лирикасы С.Сәйдәшев лирикасыннан нәфисрәк һәм романтик күтәренке. «Башмагым» музыкаль комедиясе композитор иҗатында югары баскыч булды. Әсәр Х.Ибраһимовның шул ук исемдәге классик комедиясе буенча язылган (Т.Гыйззәт либреттосы).

30-40 еллар татар музыкасы тарихында Фәрит Яруллин (1914-1943) үзенә аерым бер урын алып тора. Ул кыска гына гомере эчендә 20ләп җыр, 3 романс, берничә инструменталь-камера әсәре, виолончель өчен соната һәм симфония иҗат итәргә өлгерә. Беренче татар балеты «Шүрәле» — аның опера студиясен тәмамлаганда иҗат иткән диплом эше. Композитор балетның клавирын төгәлләргә өлгерә. Сугыш башлана, Ф.Яруллин фронтка китә. Ә 1943 елда үзенең балетын сәхнәдә күрә дә алмыйча, 29 яшендә һәлак була. Аның инструментовкасын Мәскәү композиторлары В.Власов һәм В.Фере төгәлләлли. Ә.Фәйзи һәм Л.Якобсон либреттосы һәм танылган балетмейстер Л.Якобсон хореографиясендә балет Казанда гына түгел, Петербургта (1950 ел), Мәскәү (1955 ел), шулай ук Германия, Польша, Болгария, Румыния һ.б. күп кенә илләр театрларында куела. «Шүрәле» — татар композиторлары музыкасы югары дәрәҗәгә ирешүенең күрсәткече. Авторы, үлгәннән соң, 1958 елда Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясенә лаек булды.

50-80 нче елларда Рөстәм Яхин (1921-1994) милли музыкада романтик юнәлешне үстерде. Мәскәү консерваториясен ике белгечлек — фортепиано һәм композиция буенча тәмамлаган Р.Яхин 300ләп романс һәм 100гә якын инструменталь миниатюра иҗат итә. Аның инструменталь миниатюралары сокландыра, романтик дулкынландыра торган. Аларның күбесе тойгылы лирик мәхәббәт һәм сагыш турындагы поэмалар. Ул «Поэтик күренеш», «Музыкаль мизгел», «Вальс-экспромт», «Сүзсез җыр», «Ноктюрн», «Скерцо» кебек татар камера-инструменталь музыкасының күп кенә яңа жанрларын булдыручы.

Татар музыка мәдәнияте тарихында 30-60 нчы елларда халык арасында яратып кабул ителгән композитор Мансур Мозаффаров 20-30 нчы еллар башында, нигездә, эшкәртүләр һәм җыр язу белән шөгыльләнә. 1964 елда «Татар халык җырлары»ның җыентыгын чыгара. Соңырак композитор иҗатында өстенлек иткән катлаулы, күләмле опера һәм симфоник оркестр поэмасы жанрлары барлыкка килә. Ул ике опера — М.Фәйзинең классик драмасы сюжетына «Галиябану» (1939) һәм Ә.Фәйзи либреттосына «Зөлхәбирә»не (1943) яза. М.Мозаффаров тарафыннан язылган беренче симфоник поэма «Тукай истәлегенә» (1952) дип атала. Ә икенчесе — «Мулланур Вахитов истәлегенә» (1957).

Казанда 1945 елда консерватория ачылу милли композиторлар әзерләүгә зур этәргеч бирә. 60 нчы елларда ком-

позиция кафедрасы мөдире, танылган музыкант, теория белгече һәм композитор Альберт Леман җитәкчелегендә яңа идеяләрне өйрәнү белән бергә заманча ысул-чаралар белән коралланып иҗат итәргә омтылган бер буын шәхесләр үсеп чыга. Ә.Бакиров, Х.Вәлиуллин, Ф.Әхмәтов, Б.Мөлеков, А.Монасыйпов, Р.Еникеев, М.Яруллин, Р.Билалов кебек яңа исемнәр танылa башлый. Аларның ижатлары С.Прокофьев, Д.Шостакович, И.Стравинский, Г.Малер, А.Шенберг, Б.Барток һ.б. тәэсирләре йогынтысында алга бара.

Ә инде 1967 елда атаклы дирижёр Натан Рахлин җитәкчелегендә симфоник оркестр оешу татар композиторларына симфония өлкәсендәге талантларын күрсәтергә яңа мөмкинлек тудыра. Шул вакытта Н.Җиһанов, А.Монасыйпов, Ф.Әхмәтов һ.б. бик күпләрнең беренче симфонияләре дөнья күрә. Шактый санда камера-инструменталь музыканы башкаручылар да җитлегеп өлгерәләр. Бу чорда иҗат ителгән әсәрләргә нигездә чынбарлыкны фәлсәфи күзлектән тасвирлау һәм замандашлар образына мөрәҗәгать итү хас булып тора.

80-90 нчы елларда совет чынбарлыгын ал да гөл дип язулар инде ышандырмый башлады. Әгәр 40-50 нче елларда милли тарих алга бара, үсешкә омтыла дигән булсалар, хәзер инде милли фаҗига очкыннары өстенлек ала. Беренчелердән булып тарихны музыкаль иҗатта сурәтләүгә «Казан» симфониясе белән Фасил Әхмәтов алына. Симфониянең финалы коточкыч фаҗигане, дәһшәтле афәтләрне сурәтли. А.Монасыйповның «Дастан»ында, Р.Кәлимуллинның «Болгар» симфоник поэмасында, М.Шәмсетдинованың «Болгар турындагы дастан»ында да шушы идеяләр чагылыш таба.

40-50 нче елларда опера белән балет жанрлары алгы планда торса, 70-90 нчы елларда симфония белән камера-инструменталь музыка жанрлары яңгырарга тотына. Композиторларның стиль юнәлешләре күптөрле. Элек стиль юнәлешләре дистә еллардан соң алышынса, хәзер бер үк вакытта берничә стиль янәшә яшәргә мөмкин, ул гына да түгел, бер үк композитор берничә стильне бер үк вакытта кулланырга мөмкин. Композиторлар фольклор жанрларыннан озын көй белән кыска көйгә күбрәк мөрәҗәгать иткән булсалар, хәзер йола көйләре һәм мөнәҗәтләр моңы ишетелә.

Алмаз Монасыйповны (1925-2009) татар милли музыкаль эстрадасын башлап җибәрүче дип атарга хакыбыз бар. Аның юнәлешен Р.Билалов, Р.Еникеев, Р.Кәлимуллин, Р.Әхиярова, Р.Абдуллин, Л.Батыр-Болгарилар үзләренең җырлары белән дәвам итәләр.

Ренат Еникеевның (1937) иҗаты аеруча әһәмияткә ия. Фортепиано өчен сонаталары һәм Партитасе, Крылов мәсәлләренә сюитасы, виолончель өчен «Ариетта»сыннан аны неоклассицизм вәкиле дип атарга мөмкин.

Неофольклоризм исә фольклорның борынгы катламнарына игътибар итә һәм XX гасыр музыкасын заманча яңа чаралары белән баета. Бу юнәлешкә нигезне А.Монасыйпов һәм Ш.Шәрифуллин сала, ә алга таба композиторлар Р.Кәлимуллин һәм М.Шәмсетдиновалар дәвам итәләр. Борынгы тарихка мөрәҗәгатьне, рухи чыганаклар турында уйлануларны Р.Кәлимуллинның «Болгар» симфоник поэмасы, икенче сонатасы, ике флейта өчен «Бездән соң да бәхет кирәк» поэмасы һәм «Кәккүк тавышы» рок-операсы кебек неофольклор әсәрләре чагылдыра.

Хәзерге заман композиторларының эзләнүләре менә шундый яңа үзенчәлекләргә ия. Композиторлар ничек кенә булмасын бу катлаулы, тынгысыз дөньяда таяну ноктасы табарга омтылалар. Берәүләр башлангыч чорга, икенчеләре үткәндәге классик сәнгатькә мөрәҗәгать итә, өченчеләре исә халык мәдәнияте белән гармониядә иҗат итә. Боларның барсын да хәзерге көн татар композиторларының гади булмаган иҗади эзләнүләре күрсәтеп тора. ■

КАЛФАК

(ТР Милли музее фондларыннан)

Татар хатын-кызлары баш киемнәренә зур игътибар биргән. Яраткан баш киеме булып калфак саналган. Калфакның бик күп төрләре билгеле. XIX йөзнең урталарына кадәр зур, чуклары аркага төшеп торган калфак кигәннәр. Аны тамбур белән чәчәкләп чиккәннәр, тукыма чәчәкләрдән аппликацияләр ясап теккәннәр. XIX йөз ахыры-XX гасыр башында бәрхет калфаклар киң тарала. Мондый калфаклар чәчкә кадалып, түгәрәкләп ясалган. Соңрак калфакның формалары тагын да кечерәеп, декоратив чәч каптырмасы булып кына кулланыла башлый. Кечкенә калфаклар алтын җеп, энҗе, сәйлән белән бизәлеп, һәр хатын-кызның гардеробында үз урынын яулаган.

***Руфия Мөхетдинова** әзерләде.*

«БУА ЭШЕ»

Әмир Камалов, Ислам Әхмәтҗанов

Хәтер төпкелләреннән, тарих катламнарыннан, суд архивларыннан сафларыбызга бик таныш һәм таныш булмаган исемнәрнең – хаксызга рәнҗетелгәннәрнең исемнәре әйләнеп кайтуына шаһитбыз. Үлгәннәргә берни кирәкми, диләр. Килешмибез, дөрес әйтмиләр. Рәнҗетелгәннәрнең үзләренә, якыннарына, безгә, бездән соң киләчәк яшь алмашка аларның тапсыз исемнәре кирәк. Хакыйкатьнең юлы кайчак озын, бик озын була, әмма ул барыбер табылмыйча калмый – мәңгелек яшәеш шуны раслый.

« — Менжинский клубында хәрби трибунал. Өченче көнне «Буа эше»н караганнар.

— Әйе-әйе, ишеткән идем. Нәрсәдә гаеплиләр, кемнәрне?

— Кемнәрне булсын, Буа районының барлык җитәкчеләрен. Райком секретарьларын, Башкарма комитет председателен һәм башкаларны. Барысы уналты кеше. Имеш, корткычлык оештырганнар. Кичә хөкем карары укылган.

— Аклаганнармы?

— Аклаганнар: унбишен атарга, бары редактор Яушевка гына унбиш ел төрмә.

— Булмас! — Алкин кычкырып җибәрде. — Булмас!»

Әлеге өзекне Ибраһим Салаховның «Колыма хикәяләре» исемле роман-хроникасыннан китердек.

Күпләрнең: «Ленинград эше» бар, «Хәрбиләр заговоры», «Врачлар эше» бар, ә менә «Буа эше» хакында тәүге ишетүебез, дип җилкә уйнатулары ихтимал. Каһәрләнгән утыз җиденең күзендә бөтен республиканы шаулаткан вакыйганы белмәвебез һич тә гаҗәп түгел. Үткән юлыбызның караңгы бормаларын барларга, кайбер гаепсез рәнҗетелгән исемнәрне катлы-катлы ялган тузаннарыннан арындырырга ике дистә ел элегрәк кенә тотындык бит. Бөтенесе дә тарих дәреслегендәгечә шома гына булсачы, юк шул, хәвеф тулы битләрне, нигәдер, читләтеп узарга күнеккән идек.

Утыз җиденең башыннан дулкын арты дулкын төсендә республиканың төрле төбәкләрендә мәхкәмәләр уза башлый. Ул еллардагы архив кәгазьләрен, гәзит тегелмәләрен актарганда Кукмара МТСындагы, Заготзерноның Красновидово белән Тәтеш бүлекчәләрендәге, Балтач районының «Яңа көч» колхозындагы, Чистай районара бактериология берләшмәсендәге «контрреволюцион корткычларны» хөкем иткән шау-шулы (республика матбугатында судлардан урнаштырылган тәфсилле язмалар, гаепләнүчеләрне хурлап уз-

Д.Нәүрүзова коллажы

дырылган митинг-җыелышлар моңа ишарә) процессларга юлыгасың. *«Авыл хуҗалыгында корткычлык эше партия аппаратына үтеп кергән контрреволюцион милләтчеләр — фашизм агентлары тарафыннан җитәкләнә»*, — диелә 1937 елның 11 июнендә булган Татарстан өлкә партконференциясендә ясалган хисап докладында. Татнаркомземда эшләүчеләр, Бондюгтагы химия заводына оялаган «япон-немец шпионнары һәм диверсантлары» өстендә болытлар куера башлый. Аннары чәнечкеле куллар Буаны капшарга тотына: ничек анда — бөтенесе дә тәртиптәме, абынучылар юкмы? Бар икән ләбаса, контралар да, белер-белмәс нотык сөйләүчеләр дә, корткычлык кылучылар да бар икән. «Буа эше» турында сөйләүне хөкем карарыннан башлыйк. «Кызыл Татарстан»ның 1937 ел 5 ноябрь санында басылган хәбәрдә мондый юллар бар: *«Буа районында контрреволюцион троцкийчы-бухаринчы банда эше буенча хөкем карары. 4 ноябрьдә берничә сәгатьләр киңәшмә ясаганнан соң, Татарстан АССР Верховный Судының махсус коллегиясе Буа районында контрреволюцион троцкийчы-бухаринчы банда эше буенча хөкем карары чыгарды. Татарстан АССР Верховный Судының махсус коллегиясе К.Г.Гафуровны, И.С.Гаринны, Г.В.Вәлиевны, Ә.С.Галимовны, М.Х.Җәмиловны, А.Б.Дружининны, М.Н.Поповны, Ә.З.Харисовны, А.С.Сәгыйдуллинны, Ф.И.Качалинны, С.А.Ширяевны, З.Җ.Шәрәфетдиновны иң югары җәзага — атарга, Я.Ш.Яушевны 15 елга төрмәгә ябарга һәм соңыннан 5 елга хокукыннан мәхрүм итәргә хөкем итте.*

Хөкем карары катгый, жалоба бирергә мөмкин түгел».

Буа вакыйгасын ишетеп белүчеләрдә нинди дә аңлашылмаучылык калмасын өчен бернәрсәне ачыклап узыйк: мәхкәмәдә җәмгысе 21 кешенең эше каралып, Югары Судның махсус коллегиясе гаепләләр эскәмиясендәге М.М.Фёдоров, А.Е.Миканов, Г.Вәлиуллин, А.И.Игнатьев, А.М.Батманов, В.А.Журавлёв эшен аерып каруны сорый. Ибраһим Салаховның алдарак китерелгән өзектәге санны да төзәтеп укырга кирәктер.

Гаепләү актының һәр җөмләсендә диярлек, «банда», «халык дошманнары», «корткычлар», «буржуаз милләтчеләр», «сатлыкҗаннар» кебек күңел өшеткеч сүзләргә тап буласың. Нахак гаептән бүген дә күңел сызлый. Нинди «корткычлык» кылган соң буалылар, гаепләре «иң югары җәзалык» микәнни?

Җәй башында ВКП(б) әгъзалыгына кандидат Сабира Сәйфетдинованың туракланган гәүдәсе коеда табылгач, районда төрле имеш-мимешләр йөри башлый. «Кыят» совхозыннан өлкә оешмаларына юлланган шикаятьләр кызган табага май тамызгандай була.

Кем соң ул Сабира? Вәхшиләрчә кыланырлык нәрсә эшләгән?

Тормыш арбасына яшьли җигелеп, нужа шулпасын шактый татыган бу тәвәккәл кыз 1932-1934 елларда милиционер булып эшли. Шулчакта малкуар сәүдәгәрләрнең, ат каракларының, күмәк хуҗалыкка төрлечә аяк чалырга маташучыларның «тез асларына» ныкк сугып, районда хөрмәт-абруй яулый. Берчакны Сабираны райкомга чакырып алып болай диләр: «Сәүдәгә икейөзле мут кешеләр елышты, шулардан арынырга кирәк!» Карусыз активистка баш-аягы белән эшкә чума: кооперация җитәкчелеген аумакайлыгы өчен кискен тәнкыйтьли, дәүләт кесәсе белән үз кесәсен бутаучыларны кояш яктысына сөйрәп чыгара, авыллардан кайтып керми. Яныйлар, күп тапкырлар яныйлар Сабирага: «Тыел, сүзебезгә колак салмасаң, сиңа да авызлык табылыр», — диләр, тутык тавыш белән аулак җирдә туры китереп. Әйтеп-әйтеп тә тыңлата алмагач, 1937 елның 5 мартында мәкерле ниятләрен чынга ашыралар. Әйткәнебезчә, Сабира Сәйфетдинованың гәүдәсен ту-

раклап, коега ташлыйлар. Баштарак берәү дә берни белми. Күпмедәндер шәһәрдә сәүдәгә оялаган койрык болгаучылар ярдәме белән мондыйрак хәбәр тарала: Сабира, янәсе, балага узган һәм шул хурлыктан халык күзенә күренергә ояла. 3 нче майда һич көтмәгәндә-уйламаганда юлыгалар аның гәүдәсенә. Берничә көннән партия райкомының «Милиция, прокуратура һәм НКВД органнарының ип. Сәйфетдинованы үтерүне тикшерү буенча эше турында»гы беренче карары чыга. Милиция органнарының, прокуратураның, НКВД район бүлегенең ВКП(б) членлыгына кандидатка кул күтәрүчеләрне эзләүдә бик акрын кыймылдаулары күрсәтелгән «райком карары, «бюрократик күз буяу» дип бәяләнеп, райком, райбашкарма җитәкчеләренә Сәйфетдинова өчен җавап бирергә туры киләчәк», шикелле сүзләр ишеттерә башлыйлар.

Районга бер-бер артлы төрле комиссияләр агыла. Аларның «эшкә» нинди күзлектән карап, ничек хисап бирүләрен күзаллау өчен Татарстан Республикасының Дәүләт үзәк архивыннан алынган шундый «документларның» берсе белән киңрәк танышу урынлы булыр. Русчадан тәрҗемә иткәндә шул чор теле, стиле сакланды.

Архив биргән белешмәгә караганда, документ партиянең өлкә комитеты тарафыннан әзерләнгән. Имзалар юк ителгән, текстның кайбер урыннары кисеп алынган.

«ВКП(б) өлкә комитетына доклад язмасы.ВКП(б) әгъзалыгына кандидат ип.Сәйфетдинованы үтерү эше буенча — Буа.

Буа эше буенча Хисамов, Лейбович һ.б. хәбәренә өстәмә рәвешендә, түбәндәгеләрне хәбәр итүне кирәк дип саныйм.

Без монда районның иң мөһим дәүләт, сәяси (астына сызылган) һәм уңайлык органнар (НКВД, прокуратура, милиция, МТС, «Кыят» совхозы, райпотребсоюз, заготзерно һ.б.) җитәкчелегенә үтеп кергән бандитлар, корткычларның оешкан шайкасы белән эш итәбез... Буа, элеккечә үк, сәүдә шәһәре булып тора, анда пролетар революциядән соң да берничә ел буена җитәкчелектә Бикташев һ.б. кебек фаш ителгән «халык дошманнары» торган, районның җитәкче органнарына аңлы рәвештә контрреволюцион эш алып бару өчен иң кулай материал буларак, чит, дошман, советка «каршы элементлар белән чүпләгәннәр».

Сагайтырга мәҗбүр итә бит әле бу: активистканы үтерәләр, ә җинаятьче табылмый, совхоздан, МТСтан, заготзернодан корткычлык эшләре турында сигналлар бар, райпотребсоюз кулакакгвардиячеләр белән «тулган», «Яңа юл» район гәзите халыкның матди һәм хокукый хәле турында контрреволюцион рухтагы хәбәрләр баса, димәк ки, район җитәкчелеге бухаринчы фашистик банда кулына эләккән, дип уйларга җирлек бар. Берничә айдан нәкъ шундый фикергә киләләр дә. Дәүләт гаепләүчесе, хәрби прокурор Бондырь «Буа эше» каралган судта менә нинди гаеп ташлый:

— Тикшерү раслаганча, гаепләнүчеләр, Буа район җитәкчелегенә үтеп кереп, озак вакыт дәвамында колхозларны, МТС, совхозны, кооперация һәм дәүләт сәүдәсен таркатуга, хезмәт ияләренең материаль хәлен начарайтуга юнәлдерелгән җирәнгеч эш алып бардылар, партия һәм совет власте политикасын төрлечә бозып күрсәтергә маташтылар. Дошманның бу кабахәт, фәкыйрь өере үзалдына Совет иленең куәтен какшату бурычын куеп, СССРда капитализмны торгызырга маташты. Котырынган «халык дошманнары» — троцкийчылар, бухаринчылар, буржуаз милләтчеләр, совет халкына көчле нәфрәт саклап, социалистик дәүләткә каршы көрәштә теләсә-нинди алым һәм хәйләдән дә тартынмыйлар. Буадагы контрреволюцион оешма процессы моны ачык күрсәтә. Бирелә «халык

дошманнары»ның, фашист разведкасы агентларының чиркангыч өере үзенең корткычлык эшен күрәләтә ашлык черетү, терлекләрнең күпләп үлүен оештыру, тракторларны һәм авыл хуҗалыгы машиналарын начар ремонтлау, район хезмәт ияләрен кирәкле товарлар белән тәэмин итүдә кыенлыклар тудыру юлы белән алып бара.

Дәлилләре кире каккысыз түгел, кагырга бик мөмкин, ә менә кемне ышандырырсың? Игътибар итик: гаепләү чыгышында бер процесстан икенчесенә күчеп йөреп, шомарып беткән игезәк сүзләр — банда, фашист агентлары, капитализмны торгызу. «Юләр сүзгә йөгән юк», дигәннәре шушы буладыр инде ул.

Утыз җиде-утыз сигезенче елларның фәлсәфәсе гади: «явыз банда» икән, аның тамырына балта чабарга кирәк. Озак уйлап торуның хаҗәте юк. Һәм балта уңга-сулга селтәнә башлый. Беренче булып аны НКВДның район бүлеге начальнигы А.П.Дружинин, милиция начальнигы Г.Вәлиуллин, прокурор М.Х.Җәмилов татый. Аларның 3 июльдә партиядән чыгарылып, озакламый кулга алынулары билгеле. Дружинин, бер яктан Сабира эшен тизләтмәве өчен гаепләнсә, икенче яктан, аңа «Кыят» совхозындагы, заготзерно, МТСтагы корткычлык турындагы сигналларны яшереп калуы, совхоз директоры Попов белән әшнәлектә торуы, «халык дошманнары»н фаш итүне тоткарлавы гаепкә куела.

Аннары башкаларга чират җитә.

Ул чакта ВКП(б)ның Буа райкомының беренче секретаре Кәбир Гафуровның хатыны Нәфисә Биктеева сөйләгәннәрдән (әңгәмә узган гасырның сиксәненче еллары уртасында язып алынган иде):

— Илле ел гомер узса да, утыз җиденең мәхшәр көннәрен соңгы сулышымача онытасым юк. Һич көтмәгәндә, тормыш караңгы бер көнгә әйләнде дә куйды. Кәбирне эшеннән алгач, әле партиядән чыгарманнар иде, өч баланы ияртеп, Казанга сеңелләрнең болай да кечкенә фатирына килеп төштек. Берничә көннән җайланыр, дип уйладык. Кәбирем иртәгәсен өлкә комитетына эш сорарга барган җиреннән хәрбиләр белән әйләнеп кайтмасынмы?! Йөрәгем жу итеп куйды — сизенде күңелем. Бик тынгысыз көннәр иде бит. Чишәргә дә өлгермәгән төенчекләрдәге китапларны берәмтекләп актардылар. Бәхеткә, Буада ук байтак фоторәсемнәр белән кайбер китапларны яндырып килгән идек. «Киен!» — дип боердылар аннары. Хәрбинең: «Ремененңне калдыр, башка кирәкмәс ул», — дип әйткәнен дә хәтерлим. Аерылышканда Кәбир миңа таба каерылып:

— Нәфисә, күрәсең, ниндидер аңлашылмаучылык килеп чыккан. Барыйм, төшендерим, бераздан әйләнеп кайтырмын. Тынычлыгыңны җуя күрмә, балаларны кара, — диде.

Кем белгән моның соңгы очрашу булуын! Кешегә күрсәтеп еларга да ярамый иде бит ул вакытта, бакчаның бер аулак почмагына сеңып: «Нинди хаксызлык соң бу, Ходаем!» — дип үксеп учыма еладым.

Сентябрьнең беренче атналарында «Буа эше» кузгатылып, районнан җитәкче урыннардагы 21 кешене «чүпләп», зинданга ябып куялар. Кемнәр алар, хаксызга рәнҗетелүчеләр? Бөтенесен үк түгел, алдарак телгә алынган хөкем карарындагы исемнәрне тагын бер кат, бу юлы ихтирам белән, күздән кичерик.

Кәбир Гафурович Гафуров. 1902 елда Татарстанның хәзерге Чүпрәле районында туган, ВКП(б) әгъзасы, партиянең Буа райкомының беренче секретаре.

Исмәгыйль Садретдинович Гарин. 1905 елда Саратов өлкәсендә туган, ВКП(б) әгъзасы, партиянең Буа райкомының икенче секретаре.

Гали Вәлиевич Вәлиев. 1896 елда Татарстанның Лаеш районында туган, ВКП(б) әгъзасы, Буа район Советы

башкарма комитеты председателе.

Әхәт Сәлимович Галимов. 1898 елда Татарстанның Кама Тамагы районында туган, ВКП(б) әгъзасы, Дәүләт банкының Буа бүлекчәсе управляющие.

Мөхәммәт Хөснетдинович Җәмилов. 1895 елда Татарстанда туган, ВКП(б) әгъзасы, район прокуроры.

Александр Прокофьевич Дружинин. 1897 елда Мари АССРда туган, ВКП(б) әгъзасы, НКВДның Буа район бүлеге начальнигы.

Борһан Садретдинович Садретдинов. 1898 елда Татарстанның Буа районында туган, ВКП(б) әгъзасы, Буа райпотребсоюзы председателе.

Сәләх Шәрипович Сәмерханов. 1898 елда Татарстанның Буа районында туган, ВКП(б) әгъзасы, Буа горпосы председателе.

Михаил Николаевич Попов. 1903 елда Украинада туган, ВКП(б) әгъзасы, «Кыят» совхозы директоры.

Әхмәт Зарипович Харисов. 1900 елда Татарстанның Баулы районында туган, ВКП(б) әгъзасы, Буа МТСы директоры.

Асыл Сәгыйдуллович Сәгыйдуллин. 1903 елда Татарстанның Буа районында туган, ВКП(б) әгъзасы, Буа МТСының өлкән агрономы.

Фёдор Иванович Качалин. 1902 елда Татарстанның Биектау районында туган, ВКП(б) әгъзасы, Буа МТСының өлкән механигы.

Сергей Алексеевич Ширяев. 1905 елда Алексеевский районында туган, партиясез, Буа җир бүлегенең өлкән агрономы.

Зыятдин Җәләлетдинович Шәрәфетдинов. 1903 елда Татарстанның Буа районында туган, ВКП(б) әгъзасы, Буа районы җир бүлеге мөдире.

Ясәви Шиһапович Яушев. 1895 елда Татарстанда туган, ВКП(б) әгъзасы, «Яңа юл» район газетасы редакторы.

...Революция эшен дәвам иттерүне тормыш кыйбласына, халык хакына фидакярлекне иманына әйләндергән Кәбир Гафуровны ничек итеп «халык дошманы», икейөзле агент рәвешендә күз алдына китерергә мөмкин?!

Акылга-аңга сыймаслык уйдырма лабаса бу! Әтисе Гафур, башка ир туганнары, шахтада эшләп, тормышларын берникадәр җайга салган кешеләр. Кәбир үзе дә татый бу хезмәтне. Донбассның Макеевка шахталарында үз-үзен аямыйча күмер чаба. Шуннан солдатка алына. Хәрби срогын тутыргач, Казанга кайтып, рабфакта укый башлый. Аны тәмамлагач, энергетика институтына керә. Укыган җиреннән яңа оешкан Сарман МТСына политбүлек начальнигы итеп җибәрәләр. Соңрак — Азнакай районында МТС директоры, аннары Буада — райком секретаре.

Кәбир Гафуров судка кадәр дә, судта да үзенә ташланган нахак гаепне танымый. Секретарь күңеленә ук булып кадалган: «Туры җавап бир: сатылдыңмы?» — дигән һәр сорауны:

— Беркайчан да үз халкымның дошманы булмадым. Гаеп ташлыйсыгыз килсә, башка сүзләр табыгыз, комнан бау ишеп маташмагыз! Ялган бу! — дип җаваплый.

Кем белә, каршы агачка — каты чөй дип, Кәбир Гафуровка бәлки бу сүзләре өчен әллә ниләр кичерергә туры килгәндер?

Агриппина Григорьевна Хмелёва сөйләгәннәрдән:

— Ул чакта партия райкомында техник секретарь идем. Суд барган бинага аларны ничек алып килүләрен, сакал-мыек баскан йөзләрен яхшы хәтерлим. *«Контрреволюцион өер», «фашист агентлары» кебек куркыныч сүзләр байтак кешеләрнең аңын томаласа да, гаепләнүчеләрне якыннан белгәннәр күңелләре белән алар яклы булып, һаман көрсенеп-уфтанып утырды. Чая сүзле Гафуров сөйли башлагач, соңрак Дружинин да кабатлады аны, залдагыларның кайберләре еларга тотына. Соңгы сүзен ул:*

— Күрерсез, тарих безне аклаячак, — дип тәмамлады.

Судтан соң бөтенесен «кара фургон»га төяп киттеләр, соңгы күрүебез шунда булды».

Гафуровны авылдан китеп кәсеп иткән шахтёр малае, дидек. Хәер, аларның кайсы алпавыт яисә сәүдәгәр малае соң? Исмәгыйль Гаринмы? Әллә Гали Вәлиевме? Очын-очка көчкә ялгап килгән игенче гаиләсеннән чыккан Гали Вәлиевкә тагылган «контра» дигән кара мөһер — һич ышандырмый.

Тагын бернәрсә. Судта гаепләнүчеләрнең тормыш юлы, чыгышы, уртак эш өчен көн-төн чабулары хакында ник бер кәлимә әйтелсен. Ләм-мим. Әйтерсең лә, аларның үткәне булмаган. Судны алып баручыларның — ә аңа Татарстанның Верховный Суды председателе Сәгыйтов рәислек итә — бар белгәне: «НКВД органнарында районда корткычлык эше җәелдерүегез хакында сигналлар бар. Һәм аларның күбесе расланды. Димәк ки, сез — хыянәтчеләр, контрреволюционерлар». Дәүләт гаепләүчесе — Татарстан прокурорының өлкән ярдәмчесе Галиев судның соңгы көнендә болай ди:

— Буржуаз милләтчеләр группасының эше тугыз көн буена җентекләп тикшерелде. Мин бөтен кискенлеге белән шуны әйтергә тиешмен, аларның гаепләрен йомшартырлык бер генә дәлил дә юк.

Ышансаң, ышан, ышанмасаң, юк. Шуның белән вәссәлам!

Яшермибез, судтагы гаепләү сүзендә китерелгән кайбер җитешсезлекләр дә булгандыр. «Кыят» совхозы басуларында бәрәңге дә алынып бетмичә калгандыр, начар ремонтлау сәбәпле туктап калган тракторлар да булгандыр. «Сабира эше»нең озакка сузылуы (сүз уңаенда сүз: аңа кул күтәрүчеләр тиешле җәзаларын алалар) да борчу уятмыйча калмагандыр, ләкин бит боларны аңлы төстә эшләнгән корткычлык, дип бәяләргә һичнинди җирлек юк. «Фашистик өер» капитализмга җан өрергә, аны торгызырга маташкан икән! Ихлас менә, башка сыймаслык гаеп.

Суд карары 4 ноябрьдә укыла (процесс 21 октябрьдән дәвам итә). Суд рәисе РСФСР җинаятьләр кодексының 58 нче статьясының җиденче, сигезенче, унберенче пунктлары нигезендә ундүрт гаепләнүченең иң югары җәзага — атып үтерүгә, ә берсенең унбиш елга барча хокуклардан мәхрүм ителүе турында хөкем карарын укый.

Ә ике көннән октябрь революциясенең егерме еллыгы билгеләп үтеләчәк. Олы тантана Бөек Октябрьгә егерме яшь тулу бусагасында революция варисларына чыгарылган нахак хөкем — еллар узып та гафу ителмәслек җинаять.

Нәфисә Биктеева сөйләгәннәрдән:

— Суд булып, хөкем карары игълан ителгәч, сеңлемнең ирен — Казанның 12 нче мәктәбендә математика укыткан Нур Гыймадиевны эшеннән алдылар. Бәҗаең, янәсе, «халык дошманы». Беркөнне сеңлем күз яшенә буыла-буыла: «Апа, китегез инде, безнең дә канатны кисүләре бар бит», — дип ялварды. Кемгә барып сыенырга? Балаларны ияртеп вокзалга чыгып киттем. Аска гәҗит җәеп бер төнне ничек кирәк алай уздырдык. Башка әмәл калмагач, Кәбирнең Иске Задурдагы (Чүпрәле районы — авт.) абыйсына телеграмма суктым. Өендә өреп очырырлык ризык заты, сыеры булмаса да, рәхмәт үзенә, биш баласы өстенә безне дә сыендырды. Кеше бөтенесенә күнегә икән: яхшының — яхшылыгына, яманның — яманлыгына.

...РСФСР Верховный Судының 1956 ел 2 апрель карары белән Татарстан АССР Верховный Судының 1937 ел 21 октябрь-4 ноябрьдә Буадагы процесста чыгарылган хөкем карары кире кагыла.

Кайчандыр суд эскәмиясендә утырган гаепләнүчеләр бүген хөкемдар булып, гомерләрен вакытсыз өзүчеләргә үзләре хөкем укыйлар. Исемнәрен кара таплардан юып, Вакыт Галиҗәнаплары гаепсез рәнҗетелгәннәрне — Туфан язган «киек казлар»ны — яңадан арабызга кайтарды. ■

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

ИСЛАМ ҺӘМ РӘСЕМ-СЫН СӘНГАТЕ — Мәгълүм булганча, шәригать җан ияләренең сурәтләрен ясауны тыя. Шуның аркасында элек кеше рәсемнәре төшерү, хәтта фоторәсемгә төшү дә нәшәргый гамәл исәпләнгән. *«Эт белән сурәт булган өйгә фәрештәләр аяк басмас»*, *«Сурәт булган өйдә намаз уку мәкруһдыр»* кебек тыюлар электән катгый саналган. 1912 елда да әле «Дин вә мәгыйшәт журналы *«Сурәт вә рәсемнәрне өйдә тоту мөселман кешегә гаммәви голәмә иттифакы илән хәрәмдер»*, — дип язган иде. Ш.Мәрҗани мондый тыюны түбәндәгечә аңлата: *«Пәйгамбәр заманында кешеләр сурәткә табынганнар. Шуңа күрә рәсем ясау гомумән тыелган. Ә хәзер андый куркыныч юк. Шулай булгач, тыюның сәбәбе бетә һәм тыюның кирәге калмый»*. Мәрҗани берничә тапкыр үзенең фоторәсемен алдыра, Истанбулда Мөниф паша йортында үзе күргән хатын-кыз скульптурасы турында һичбер тартынмый, шелтәләми яза (Х.Хисмәтуллин). *«1908-1914 еллар арасында «Гасыр» Һәм «Васыйтә» нәшриятлары тарафыннан күренекле татар әдипләре, мәдәният әһелләре һәм җәмәгать эшлеклеләренең (мәс., Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Камал, Һ.Атласи, Һ.Максуди һ.б.) фоторәсемнәре «ачык хат» (открытка) рәвешендә киң тарала»* (М.Госманов). Белгәнебезчә, хәзерге вакытта мөселман илләрендә басылган төрле китап-дәреслекләрдә рәсем-сурәтләр булмыйча калмый, ләкин гадәттә рәсемдәге кешеләр мөмкин кадәр схематик һәм яссы итеп сурәтләнәләр. Ләкин киләчәктә мондый тыюлар тагы да йомшый төшәр, дип көтәргә кирәк.

Безнең көннәрдә Ислам һәм сынлы сәнгать мәсьәләсе тагын бер куерып алды. Билгеле булганча, татарның иң күренекле улы Шиһабетдин Мәрҗанинең сынын Кабан күле буендагы Мәрҗани урамына һәйкәл

* Дәвамы. 2014 елның 3 нче саныннан басылып килә. Автор искәрткәнчә, «...бу сүзлекнең чирек өлеше 2007 елда «Мәгариф» нәшрияты тарафыннан 1000 данәлек тираж белән бастырып чыгарылган иде».

итеп кую планы бар иде. Күп кенә дин әһелләре моңа каршы күтәрелеп чыктылар. *«Әүвәл Татарстан Диния нәзарәте олуг галимнең сынын һәйкәл итүгә каршы махсус карар чыгарды. Соңра Согуд Гарәбстанында укып яткан шәкертләрнең бер төркеме Шиһаб Мәрҗанинең сынын кую Ислам диненә ни дәрәҗәдә афәт икәнлеге турында «Иман» гәзите аша мөрәҗәгать белән чыкты».* (Харис хәзрәт Салихҗан.) *Алар үз фикерләренә дәлил итеп Коръән-Кәрим кәлимәләрен китерәләр. Чыннан да Изге Китапта: «Ий мөэминнәр! Исерткеч эчемлекләр һәммәсе дә, отыш уеннарының һәртөрлесе дә, сыннарга табыну, гыйбадәт кылу, шулай ук ырым һәм багучылык — болар барысы да шайтан гамәлләре. Бу гамәлләрдән качыгыз. Сакланыгыз, шаять һәлакәттән котылырсыз»*, — диелгән. Ләкин монда сүз сыннарга табыну турында бара. Әгәр табыну юк икән, бу эшнең гөнаһы да юк. Әфганстанда тауташта Будданың борынгылар уеп ясаган мәһабәт сынын талибаннарның шартлатып юк итүләрен берничек тә аклап булмый, моны фанатикларның вәхшилеге дип кенә бәяләргә мөмкин.

ЙОДРЫК СУГЫШЫ — Борынгы төркидә — йомрык сугышы. Аны түбәләш тә дигәннәр. Пәрмә-пәр сугышу сүзенең мәгънәсе дә шул ук (коралсыз гына бергә-бер сугышу).

Электә урам белән урам, авыл белән авыл сугышлары булгалаган. XIX гасырда Казанда кышын Кабан күле өстендә татар белән руслар арасында да йодрык сугышлары еш була. Аларның тасвирын, мәсәлән, рус язучысы С.Т.Аксаковта табарга мөмкин.

//Җәмгыятьтә йодрык белән түгел, күбесенчә терсәк белән төртеп имгәтәләр. М.Чукас.

ЙОМЫШЛЫ ТАТАР, ЙОМЫШЛЫ МӨСЕЛМАН — Ясак түләүче крәстиәннәрдән (чёрные люди — кара халыктан) аермалы буларак, патшага башлыча гаскәри хезмәт итүчеләр (рус телендә — служилый, служивый). Рус дәүләте документларында «служилые татары», «свои татары» терминнары очрый. Башкорт терминологиясендә «хезмәтле кешеләр» төшенчәсе бар.

XVII-XVIII гасырларда хакимият контораларында күбесенчә тылмачлык итүче, йомыш-юлларга йөртелүче түбән чинлы татар кешеләре. 1718 елда Казан адмиралтиясенә (адмиралтействосына) кораблар төзү өчен урман кисү эшенә беркетелгәннәр. Җан башыннан салым түләү кертелгәч (1724), ясаклылар белән бертигез хокукта калдырылалар, ләкин үз исемнәрен XIX гасырга кадәр саклыйлар. *//Рус патшаларының татарларны дәүләт хезмәтләренә тартуы «йомышлы татарлар» дигән катламны китереп чыгарган.* Х.Госман. *Кенәз Долгоруков Бакуга Казаннан тылмачлыкка йомышлы татарлар чакыртып китергән.* К.Нәҗми. (Мисаллар «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ннән алынды.)

ЕВПАТОРИЯ — Кырымдагы шәһәр. б.э.га кадәр V-VI гасырлардан алып я.э. ның II гасырына кадәр биредә грек колониясе булган һәм грек колонистлары аны Боспор патшасы Митридат Эвпатор хөрмәтенә Евпатория дип атаганнар. XIV гасырда төрекләр яулап алгач, Евпаториягә Гезләү дигән яңа исем кушканнар. 1783 елда Кырым ханлыгы, Россия кул астына кергәннән соң, әлеге исемне рус колагына «яраклаштырып», Козлов дип үзгәрткәннәр. Әле Евпатория исеме кире кайтарылгач та аны Козлов дип атау дәвам иткән.

Евпатория шәһәрендә 1552 елга караган җомга мәчете бар.

ЕВРОИСЛАМ — XX гасырның 90 нчы елларында туган термин — «Европа Исламы». Көнбатыш чыганакларыннан таралган бу төшенчә

Евпатория

көнбатыштагыча яшәү үрнәкләре белән сыеша һәм сәясәткә катнашмый торган «европаи ислам»ны күздә тота. Баден-Вюртемберг федераль төбәге башлыгы Вольфганг Гирге: *«Мондый ислам Европа мәгърифәте традицияләре белән үрелгән ислам ул»*, – дип яза. Политолог Рафаил Хәким евроислам идеясен «Татарстан туфрагына» күчереп, хәзерге евроисламның нигезләрен XVIII-XIX гасырларда татар дөньясындагы реформаторлык хәрәкәтендә, XX гасыр башларындагы җәдидчелектә күрә («яңа җәдидчелек» — неоджадидизм). Ләкин җәдидчелек бер Татарстанда гына барлыкка килмәгән, Урта Азиядә, мәсәлән, М.Бекбуди, А.Фитрат, А.Дониш кебек күренекле җәдидчеләр билгеле. Шуңа күрә «евроислам» башлангычлары, аның яралгылары татар дөньясы белән генә чикләнми.

«Евроислам — рухияткә кайту ул», — дип яза Рафаил Хәким.

А.Юзиев хәзерге вакытта Татарстанда, көнчыгыш мөселман мәдәнияте кыйммәтләре белән беррәттән, техноген чыгышлы цивилизациянең бүгенге казанышларын да исәпкә ала торган Ислам кирәк, дип саный.

Чыннан да, кайчандыр дөнья күләмендә алдынгы урынны алып торган Ислам мәдәнияте — «дарелислам» фән һәм техника, әдәбият һәм сәнгать, шулай ук халыкның тормыш дәрәҗәсе ягыннан артта калган, таркау һәм зәгыйфь икътисадлы бер ярчен регионга әйләнде. Гарәп илләрендә тарих өчен «бер мизгеллек» нефть байлыклары үзара сугышларда һәм дин кардәшләре арасындагы низагларда исраф ителә, җилгә оча. Җирле халык үзенең киләчәк буыннар хисабына яшәвен аңламый. *«Шуңа күрә хәзерге мөселманга үзенең шанлы тарихы белән бүгенге тормышының кырыс таләпләре арасында туган капма-каршылыкта газапланып яшәргә туры килә»*. (Рафик Мухаметшин. Ислам в общественной и политической жизни татар и Татарстана в XX веке, Казань, Татарское книжное издательство, 2005; тәрҗемә безнеке – ***А.Т.***). Ислам мәрасимнәрен ничек кенә сакларга тырышмасын, бүгенге мөселман кешесе шул ук вакытта Исламның барлык принципларын да үтәп бетерми һәм бетерә дә алмый. Безнең арабызда тәкъвалык сирәк очрый хәзер. Ә хаҗ кылу елдан-ел кыйммәтләнә барганга, изге Мәккә чын диндарлардан коточкыч ераклашты, хаҗилык гөнаһкяр миллионерларның калканынамы, битлегенәме, әллә вөҗдан борчуларын баса торган алдавыч даругамы әйләнеп килә.

Бүгенге дин әһелләребез моңа («яңа җәдидчелек»кә, Ислам модернизмына) һичшиксез каршы торачаклар, ләкин яңалык барыбер өстен чыгар, дип өметләник. ■

ТЕЛЕ БАРНЫҢ – ИЛЕ БАР!

Рөстәм Акъегет

Татарстан радиосының заманында халык арасында зур популярлык казанган «Тел күрке – сүз» тапшырулары оештырылуына быел март аенда 40 ел тулды.
Исәпләп караганда, шушы 40 ел эчендә алып барылган бу тапшыруларны бер җепкә тезеп тоташ яңадан эфирга тапшырсаң, алар көне-төне берөзлексез бер ай яңгырар иде. Күпме бу, азмы? Эш күләмдә генә түгелдер, эш аларның әһәмиятендә дә булса кирәк...

Илһам учагы тирәсендә. Уртада – Рим Кәримов. 1970 ел, сентябрь

Заманында Мәскәү радиосыннан «В мире слов» дигән тапшыру бара иде. Шуларның кайсыдыр берсен тыңлагач, студент елларымда кулга каләм алырга мәҗбүр булган идем. Моңа тапшыруда рус телендәге төрки тамырлы сүзләрнең тырышып-тырышып славян телләре тамырына бәйләргә азапланулары этәрде. Хатымда Татарстан радиосында да тел турында тапшырулар башлап җибәрү, татар теленең хасиятен, байлыгын халыкка фәнни нигезләп, популяр чаралар белән аңлатып бару кирәклеген дәлилләргә тырышкан идем. Милли мәктәпләр бармак белән генә санарлык калган саңгыраулык заманы иде шул, җавап килмәде…

Язмыш шуклыгыдыр инде, мин, район мәктәпләренең берсендә рус теле һәм әдәбияты укытырга җыенган кеше, кинәт кенә үзем хат җибәргән бүлектә – радиода эшли башладым. Җитәкчем – радионың күренекле хезмәткәре **Рим Кәримов**. Аның күркәм сыйфатлары күп иде. Халыкка ихлас хезмәт итәргә теләгәннәргә мөмкин булмаганны да эшләргә әзер иде ул. Шунысын да әйтим, минем күп кенә фикерләрем, уй-теләкләрем, иҗади омтылышларым кабинетларда түгел, җитәкчеләр белән аягөсте аралашканда, рәсми булмаган шартларда җиңелрәк тормышка аша иде. Бу юлы да шулай килеп чыкты. Тел турындагы тапшырулар оештыру фикерен Рим абыйга ишегалдында тәмәке көйрәтеп торганда әйттем. Ул бу фикерне ишеткәч, бераз уйланып торды, аннары моңа үзе дә бик үк ышанып җитмәгән хәлдә: «Әйдә соң, тәвәккәлләп карыйк», — диде. Эш шуннан башланды.

Тапшыруның исемен бергәләп эзләдек. Шактый уйланып йөри торгач, кемнеңдер хәтерендә һич көтмәгәндә бер күренекле әйтемебез балкып китте: «Йөз күрке — күз, тел күрке — сүз!» әлбәттә инде, тапшыруның исеме «Тел күрке — сүз» булырга тиеш!» — дидек.

Хәсән Сарьян

Исеме бар, тик менә җисеме… Җисеме дигәндә, ул бит әле әзерләү генә түгел, ә беренче чиратта шул тапшыруны эфирга кадәр алып барып җиткерү иде.

Мәгълүм ки, ул вакыттагы тәртипләр буенча, партия өлкә комитетының рөхсәтеннән башка милли мәсьәләләргә әз генә булса да кагылышы булган тапшыруларны уйга да китерергә ярамый иде. Яңгыраячак күп кенә язмаларыбызның эчтәлеген, тематикасын, гомумән, тел турындагы тапшыруларның максатын һәм нигезләмәсен ачыклаган әллә ничә битле нигезләмәне рус телендә әзерләп, өлкә комитетның матбугат секторына илттек. **Илгиз Кәлимулла** улы **Хәйруллинга** рәхмәт, ул безне аңлады, кирәк булса дип, аннан да югарырак утыручылар каршында хәлебезне җиңеләйтерлек киңәшләрен әйтте дә, «Тел күрке — сүз»гә хәер-фатихасын бирде. Әле хәзер дә кайтып уйланам, мондый тәвәккәл адым ясап, ул үз җилкәсенә күпмедер җаваплылык та алгандыр…

Сулдан уңга: Рөстәм Фәйзуллин (Акъегет), Камал Саттарова, Рим Кәримов. 1975 ел

1975 нче елның март аенда беренче мәртәбә эфир дулкыннарына чыктык. Тапшыруны Рим абый үзе алып барды. Авторларга килгәндә, иң беренчеләрдән бу эшкә, җиң сызганып дигәндәй, Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты хезмәткәре **Рифгать Әхмәтҗанов** алынды. Аңа рәхмәтебез зур. Башлап җибәрмәс борын ук көтелмәгән хәлләргә дә юлыккаладык. Без элегрәк Мәскәүдә барган «В мире слов»тан соң ук, бер үк көнне эфирга чыга идек. Шундый якшәмбеләрнең берсендә бер кызык килеп чыкты. Мәскәү «Алабуга», «Бөгелмә» атамаларын «бугай», «буг» дигән урыс атамаларыннан дип аңлата (теге чакны кулга каләм алырга мәҗбүр булган вакыттагы сыманрак...), ә без алардан соң сүз алабуга балыгы һәм «бөгелеп аккан елгадан чыккан «Бөгелмә» атамасы икәнен бирәбез. Бу өстә утырган өлкән абзыйларга барып җиткән һәм моңа реакцияләре озак көттермәде. Моның очраклы туры килү генә икәнлеген, Мәскәү радиосының нинди язмалар әзерләячәген безнең берничек тә белә алмавыбызны һич тә дәлилли алмадык... әмма бу юлы өстебездә болытлар куерырга өлгермәде.

Бәхәссез ки, тел һәм әдәбият — милләтне милләт буларак саклап килүче дә, тәрәккый иттерүче көч тә. Һәм татар теленең бөеклеген, беркайчан да бетәргә тиеш түгеллеген ике арада буталып йөрүчеләргә аңлату кирәк иде. Бу изге эштә, шөкер, без, радио хезмәткәрләре, ялгыз булмадык. **Хәсән Сарьян**, **Сибгат Хәким**, **Нурихан Фәттах**, **Мөхәммәт Мәһдиев** кебек әдипләребез, **Әбрар Кәримуллин**, **Рүзәл Йосыпов** кебек галимнәребез ярдәмгә килде. Соңыннан Хәсән Сарьян **«Уеңны уйдырып сал»** дигән китабына безнең тапшыруларда барган гыйбрәтле чыгышларын аерым бер бүлек итеп кертте.

«Тел күрке — сүз» тапшыруларында озак еллар катнашып килгән, фидакяр хезмәт күрсәтеп, бәяләп бетергесез игелекләр кылган **Вахит Хаков**, **Хуҗи Мәхмүтов**, **Илдар Низамов** кебек танылган галимнәребезгә аерым тукталып китсәк тә буладыр.

Күренекле тел галиме, филология фәннәре докторы, профессор Вахит ага Хаковны «Тел күрке — сүз» тапшыруының чишмә башында торды, дисәк тә ялгыш булмас. Чөнки ул беренче авторларыбыз — тел белгече Рифкать Әхмәтҗанов һәм язучы Хәсән Сарьяннарга бик тиз кушылып китте һәм безнең тапшыруларда аеруча актив катнаша башлады. Тора-бара ул төп йөкне тартучыларның берсенә үк әверелде.

«Тел күрке — сүз» тапшырулары циклы ачылу белән редакциягә хатлар ташкыны ява башлады. Сөйләм культурасына кагылышлы хатлар белән бергә, алар арасында ана телебезнең язмышы өчен борчылып, ачынып язылганнары да байтак иде. Хатларга халыкка аңлаешлы телдә фәнни шәрехләр бирү һәм аларда-

гы фикерләрне цензура иләге аша үтәрлек итеп әзерләп, мөмкин кадәр тулырак җиткерү өчен киң эрудицияле галим дә, үткен телле каләм иясе дә, күпмедер дәрәҗәдә сәясәтче дә булырга кирәк. Бу сыйфатларның барысы да Вахит агада бар иде. Шулай итеп, иң җаваплы вазифаны — хатлар белән эшләүне үз өстенә алды һәм аны вафатына кадәр дәвам итте.

Моннан тыш, ул вакытлы матбугатта дөнья күргән басмаларга күзәтүләр ясап, радиотыңлаучыларны туган телебезгә багышланган язмалар белән таныштырып барды. Латинга күчү мәсьәләсен дә безнең тапшыруларда беренчеләрдән булып Вахит ага Хаков күтәреп чыкты һәм бу теманы, заманалар үзгәрсә дә, гел игътибар үзәгендә тотты.

Вахит ага «Тел күрке — сүз» тапшыруларының иң актив авторы булган кеше генә түгел, безнең акыллы киңәшчебез, рухи фикердәшебез дә иде.

Халык иҗатын җыючы галим, филология фәннәре докторы Хуҗи Мәхмүтов — Татарстан радиосының шулай ук иң актив авторларыннан. Телебезнең матурлыгын, тасвирсурәтләргә байлыгын һәрвакыт күз уңында тоткан галим менә инде 40 елга якын радионың «Тел күрке — сүз» тапшыруларында катнашып килә. Аның ана теле, татар әдәбияты, халык иҗаты белән бәйле үзе яратып яза торган темалары бар. Ул бездә **«Сүзлекләр тарихыннан»**, **«Тел галимнәре»**, **«Тел турында төрлесе»**, **«Тукай сүзләре»**, **«Исемнәр бакчасында»**, **«Фамилияләр ни сөйли?»** кебек рубрикаларны алып барды. Һичшиксез, бу язмалар тапшыруларыбызның тагын да баерак һәм кызыклырак булуына зур ярдәм иттеләр. Бүгенге көндә тапшыруда аның «Ни өчен болай әйтәбез» дигән язмалары яңгырый һәм алар да тыңлаучыларыбызда зур кызыксыну уята.

Моннан 15 ел чамасы элек безнең «Тел күрке — сүз» тапшыруларының авторлары сафына үзенең әңгәмәдәресләре белән танылган тел галиме **Илдар** ага **Низамов** килеп кушылды һәм Вахит ага Хаков, Хуҗи ага Мәхмүтов традицияләрен уңышлы гына дәвам иттерде. Аның ана телебез сафлыгына, сөйләм культурасына багышланган чыгышлары тиз арада күп санлы радиотыңлаучыларыбыз күңелен җәлеп итеп, киң даирәдә яңгыраш тапты. Ул чыгышларны тыңлаган яңа буын да үсеп җитте. Илдар аганың туган телне сөючеләр сафы яшәрә баруын, безгә килеп ирешкән тәкъдимнәрне-теләкләрне, гомумән, заман таләпләрен искә алып, һаман да баетылып, яңартылып барган әңгәмә дәресләре (без аны үзара «Илдар абый дәресләре» дип атыйбыз) «Тел күрке — сүз» тапшыруларының бүген дә үзәгендә тора.

Татар халкы, дигәндә, без беренче чиратта татар авылын күз алдына китерәбез. Телебезне, денебезне, динебезне, гореф-гадәтләребезне, әхлагыбызны, ахыр чиктә, безне, милләт буларак, нигездә шушы татар авылы саклап килде ләбаса. Безгә бүген туган авыл гына түгел, татар яшәгән һәр җир, һәр төбәк кадерле һәм газиз. Ул безнең үткәнебез, бүгенгебез һәм киләчәк язмышыбыз да. Шуңа күрә дә татар авылларының һәм калаларының тарихын, атамаларының килеп чыгышын яктыртуны без изге бурычыбыз, дип санадык. Әлбәттә, бөтен гомерен татар яшәгән төбәкләрне барлауга багышлаган фидакяр җан, филология фәннәре докторы Фирдәвес ханым Гарипованың шушы темага язылган хезмәтләре булмаса, без бу эшкә тиз генә керешә дә алмас идек. Фирдәвес ханым инде бүген арабызда булмаса да, без аның язмаларын әле дә файдаланабыз һәм үзебезнең кадерле авторыбызның берсе, дип саныйбыз.

Радио ул, ни дисәң дә, тавыштыр. Әгәр дә безнең тапшыруларыбыз халык күңеленә барып җитә икән, анда

Хуҗи Мәхмүтов һәм Вахит Хаков

яңгыраш таба икән, моңа без, әлбәттә, алтын тавышлы дикторларыбызга бурычлы. Аларның исемнәрен булса да телгә алмыйча ярамыйдыр. Бу җәһәттән, без «Тел күрке — сүз» тапшыруларының беренче чыгарылышларыннан башлап, вафатларына кадәр алып барган **Камал** апа **Саттарова** белән **Рим** абый **Кәримовны** зур хөрмәт хисләре белән искә алабыз. Соңынан эстафетаны **Мәрьям** апа **Арсланова** белән **Фоат** абый **Галимуллин** алды һәм ике дистә ел шушы тапшыруларны радиотыңлаучыларыбызның күңелләренә сеңдерерлек итеп җиткерде. Без аларга да бик рәхмәтле. Менә хәзер инде ничә ел дәвамында үзләренең ягымлы тавышлары белән алдагы буын алып баручыларының матур традицияләрен күренекле артист Флёра Хәмитова һәм Тәлгат Хамматшин дәвам иттерә.

Инде кабат тарихка әйләнеп кайтыйк. Дөресен әйтергә кирәк, без «Тел күрке — сүз» тапшыруларын башлаганда аны саклану рәвешендә башлаган, ягъни бу тапшыруларны телебез өстенә килгән афәттән калкан рәвешендә алган идек. Торгынлык дип аталган чорда без «Тугандаш халыклар үз телләре турында» дигән бүлек алып бардык. Анда башка милләт язучылары әсәрләре аша үз халкыбызны борчыган мәсьәләләрне күтәрергә омтылдык. Мәсәлән, **Чыңгыз Айтматовның «Гасырга сузылган көн»**, **Рәсүл Гамзатовның «Минем Дагыстаным»** әсәрләреннән өзекләр бирдек. Тугандаш халыклар шагыйрьләренең үз телләре хакында горурлык белән язган шигырьләрен татарча укый башладык. Әнә шул кысан хәлдә безне кыюлыкка чакырып, дистәләгән төбәктән дистәләгән хатлар килде, аларның төп эчтәлеге мондый таләптән тора иде:

Туган телебезне дәүләт теле итү;

халкыбызның сабыйларын балалар бакчаларыннан ук туган теленнән мәхрүм итүне закон нигезендә туктату;

башлангыч мәктәптән алып, югары уку йортларына кадәр бердәм татарча белем бирү системасын булдыру;

татар кешесенә эндәшү тәртибен, чит телдән кергән -ов, -ев кушымча-

ларыннан азат итеп, борынгыдан килгәнне үз асылына кайтару;

чит телләрне рус теле аша түгел, ә турыдан-туры татар теле аша укыту һ.б.

Бу таләпләр бүген дә, Татарстан Республикасында телләр турында законның күпмедер гамәлдә булуына да карамастан, көн тәртибендә кала бирә. Хәер, бермәлне, ун ел дәвамында даими яңгыраганнан соң, ниндидер сәбәпләр белән тел турындагы тапшыруларга ябылу куркынычы яный башлады. Партиянең Татарстан өлкә комитеты безнең эшне тикшереп, алга таба «Тел күрке — сүз» тапшыруларын калдыру-калдырмау мәсьәләсен хәл итәр өчен, Флёра Садри кызы Сафиуллина җитәкчелегендә зур галимнәр төркеменнән торган махсус рәсми комиссия билгеләде. Флёра ханымга рәхмәт, ул комиссияне дөрес юнәлештә эшләтә алды. Нәтиҗәдә, эшебезгә уңай бәя бирелде, ә «Тел күрке — сүз», радиобызның йөз күрке булып, әле дә булса яшәвен дәвам итә.

Заманалар үзгәргән саен, тел турындагы тапшыруларыбыз да үзгәрә, киңәя һәм тирәнәя, күтәргән проблемалары да саллырак була барды. Кайчандыр без тәвәккәллек белән күтәргән мәсьәләләрнең байтагы Татарстан Дәүләт Советы югарылыгында закон проектлары буларак формалашты.

Инде дә килеп, икетеллелек турында сөйләшәбез икән, бу өлкәдә редакция хәл кадәри хезмәт куйды: бу хакта күп кенә галимнәребез әле сүз генә алып барганда, без инде 250 дәрестән торган **«Татарский язык для вас»** һәм 50 дәресне эченә алган **«Изучаем татарский язык»** дигән тапшырулар шәлкемен эфирга чыгара башладык. Килгән хатлардан күренгәнчә, алар җөмһүриятебездә яшәүче русларда һәм башка милләтләрдә зур кызыксыну уятты. Соңыннан, бу тел дәресләре аерым китап һәм аудиокассеталар рәвешендә дөнья күрде.

Заманалар үзгәрә, туган тел мәсьләсе күз алдында кискенләшкәннән кискенләшә бара. «Тел күрке — сүз» тапшыруларына да камилләшергә, киңәергә, тирәнәергә кирәк, анда күтәрелгән проблемалар да саллырак булырга тиеш. Хәер, хәзер яңа көчләр өстәлде, иншаллаһ, бүген үзенең кырык еллыгын билгеләп үткән «Тел күрке — сүз» тапшыруыбыз үз кыйбласыннан тайпылмыйча, киләчәктә дә изге эшен дәвам итәр, дип уйлыйбыз. ■

Әбрар Кәримуллин

«Тел күрке – сүз» фәнни яктан әтрафлы, формасы ягыннан мавыктыргыч алып барыла. Монда тапшыруларның фәнни консультанты Вахит Хаковның да өлеше аз түгел. Бу тапшыруларны беренче чыгыштан алып хәзерге көнгәчә әзерләп килүче редактор Рөстәм Фәйзуллинның фидакяр тырышлыгын икърар итәргә кирәк. Тапшыруларның популярлыгы диктор Рим Кәримов һәм Камал Саттарова осталыгына да бәйләнгән».

Әбрар Кәримуллин

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1915 елның март ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Мохтаҗ мөселман урын эзли

Мохтаҗлыкта калып Казанга килгән литвалы бер мөселман конторада хезмәт итәргә яки рус теле, тарих, җәгърафия [география], хисап, җәбер [алгебра], һәндәсә [геометрия], хикмәт табигыя дәресләре укытырга урын эзли. Адресын «Кояш» идарәсеннән белешергә мөмкин.

Кояш. — 1915. — №653. — 13 март.

Габдулла әфәнде бенефисы

13 нче мартта Большой театр залында Кариевның бенефисы булды. Бенефис кичәсе үзе Большой театр кебек кинематограф өчен ясалган театрда, үзе сәгать 4тән 7гә кадәр вакытсыз-вакытлы булуына карамыйча, халык бик күп килгән, театрның меңнән артык кеше сыйдыра торган зур залы тәмам тулган иде. Артистлар уеннарны чибәр генә уйнадылар. Театрда һәммә нәрсәдән әүвәл, кичәнең бенефис кичәсе өчен бернинди уңайлыклары булмавына, пьесаның шушы көннәрдә генә ике мәртәбә уйналган булуына карамыйча, театр залының шыгрым тулы булуы күзгә бәреләдер иде. Бу көн бөтен Казанны театрга фәкать Габдулла Кариев дигән исемнең генә китергәнлеге әллә кайдан күренеп тора иде. Бу бенефиска дус-ишләрне димләштерү, билет тарату кебек эшләрнең берсе дә эшләнмичә торып, фәкать Габдулла әфәнде исеменең генә халыкны болай җәлеп итүе халкыбызның үз адәмнәрен танырлык вә олугларлык хәлгә килгәнлеген күрсәтәдер ки, моңар шатланмаска мөмкин түгел.

Габдулла әфәндегә пакетлар илә бүләкләр тәкъдим итүчеләр булган кебек, читтән бенефис илә тәбрик итеп телеграммалар да килгәләгән. Телеграммалар арасында «Ил» газетасы[1] идарәсеннән түбәндәге телеграмма да бар: «Сезнең артистлык куәтегезне һәм дә милли театр өчен иткән бөек хезмәтләрегезне тәкъдир итеп, чын күңелдән үзегезне тәбрик итәбез вә сезгә янә бик күп еллар хезмәт итәрлек сәламәтлек вә көч телибез».

Габдулла әфәнде, профессорларга күренгәннән соң, озакламыйча җылы тарафларга дәваланырга китәчәктер. Әкмали

Кояш. — 1915. — №654. — 15 март.

Мөселман фельдшерица-акушерка

Үткән ел фельдшерский курсны тәмам иткән Фатыйма туташ мулла Габдулла Апанай кызы өченче көн акушерский курсны да тәмам итеп, фельдшерица-акушерлык шәһадәтнамәсе алган. Һәмширәләренә [кыз кардәшләренә] тыйбби ярдәмгә әзерләнгән Фатыйма туташка уңышлар телибез. Тел белмәгән хәлдә, башка милләт фельдшерицаларына мөрәҗәгать итәргә

---

[1] «Ил» — 1913 елдан Петербургта, 1914-1918 елларда Мәскәүдә нәшер ителгән татар газетасы. Нашире — Г.Исхакый.

мәҗбүр була торган мөселман хатыннары, моннан соң үз кардәшләренә мөрәҗәгать итсәләр була инде.

Кояш. — 1915. — №658. — 19 март.

Габдулла Кариевның сәфәре

21 нче мартта Габдулла әфәнде Кариев Кырымга дәваланырга Казаннан сәфәр китте. Габдулла әфәндене озатырга газета идарәләреннән кешеләр, каләм әһелләре вә зыялылардан һәм ханымнардан байтак кеше төшкән иделәр. «Сәйяр» труппасы, артистларыбыздан Кәрим әфәнде Тинчурин тәхте идарәсендә, әүвәлгечә дәвам итеп, һаман спектакльләр биреп торачактыр.

Кояш. — 1915. — №660. — 22 март.

***

Җомга көн 27 нче мартта Большой театрда Ильяс Кудашев-Ашказарский труппасы тарафыннан театр, балет һәм кинематографтан гыйбарәт киң программа илә икенче мәртәбә мөселман кичәсе ясалачак икән. Билетлар хәзердән сатыла башлаган.

Ятим фәкыйрьләрне укытырга

Казан җәмгыяте хәйрияи исламиянең ятимнәр-фәкыйрьләр мәктәбендә (мәктәп приютында) укып чыккан балалар, әлегә кадәр өч ел мөддәт шушы мәктәптә уку белән канәгатьләнеп, моннан соңгы көнкүрешләре тәкъдир Ходайга тапшырылып калдырылмакта иде. Ишетүебезгә караганда, җәмгыяте хәйрия әгъзаларының кайберләре арасында бу хәлгә дикъкать итүчеләр табылган. Бу хәл башланган эшне юлда калдыру буладыр. Бу рәвешчә башланган эшне юлда калдырмауның бер чарасын күрү мәслихәт булыр иде, дигән фикерләр сөйләнә башлаган. Бу фикергә килгән кешеләр, приют мәктәбен бетергән балаларның һәр ел берничәсен урта мәктәпләргә биреп укыту мәслихәт булыр иде, дип уйлыйлар. Болар урта мәктәпкә бирелгән балаларның мәгыйшәте (ашау-эчү, кием-салым, торулары) өчен приютта бер бүлмә билгеләргә вә мәсърафын [чыгымнарын] һәм дә уку әсбабы мәсърафын җәмгыяте хәйрия тарафыннан тотарга вә моның өчен нык тотынып эзләнгәндә варидәт мәнбәгъләрен [керем чыганакларын] дә табарга мөмкин булыр иде, диләр. Урта мәктәпләрдә уку хакы түләүне үз өсләренә ала торган һиммәтле затлар табылачагына өмет баглыйлар. Бу өмидләренә сәбәп кайбер кешеләрнең кылган вәгъдәләре икән.

Без, үз тарафыбыздан, бу фикерне чын күңелдән алкышлап каршы алабыз, вөҗүдкә чыгуын вә уңышлы сурәттә дәвамын телибез. Варидәт мәнбәгъләрен табуда җәмгыяте хәйриябез оста үзе. Бүтән җәмгыятьләребез, гомум халкыбыз вә матбугатыбыз кул-кулга тотынышып барганда читенлеккә очрамаячагыбызга ышанабыз.

Кояш. — 1915. — №661. — 23 март.

Туташ вә әфәнделәр дикъкатенә

Гарипләр йорты файдасына бу елның 4 нче апрелендә булачак «чәчәк сату көне»ндә чәчәк сатышыр өчен язылырга теләгән туташ вә әфәнделәр 14 нче районның мөдирәсе Гайшә туташ Юнысованың үз өендә (Екатеренская урамында) һәр көнне иртән сәгать 10нан кич 6га кадәр языла алачактыр.

Бу файдалы эшкә ярдәмләшү тиешле булганга күрә, туташ вә әфәнделәрнең алдан язылып куярга дикъкатьләрен җәлеп итәбез.

***

Христианнарның пасха бәйрәмнәренең әүвәлге көнендә Казан мөселманнарының кибетләре көн буена ябык булды. Пасханың икенче, өченче көннәрендә фәкать бишәр сәгать сәүдә иттеләр.

Мөселман шифаханәсенә

Җомга көн 20 нче мартта Ак мәчеттә мөселман шифаханәсе файдасына иганә җыелып, шифаханә хәзинадарына тапшырылган. Бу көндә җыелган иганә 92 сум 32 тиен булган.

Кояш. — 1915. — №662. — 24 март.

Пасха мөнәсәбәте белән вак-төяк.

Бөтен христиан галәме зур тәкъдис белән[2] уздыра торган пасха, шәһәрнең христиан галәмен генә түгел, бәлки башка милләтләрне дә үзенә тарта. Күршеләребез русларның зур тантана белән уздыра торган бу бәйрәмнәре, мөселманнарның зур бер кыйсемен урамнарга чәчә вә хәтта бер кыйсемен кәлисәгә [чиркәүгә] кадәр илтәдер.

Менә сезгә бер кәлисә алды. Шатланган вә дини бер дәрт белән дәртләнгән рус халкы — бае, фәкыйре, зыялысы гавами зур бер ихлас белән гыйбадәт итәргә җыела, халык агыла, кәлисә алды гадәттә бер тыгызлыкка әйләнә. Менә аның алдына бер ат килеп туктый, аның трантасыннан ике мөслимә төшә. Алар да кәлисәгә юнәләләр, тыгызлыкка карамый, гыйбадәт итәргә килгәннәр арасына тыкшыналар. Бу ат һәм аны тоткан бала миңа танышлар: Казанның күп муллалы бер мәхәлләсенең бер имамының аты. Ат тотучы бала да әлеге хәзрәт мәхдүме. Мәхдүм, анасы абыстайны кәлисәгә төшергәч, өйләренә таба борылып кайтып китә. Миңа бу күренеш бераз ятрак шикелле тоелганлыктан, мин мәхдүмне туктатып: «Кемнәрне китердең?» — дип сорамакчы булам. Ләкин өлгерә алмыйм.

Әлеге хәзрәт минем бик белә торган хәзрәтем. Ул хәзрәт, һәр җомга намазында дияргә мөмкин, хатыннар өчен хиҗабның фарызлыгы тугрысында, татар театрына баруның хәрәмлеге тугрысында вәгазь сөйли. Театрга барган кешеләрне вә хиҗабсыз хатыннарны тәкфир итү [кяфер санау] дәрәҗәсәнә җитә. Ул хәзрәт гаиләсенең атлар белән кәлисәгә килгәнен күргәч инде, пасха бәйрәмен итешүнең безнең арада никадәр шөһрәт кәсеп иткәнлеген аңлыйсың.

Мөселман шифаханәсе

Мәҗрух вә авыру гаскәриләр тәрбиясе өчен ачылган мөселман шифаханәсендә, пасха бәйрәмендә мәҗрухларга, мәҗрух русларга кулич вә йомырка кеби бәйрәмгә мөнасиб [туры килгән] ашлар вә мөселманнарга ит бәлеше кеби ашлар бирелгән. Көндезге ашлар янә бәйрәмгә мөнасиб ителмештер. Күңел ачу өчен шифаханә мөтәвәллисе тарафыннан, табиб мөсагадәсе белән байтак пластинка белән граммофон китерелгән. Ә.Хәсәни тарафыннан, табиб мөсагадә иткән вакытта, һәвәсле уйнаучы табылганда

[2] Тәкъдис белән — изге дип ышану белән.

уйнау өчен шифаханәгә бер гармун һәдия ителгән. Гомумән, мәҗрухлар бәйрәмне күңелле үткәргәннәр…

Бәйрәм бетү мөнәсәбәте белән шифаханәгә Ләбибә ханым Хөсәенова кызлар мәктәбеннән 500 данә йомырка, Фатиха ханым Аитова кызлар мәктәбеннән 214 данә йомырка, Марфа Егоровна Трофимовадан 54 данә йомырка һәм 54 булки, Газизҗан Галиев әһлиясеннән 28 данә ит бәлеше, Ибниәмин Мортазиннан бер чирек сөт һәм ярты пот сушки китерелгән. Садыйк Галикәевтән 30 данә кәләпүш бирелгән. Саратов губернасы Сюзюм станциясе Пәлдәнге авылыннан[3] Мәрьям Әсфәндияр кызы Дибердиевадан җибәрелгән әсбаптан Аитова кызлар мәктәбендә тегелеп, хәзерләнеп шифаханәгә тапшырылган: чалбар — 20 данә, тужурка — 24 данә.

Кояш. — 1915. — №663. — 25 март.

Оят һәм хурлык[4]

Сәгать көндезге 5-6ларда Воскресенская урамында атта йөрүче дамалар Австрия әсирләренә «воздушный поцелуй»лар җибәрделәр, җәяүле дамалар алар белән танышырга бәйләнеп яттылар, аларга чәчәкләр, конфетлар тәкъдим иттеләр. Хатыннар ярымының бу эше адәмлек хисен хурландырадыр…

Кызлар мәктәбендә укый торган кызларның да бәгъзеләре үзләрен шушылай кабахәт тоттылар. Кайгы аларның ата-аналарына, хурлык аларны тәрбия итә торган мәктәпләргә!

Моннан да коточкычрагы шул ки, бәгъзе дамалардан үзләренең шушы эшләре тугрысында менә нинди сүзләр ишетергә тугры килә: «Алар шундый яшьләр, шундый гүзәлләр, алар каһарманнар бит!» — диләр.

Болар нинди каһарманнар?.. Бу каһарманнарның фәкать көчсез картларны, зәгыйфь хатыннарны һәм вак балаларны гына кыйнарга сәләтле кешеләр икәнлекләрен уйлаганыгыз бармы? Болар ватаннарына кайткач, сезнең тугрыда нәрсә сөйләп йөрерләр?

Сугыш дәвам иткән вакытта дошман һаман дошман килеш кала! Сугыш мәйданында аңар мәрхәмәт булмаска, сугышның арт ягында да аңар игътибар булмаска тиеш! Сәедгәрәй Алкин.

Казанда мөгаллимәләр өчен курслар

Ишетелүенә күрә, бу ел Казанда мөгаллимәләр өчен курслар ачылырга уйланадыр. Курслар өчен Аитова мәктәбенең бинасын алырга карар ителә. Алар Фәхрелбәнат Сөләймания тәхте идарәсендә, беничә мөгаллимәнең катнашы белән ачылып, май башыннан август башына кадәр, ягъни өч ай дәвам итәчәкләр. Курслар ике сыйныфтан гыйбарәт. Бу курсларның программасы шактый киң булачак. Курслар ачарга рөхсәт сорап гариза бирелгән инде.

Кояш. — 1915. — №667. — 30 март. ■

[3] Пәлдәнге авылы — хәзерге Пенза өлкәсенең Кузнәй районына керүче татар авылы. Заманында авыл шактый бай булып, бирәдә 3 мәчет, постау фабрикасы булган. 2004 елда 119 йортта 368 кеше яши.

[4] Перемышльны алу уңаеннан Казанга күпләп китерелгән әсир солдатлар шәһәрнең «рус дама һәм кызлары» белән кызыксына башлый. Тегеләре дә битараф булмый, киң күңеллелек күрсәтә. Рус һәм татар матбугаты Казан кызларының дошманга мондый мөнәсәбәтен тәнкыйтьләп ачулы мәкаләләр яза. С.Алкинның да шундый ук мәкаләсе «Казанский телеграф» газетасында басыла, ә «Кояш» газетасы мөхәррирләре «Казанда әсирләр» дигән язмада әлеге мәкаләдән тәрҗемә итеп цитата китерәләр.

«ТЫНГЫСЫЗ КАЛӘМ» БИТЛӘРЕННӘН...

П.САЕСКАН (Фаил Шәфигуллин)

....

ТӘҮБӘ

(Каләмдәш дусларыма ачык хат)

Хөрмәтле иптәшләр, кадерле каләмдәш туганнарым. Беләм, сезнең каршыгызда бик тә гаеплемен. Бары бернәрсә генә әйтә алам: мин бит аны зур акылым белән түгел, ә чын күңелемнән эшләгән идем.

Ничектер шулай туган якларга кайтып төштем. Яңа аерткан каймак эчкәннән соң, бер повесть язып ташладым. Укып чыкканнан соң, үзем дә шүрләп куйдым, коточкыч шәп чыккан бит бу! Журналда да башта икеләнеп калдылар. Шулай да, бастырып чыгардылар.

Менә шуннан соң башланды инде хәлләр! Укучылар яза, тәнкыйтьчеләр мактый, күршеләрем горурлана, ә язучылар... миннән бөтенләй йөз чөермәсенме?! Башта үпкәләп тә куйдым, соңыннан гына барып җитте — мин хаклы түгел! Уйлап кара: яңа гына каләм очлаган кеше, нахалланып, исемле зур язучыларның иҗади биленнән түбән бәрсен әле!

Күз алдыма китерәм: нindidер аягына басар-басмас бер көчек, шәфәкъ аллыгын сездән матурраак язсын әле! Иптәш проза секциясе председателе, сезгә ничек кыен булгандыр, ә?

Ә сез, Меркурий Әбделмәмбитович? Мине «кеше күңеленең сәкесенә үтеп, ак мендәрдә аяк бөкләп утырган өлкә масштабындагы Достоевский»га тиңләгән рецензияне ничек авыр кабул иткәнсездер?! Югыйсә, моңарчы һәр киңәшмәдә өлкә Достоевскиена сезне генә тиңлиләр иде.

Сезнең алда да гаепле мин, хөрмәтле Хәерниса Эзоповна! Сезнең «коронный» жанрыгызга кагылырга кирәк бит! Әле җитмәсә газеталарда язган булалар: имеш, башлап язучы ветераннарны почмакка кысрыклаган. Алай итәрсең, бар...

Ышаныгыз миңа, әдәби дуслар, барысы да алдыйлар — тәнкыйтьчеләр дә, укучылар да, мин үзем дә! Минем повестьта берни дә юк, ә нидер бар икән, ул — нерв җепселләренең тәшвишләнүеннән туган галәмәт кенә.

Ышаныгыз, дуслар, мин бу оятсызлыгымны юарга тырышырмын. Икенче повестемны мин шундый агач тел белән язармын! Сезнең төшегезгә дә кермәгән таш персонажлар уйлап табармын! Аңлыйм, бу миңа авыр бирелер, чөнки сез гомерегез буе шундый персонажлар иҗат итәсез, ә минем әле әдәби стажга тәүлек ярымнан бер генә ел тула. Мин бу эштә үземне кызганмам, укучыны кызганмам, ялгышымны барыбер төзәтермен.

Әлбәттә, тәнкыйтьчеләр язганча, мин яхшы психолог та булып китәр идем, әмма мин бер нәрсәне төшенеп алдым: шундый коллегалар бар бит, алар кеше уңышына караганда үз уңышсызлыкларын җиңелрәк кичерә.

Һәрхәлдә, уйламаганда гына әдәбиятка керткән хәзинәм өчен мине гафу итүегезне сорыйм. Инде гөнаһларны сызарга кирәк. Кара савытым янына китәм.

ТМИН (Туфан Миңнуллин)

....

ЯШӘСЕН ХАТЫН-КЫЗЛАР!

Хатын-кызлар турында мин бик күп акыллы сүзләр әйтеп шигырь язган шагыйрь. «Хатын-кыз ул — һәрвакыт хатын-кыз!» дип шигърияттә иң беренче сүзне мин әйттем. Хәзер дә әйтер идем, тик соңгы вакытта шигырь язарга вакытым юк. Шуңа күрә,



дөньяның данлыклы акыл ияләренең хатын-кызлар турында әйткән кайбер искиткеч зирәк сүзләрен генә кабатлап чикләнәм.

Гораций: Desinit in piscet mulier pormosa superhe.
Ямаш Игәнәй: Ачуланма, яме?!
Сенека: Viri a diis reqentes.
М.Хөсәен: Янар Везувий ул —
хатын-кыз.
Судзуки: ...
Н.Әхмәдиев: Мин — мин кебек,
син — син кебек.
Плавт: Mulier tum bene olet ubi nihie olet.
Р.Низамиев: Син Зөһрә төслерәк.

Зирәк сүзләр эзләгәндә үзебезнең татар шагыйрьләренең хатын-кыз турында әйткән гүзәл сүзләреннән җырлап йөрер өчен шигырь дә төзеп булуы ачыкланды. Игътибар белән укуыгызны үтенәм.

Илдар Юзеев

Ренат Харис

Гәрәй Рәхим

И.Юзеев: *Исемеңне дә белмим,*
Төсеңне дә белмим,
М.Шабай: *Җуйган инде күптән*
исен дә;
Г.Афзал: *Кем хатыны дип беләсез —*
Минем хатын,
Ш.Галиев: *Ә син һаман, һаман исемдә.*

Г.Рәхим: *Бас каршыма.*
Р.Мингалим: *Каптыр изү*
төймәләрең...
Р.Фәйзуллин: *Нинди матур ялган!*
Р.Харис: *Ике шәраб берсен берсе*
Айныта алмый...
Р.Гатауллин: *Син китсәң — еламам.*
М.Галиев: *Әй!*
Ф.Сафин: *Ник уйнамый күрше кызы*
Гел минем белән генә?
Зөлфәт: *Калды утлар, син дә калдың...*
М.Әгъләмов: *Булдыра алсаң — сөймә.*

Кушымта өчен:

Р.Миңнуллин: *Шулай шул,*
Шулай шул.

Искәрмә! Цитаталарда бернинди фальсификация юк. Иптәш Судзуки мәсьәләсендә генә шигем бар.

1987 ■

Фәрит Вахитов,
Илдус Әҗемов һәм
Зөлфәт Хәйруллин шаржлары

Мирасворд



Мамадыш районындагы керәшен авылы

«Ак Барс» Холдинг компаниясе башлыгы

... - том

Кечкенә Иван

Вахит, Хисмәтуллин

Актриса ... Русланова

Элек татарларда сабан эшләре беткәч үткәрелгән бәйрәм

... де Мопассан

Кешеләргә мәрхәмәтле мифик зат

Корыган үлән

Жак ... Кусто

Стройның фронтның уң яки сул очы

Грузиядәге елга

Биш герой үстергән керәшен авылы

Католик рухание

«Ак кыялар турында ...» (Р.Мөхәммәдиев)

Капюшонлы спорт курткасы

Р.Киплингның «Джунгли китабы»ндагы елан

«Яшел ...» (Г.Әпсәләмов)

Керәшеннәрнең җәйге бәйрәме

Индонезия составындагы утрау

Н.Гоголь повесте

Дивар шәмдәле

Йокы (иск.)

Диңгездән энҗе эзләүче япон

Нота

Василий — Бәчели, Мария — Маржый, Татьяна - ...

Шагыйрә ... Янсуар

Төньякта яшәүче төрки халык

Борынгы грек

Җайдак утыргычы

Керәшеннәрнең мәдәни-агарту газетасы

Нота

Композитор ... Макаров



Морза, түрә

Кайбер Шәрык илләрендә монарх титулы

Рәссам ... Гог

... Лукойе

Гитаның игезәге

Азиядә яшәгән борынгы күчмә төрки кабиләләр атамасы

Рәис Габдулла төзеде.

2 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Султан унга: «Кораб», әҗәт, магул, «Хәят», алпар, митра, Марс, саам, артист, тау, Кирам, Ош, Аеш, анам, шималь, яу, Максуди, бума, анда, Ак, баб, Низами.

Өстән аска: күмә, Карашәм, Регул, Ташаяк, псы, Усман, Болгарская, Кир, ратин, ода, шар, Габди, тамил, нам, Хисам, Бабич, Җүкәтау, «Яра», очлым, Туктамыш.

Воскресение тавы. Ф.Х.Грахе даруханәсе

«БЕЗНЕҢ МИРАС» елъязмасы / март

● 640 ел элек (1375)

Хөсам Кятиб «Җөмҗөмә солтан» дастанын яза.

● 300 ел элек (1715)

Күренекле мәгърифәтче, дин әһеле һәм яугир, милли азатлык хәрәкәтенең оештыручысы һәм җитәкчесе булган Батырша (Габдулла Галиев) (1715-1762) дөньяга килә.

● 110 ел элек (1905)

Мәшһүр төрки телләр галиме, филология фәннәре докторы, Каракалпакстан, Төрекмәнстан, Казакъстан һәм Россиянең атказанган фән эшлеклесе Николай Баскаков (1905-1996) дөньяга килә.

● 95 ел элек (1920)

14-16 мартта Мулланур Вахитов исемендәге клубта Казан шәһәренең татар артистлары һәм музыкантларының беренче конференциясе уздырыла. Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең аң-белем тарату бүлеге тарафыннан чакырылган әлеге конференцияне Кәрим Тинчурин ача.

● 75 ел элек (1940)

12 мартта Казанда Максим Горький музее ачыла. Йорт-музей Галактионов (хәзер М.Горький) урамында, элек Деренков пекарнясы булган (1880 елда язучы биредә эшләгән) йортта урнашкан.

● 70 ел элек (1945)

8 мартта Татар дәүләт опера һәм балет театрында беренче татар балеты «Шүрәле»нең премьерасы була. Композиторы — Фәрит Яруллин, либретто авторы — Әхмәт Фәйзи. Сәхнәгә куючылар: Леонид Жуков һәм Гай Таһиров. Дирижёры — Ильяс Әүһәдиев.

● 60 ел элек (1955)

8 мартта күренекле драматург Таҗи Гыйззәт (1895-1955) вафат була.

● 55 ел элек (1960)

Алма-Атада Фатих Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы» романы казакъ теленә тәрҗемә ителә.

● 45 ел элек (1970)

«Казан утлары» журналында Газиз Мөхәммәтшинның «Йөрәктәге эзләр» романы басыла башлый.

● 25 ел элек (1990)

Нәниләр өчен татар телендә «Салават күпере» исемле айлык журналның беренче саны дөнья күрә.

ИЛЬЯ МАКСИМОВ

«Питрау гүзәле». 2008 ел. Киндер, майлы буяу

«Авылны юксынганда» (фрагмент). 2011 ел. Киндер, майлы буяу

1963 елның 6 августында ТАССРның Саба районы Тәмте авылында туа.

1982 елда Казан сәнгать училищесын тәмамлый. Шул ук елны армия сафларына алына, ике ел хәрби рәссам була, армиядән соң бүгенгәчә Алабуга шәһәрендә яши.

2000 елда Чаллы педагогия институтының сәнгать-графика факультетына читтән торып укырга керә, шул елдан бирле эше-һөнәре балалар белән бәйле.

1987 елдан башлап төрле күргәзмәләрдә катнаша. 2014 елдан — Татарстан Рәссамнар берлеге әгъзасы.

АЛДАГЫ САННАРДА:

«Ул вакытлар анда тимер юллар, машина, телеграм дигән нәрсәләрнең исеме дә улмадыгы кеби, низам, хөкем, гадаләт, мосавәтнең дә нә идкен дә белмәделәр иде. Кем көчле – дөнья шуныкы...»
КАСЫЙМ БИККОЛЫЙ. ТӨРКЕСТАН.

«Тормышка чыкканнан соң, мин аны (Салих Сәйдәшевне) күргәндә, ул минем берлә исәнләшмәде...»
ӘМИРХАН ЕНИКИНЕҢ «ГӨЛӘНДӘМ ТУТАШ ХАТИРӘСЕ» ӘСӘРЕНӘ НИГЕЗ БУЛГАН ФАТИМАИ-ЗӨҺРӘ КУЛЪЯЗМАСЫ.

«Шул шигырьләре чыгу белән Казан хатын-кызлары тузга язмаган хәбәрләр таратып: «Бу шигыре минем турыда, минем хакта. Ул мине сөя, ул минем белән таныш», – диләр...»
ВАФА БӘХТИЯРОВ. ТУКАЙ ТУРЫНДА ИСТӘЛЕКЛӘР.

«Гаризаларына алар: «Фронттан кайттым. Яңадан эшкә керешергә рөхсәт итегез», – дип яза; әйтерсең лә дүрт ел буе ут эчендә булмаганнар да! Әйтерсең лә чираттагы ялларыннан яисә командировкадан кайтып килешләре!»
РӘДИФ СӘГЪДИ. ФРОНТОВИК-АРТИСТЛАР.

Индекс:
Татарстанда – 54132
Россиядә – 70275
www.beznenmiras.ru

«Безнең мирас» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» (Бауман урамы, 29/11) кибетеннән сатып алырга мөмкин.

4 612750 670172

№02 / 2015